Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

07
июль 2018
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ФӘРИТ ЯКУПОВ. «АВЫЛ КЕНТАВРЫ»

Галиев мәчетендә Ураза гаете намазы



Фотолар http://president.tatar.ru сайтыннан алынды

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

07 (295)

июль 2018

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

56

10 **КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ ЯЗМЫШЫ.** *Булат Хәмидуллин*


РСФСР

СВИДЕТЕЛЬСТВО О СМЕРТИ

II-А № 954293

Гр. Галлутдинов Махмуд Галлутдинович

умер (ла)

возраст 52 года

Причина смерти

о чём в книге записей актов гражданского состояния о смерти 1952 года апреля месяца 11 числа произведена соответствующая запись за № 25

Место смерти: город, селение

район, область, край, республика

Место регистрации:

Дата выдачи 13 апреля 1952

82 **МӘХМҮТ ГАЛӘҮ (1886-1937)**

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР…

3 **Ренат Харис**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Гәүһәршад.** *О.Иванова*
9 **Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре**
10 **Казан ханлыгының язмышы.** *Б.Хәмидуллин*
15 **Керәшеннәрдә «имнәү», сихер һәм күрәзәлек.** *Р.Исхаков*
20 **Нагайбәк казаклары: саннары, яшәү урыны һәм үзидарә.** *Р.Әминов*
24 **Татар телен гамәлгә кую мәсьәләләре.** *Х.Габидуллин*
28 **Эчкен татарлары.** *Р.Исакаев*
31 **«Шул татарны күрәсе иде, нинди кеше икән?»** *Л.Мортазина*
36 **Америка мәктүбләре.** *З.Габдуллин*
38 **Гарифҗан Мөхәммәтшин: «Әхлакның тамыры – авылда!»**
42 **Марат Юнысов: «Сабан туена зур өмет баглыйбыз»**
48 **Катай авылы һөнәрчеләре.** *Т.Кәримов*
52 **Икшермә чиркәве.** *Г.Закирова*

МӨҺАҖИРЛӘР МИРАСЫ

56 **«Яңа милли юл»**

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

62 **Кем ул Пурхи Ахван?**
64 **Чуашлар.** *З.Бәшири*

ДИНИ МИРАС

69 **Ислам дөньясы.** *Г.Ибраһимов*

ТАТАР ГАМЕ

74 **Остаз.** *Р.Галиуллин*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Ленар Гобәйдуллин
89520365448

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррире
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ӘДӘБИ МИРАС

78 **Сандугач.** *Г.Галиев*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

82 **Мәхмүт Галәү**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

86 **Истә, һаман да истә!**
88 **Заһит Таз.** *З.Зәйнуллин*
90 **Милли мәгариф каһарманы.** *Х.Бәдигый*

СӘНГАТИ МИРАС

94 **Әз-мәз үзем турында.** *Р.Шәрәфи*
99 **Бәхетле моң остасы.** *М.Фәйзулаева*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

104 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

106 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
110 **Симетбаш җыены-2018**
112 **Киез итекләр иле**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Июль*

Заказ №.Е-1606. Тираж – 2050 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 26.06.2018
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Авыл кентаврлары». 2001 ел
Фәрит Якупов рәсеме

Безнең мирас №7 июль 2018

Ренат Харис

Татарлар

(Поэма-монологтан)

Тарихның кагылган саен
куба, коела ярчыгы,
катламнары арасыннан
татар чыга, татар чыга.

Мин чыгам ул... Мин ул татар –
һәр заманның тугры улы,
кирәксә – урак, кирәксә,
гадел кылыч тоткан кулы!

Нәкъ башка халыклар кебек –
мин җиңдем дә, җиңелдем дә –
барлык даным һәм хурлыгым
исемемнең җелегендә.

Дусларга аркадаш булдым,
дошманнарга сатылмадым.
Кальгаларым тузан булды,
Ә исемем ватылмады!

Халыклар исеме – алмаз!
Чорлар кырлый аны чарлап...
Татар дигән бриллиантны
киләчәк тә торыр барлап. ■

Безнең мирас №7 июль 2018

Гәүһәршад

Ольга Иванова

ТӘРҖЕМӘЧЕДӘН

Гәүһәршад – Нурсолтан ханбикә белән Ибраһим ханның кызы. Тарихчылар аның турында шактый каршылыклы фикерләр язып калдырган. Мәсәлән, Һади Атласи: «Бу тезгенсез хатын... үзе хатын гына булса да, аның Казан ханлыгына иткән зарарлары мең ирнекеннән артык булды. Казан ханлыгының бетүенә көч куйган кешеләр арасында бу хатын иң зур урын тотты», – дип мөһер суккан. Замандашыбыз, танылган галим, тарих фәннәре докторы Сәлам Алишев исә бер мәкаләсендә бу уңайдан: «[Һади Атласи фикерен] раслый торган бернинди ышанычлы дәлил китерелми... Гәүһәршад... катлаулы көрәш шартларында дәүләтнең тынычлыгын, мөстәкыйльлеген саклап калыр өчен күп көч куйган. Казан ханлыгы мәнфәгатьләрен кайгыртткан. Бу эш аның гамәлләре белән раслана. Минемчә, [Һади Атласи]... цензурадан шикләнгәнгә, рус хөкүмәтенә каршы сүз әйтүдән тыелгандыр», – дип ассызыклап әйткән иде.

Һади Атласи башлыча рус тарихчылары хезмәтләренә һәм рус елъязмаларына нигезләнеп язган. Шулай да аның «... минем яздыгым нәрсәләргә... рус мөхәррирләренең (тарихчыларының) таянып игътираз (каршылык) итмәүләрен, ... борынгы китапларга таяныбрак игътираз итүләрен үтенәмен» дигән сүзләре ташка басылып калган. Гәүһәршад ханәкәнең язмышы, чоры Мәскәү-Казан мөнәсәбәтләре кебек үк катлаулы, әлбәттә.

Роман авторының да рус телендәге чыганаклардан гына файдалана алганлыгын истә тоту кирәк. Калганы – укучыбыз хөкемендә. Сезгә фәнни хезмәт түгел, әдәби әсәр генә тәкъдим ителгәнен онытмасагыз иде.

Мөдәррис Вәлиев

...Тәрәзә тышында ак чебен кебек вак кына кар оча башлады. Иң элек әле ул бер төштә генә, туң кергән җиргә, аны суыктан сакларга теләгәндәй, юка җәймә булып ятты. Ә аннары җил күтәрелде, кар да, усалланып, чәнечкеле коры ярма сыман, түбәләргә, тәрәзәләргә шакырга тотынды. Төш җитеп килүгә карамастан, мондый көнне урамда халык күренмәде. Ашыгыч эшләр белән берәр җайдак очып үтсә, яисә бүреге белән кар-бураннан ышыкланып, һөнәрче үз остаханәсенә ашыгып узса гына.

Нурсолтан вәлидә сагышлы күренештән күзен аерып ала алмады. Менә аның алдында зарыгып көтелгән Казан сузылып китте. Күзләре иң элек инә кебек тырпаеп,

очларына кургаштай күк йөзе эләгеп торган манаралары белән җәмигъ мәчетне таныды. Кайчандыр Хәлил солтан кул астында төзелгән суфиханәне дулкынланып исенә төшерде ул. Шул чакларда Нурсолтан беренче иренең гел янәшәсендә булды, Аллаһ ризалыгы өчен корыласы бу бина турында Хәлил кадәр башка беркем дә кайгыртканы юк иде. Ул осталарны җыйды, аларның эшен карап-күзәтеп торды, җитешмәгән бөтен төшен төзәттереп барды. Хан китапханәсе дә элеккеге Казан ханбикәсе турында истәлек булып калды. Аның тырышлыгы белән тупланган китаплар бүген дә кыйммәтле хәзинә булып саклана. Нурсолтан гөмбәзле түшәмнәре, бизәк төшерелгән диварлары белән матур бу залда элеккеге саклаучы хезмәткәрне күреп сөенде. Ул Казаннан киткәндә, Муса ага әле көче ташып торган ир уртасы иде, хәзер исә вәлидәне узган еллар авырлыгы астында инде бөкрәя төшкән карт каршы алды. Әмма ул, элеккечә үк, ханбикә Нурсолтан бу хәзинәне аның кулына ышанып тапшырган вакыттан ук, кайсы сандыкта нинди китап сакланганын хәтерли икән. Хан сараендагы һәр почмак, биек аяклы зур бакыр кәндилләр белән генә яктыртылган киң галереялардан башлап ярым караңгы керү-чыгу юлларына кадәр вәлидәнең исендә тора. Сарай да аны онытмаган әле. Нурсолтан карт диварларга кагылып алганда, таш, җылынып киткәндәй булып, аңа җавап кайтара, ханша әле яшь, матур чагында, артыннан очып барган япмасы белән шул диварларга тияр-тимәс кенә коридорлар буйлап узган ерак еллар шәүләсен күз алдына бастыра. Казанда аның нечкә күңелле, бәхетсез хәләл җефете – Хәлил хан, аннан соң икенче ире – барысын аягүрә бастырып тотарга яраткан мәрхәмәтсез Ибраһим хакимлек иткән заманнар иде ул. Аларның сөякләре сарайдан ерак түгел генә дүртпочмаклы төрбә эчендә ята. Таш бизәкләр чигелгән түбә, гаять зур затлы түбәтәй кебек, Казан хакимнәренең соңгы сыену урынын җилдән, явым-төшемнән, кояш кыздыруыннан каплап тора. Бу «түбәтәй»не шундый хәлгә китерүдә бизәк уючы осталарның әллә ничә буыны тир түккән. Казанлылар белән бергә, корал көченә буйсынып әсирлеккә төшеп, хан остаханәсенә китерелгән чит ил таш уючыларының кул җылысы да калган монда.

Олы улының пайтәхеттә гүзәл биналарны торгызырга омтылуы сөендерде Нурсолтанны. Мөхәммәдәмин хан бөтен Җир шарыннан иң яхшы мигъмарларны җыярга ашыкты. Идарәчеләрен тоткыннар, коллар базарына ай кебек йөзле кызлар түгел, ә атаклы ташчылар, булдыклы балта осталары, уеп бизәк төшерүчеләр, төзүче-мигъмарлар табып кайтырга җибәрде. Казан хакименең тырышлыгы белән кала үзәгеннән, кирмәннән читтәрәк – Кабан күле буенда Кече Сарай үсеп чыкты. Аның пөхтә-бизәкле итеп эшләнгән корылмалары бакчада юеш, кара ботаклары гына тырпаеп торган шәрә агачлар, җир дә әле кара һәм игътибарны җәлеп итмәслек бу көннәрдә Кырым вәлидәсенең карашын иркәләде. Мөхәммәдәминнең сарае исә аңа Хәлил ханны озатып йөргән яраннарны хәтерләтте. Олы улы үз тирәсенә шагыйрьләрне, көйчеләрне, оста рәссамнарны, каләмнәре белән могҗизага тиң гаҗәеп матур китаплар төзүче хаттатларны туплады. Казанда мәдрәсәләр чәчәк атты, аларның диварларына сыену, гыйлем орлыкларын эстәү максаты белән, бөтен ханлыктан гына түгел, ерак олыслардан һәм чит илләрдән шәкертләр җыелды. Бөтен Казан ханлыгы буйлап суфичылык җәмгыятьләре үсеш алды. Атаклы суфилар зур авылларга, даруга үзәге булган калаларга килеп урнашты, һәркайда үз мәктәпләрен ачты.

Нурсолтан Казанга килгәннең беренче көнендә үк олы улы әнисенә бөтен гарәп дөньясында танылган җыр остасы Голәм Шади Гудины җибәргән. Мөхәммәдәмин ягымлы тавышлы җырчыны, әниемә нечкә шигъри күңелемне ача торган ихтирамлы сүзләремне тапшыр, дип озатып калган.

– Вәлидә, бүләгемне кабул итеп алыгыз. Көй вә җыр кайберәүләр өчен бары тик эссеседә салкынча һава белән тәнне җилләтүче җилпәзә генә, башкаларга ул – җан азы-

гы. Ә сезгә, кадерле әнием, бу бүләгем күңелегездән сагыш һәм сызлануларны куып чыгара торган дару-дәва булсын, – дигән ул.

Тиңдәшсез сандугач кебек дан алган әлеге җырчы бәя биреп бетергесез бүләк булып чыкты. Голәм Шади Гуди Нурсолтан вәлидәне ул Казан ханлыгы башкаласында яшәгән озын кыш буена тылсымлы көй-моңнары белән юатты, күңелен күрде. Йөрәгенең тирән яшерелгән тагын бер ярасы – үзсүзле кызы турында онытып торырга ярдәм итте. Гәүһәршад әнисе белән күрешергә дә теләмәде. Аерылып торуга түзә алмыйча, йә Нурсолтан үзе килеп чыгар, дип курыккандай, ул иң ерактагы биләмәләрнең берсенә качып киткән, дигән сүзләр килеп иреште. Сагышын белгертәсе килмәсә дә, вәлидә улыннан Гәүһәршад турында сорашты, тегесе теләмичә генә җавап кайтарды. Соңгы елларда ханның сеңлесе белән мөнәсәбәтләрен читләшү һәм аңлаша алмау бозлары каплап киткән иде. Тол калган ханәкәнең иреккә чыгып, теләсә ни кылануын, тәртипле мөселман хатынына хас булмаган сыйфатларын Мөхәммәдәмингә җиткерделәр, әлбәттә. Гәүһәршадның ябык капкалар артындагы биләмәләрендә күңеленең ерак почмакларында тагын әллә ниләр яшерелгән булуын ул тоеп-чамалап яши иде. Тәкәббер һәм хәйләкәр ханәкәнең, мәкерле ятьмәләр кору һәм үз кул астындагыларның язмышын ничек тели – шулай бору өчен туган хатынның кара уйлар, начар ниятләр белән яшәве дә гаҗәп түгел. Киләчәктә шундый хәлләр булуын күз алдына китерсә дә, хаким сеңлесенең кыланмышларын белмәмешкә салыша, бары тик кайчандыр Гәүһәршадны яңадан кияүгә бирмәскә дигән вәгъдәсенә генә үкенә. Әгәр аны үзенә тугрылыклы берәр әмиргә кәләш иткән булса, ханәкәнең азынуына ире кайгырыр иде. Ә хәзер ханәкәне пайтәхеткә килергә һәм аналарының аягына егылырга ничек мәҗбүр итәсен үзе дә аңламый. Кораллы сакчыларын өсләтеп, Гәүһәршадны ханлыкның бөтен җирләре аша сөйрәп китереп булмый ләбаса!

Ә хәзергә, Кырым вәлидәсен авыр уйларыннан коткару өчен, хаким аның хөрмәтенә төрле мәҗлесләр, ауга чыгулар һәм исәпсез-хисапсыз күңел ачулар оештыра. Мөхәммәдәмин үзе белән кадерле кунагын – Кырым солтаны Сәхибгәрәйне дә ияртеп йөри. Анысы үзенең ихтирамлы мөнәсәбәте, әдәплелеге, тышкы матур кыяфәте, җиңел холкы белән ханның күңелен яулауга ирешкән. Кырык яшьлек хаким ат өстендә, аягына өзәңге киеп, кулына йөгән тотып туган кебек, шундый килештереп, оста итеп утыручы яшь солтанның буй-сынына сиздермичә генә сокланып карый. Ау эшендә төз атуына, атта йөргәндә җитезлегенә таң кала. Җыр-моң дигәндә дә Мөхәммәдәминнең ис-акылын китәрә ул. Сәхибгәрәй шөлдерле барабанда да, курайда да яхшы уйный икән. Күңелле җырлары белән ханның һәм аның кунакларының күңелен күтәрә белә, бөтен татар ханлыкларының бишегеннән – Алтын Урданың үзеннән үк килүче хәсрәтле көйләре белән күзләрдән яшь чыгара. Аһ, Сәхибгәрәйне күрү белән, Мөхәммәдәминнең үзәге өзелеп, йөрәге ничек сыкрап куя! Ходай аны бала сөю бәхетеннән мәхрүм иткән. Ханның шундый матур, җитез һәм сөйләшүе күңелгә бәлзәм булып ятарлык улы булса иде! Аның бөтен хатыннарын һәм җарияләрен үрчемсезлек чире суккан кебек булды шул. Алар аның хәрәмханәсендә яз көне чәчәк атучы куак-агачлар сыман күз явын алырлык матур киемнәр киеп, гүзәл затлар булып яшиләр дә бит. Әмма җәй җиткәч, әлеге чәчәкләр коела да төшә, ханның шушы аллы-гөлле бакчасы тилмереп көтелгән җимешне бирми. Халыкта уңышлы яулары, таң калдыргыч җиңүләре белән дан казанган, Олуг Мөхәммәд бабасы тәхетенең бөеклеген кабат тергезгән Казан идарәчесенә күпме әрнү һәм ачыну китергән язмыш бу! Якты дөньядан һичнинди җанлы эз калдырмый, нәсел җебен өзеп китү ихтималы аның башына куркыныч төш кебек керә. Тик бу төштән уяну әмәле генә юк. Авырту-әрнүен басар өчен, хаким бөтен көчен, дәртен яңа биналар торгызуга багышлады. Гүзәллекне күрә-таный белгән хан кул астында гаҗәеп

Мөхәммәдәмин хан.
Рушан Шәмсетдинов рәсеме

мәчетләр, тыйнак мәдрәсәләр һәм суфиханәләр, шәптән-шәбрәк биләмәләр төзелде. Хан сарае хаммам-мунчалар, салават күпередәй су бөркеп торучы фонтаннар, кечкенә күлләр, бакча почмаклары һәм уңайлы утыргычлар белән бизәлде. Мөхәммәдәмин башка мавыгуларын да гамәлгә ашырды. Аның илһамлы каләменнән гүзәл туган як киңлекләрен – болын һәм басуларын данлаган, урман һәм куәтле елга-дәрьяларының матурлыгын сурәтләгән робагыйлар вә касыйдәләр туып тора. Һәм Казан хакиме шуңа күрә үзенең кул астындагыларга:

– Һәр каләм иясе кайчан да булса Ходай каршысына юл тота. Әмма аның кулы язган һәммә нәрсә – мәңгелек! – диярргә ярата.

***

Ә вәлидә кызы турында уйлап сагышланды. Ул бу сәфәргә озак еллар әзерләнде, балалары белән күрешер өчен Казанга кайтып килергә, ниһаять, ире Миңлегәрәй ханны да күндерде. Кырым хакиме һәрвакыт кашларын җыера, төрле сылтау таба, юк-

бар сәбәп белән, туры җавaптан кача килде. Әгәр Мәскәү белән Казанга сөйләшүләр алып бару өчен акыллы һәм йогынтылы кеше кирәк булмаса, Нурсолтан гомердә дә балаларын һәм бу җирләрне кабат күрә алмас иде. Менә, ниһаять, ананың хыяллары тормышка ашты: улы Садыйкны кочаклый алды, Мөхәммәдәминнең күкрәгенә сыенды, тик кызы гына башкалада булып чыкмады. Ул бит Гәүһәршадны әтисенең үлеме белән башланган кайгылы көнне шушы сарайда, бетмәс-төкәнмәс газаплар һәм ут эчендә янулар кичергән хәлдә тапты. Анасын гомер буена газапларга саласы бердәнбер кыз баласы дөньяга килде. Әйтерсең җан әрнеткеч кайгылар, җәфа чигүләр беркая да китмәгән, шушында төзәлмәс яра булып кына калган кебек иде. Вәлидә, үзенә Ходай язган мәшәкатьләргә муеныннан чумып, ул көннәрне онытырга өйрәнде, бөек эшләр, омтылышлар арасында бу әрнүле югалтуын читкә куеп торырга тырышты, бөтен кешедән, хәтта үз-үзеннән яшерде. Тик хәсрәте аңа карап кына эреп югалмады...

Кырым вәлидәсенең Казанны калдырып китәсе килмәде, әмма рәхимсез вакыт дигән нәрсә юлга кузгалыр сәгатьне ашыктыра торды. Хәзер, гомер кояшы баеп барганда, Нурсолтан үзенең биредә никадәр бәхетле булганын бөтен тулылыгы белән аңлады! Хәлил хатыны булып яшәгән көннәре тормышының иң якты һәм бер борчусыз чаклары булган икән. Ул ханның соңгы тынычлык тапкан урынына кат-кат барды. Казан ханнары төрбәсе, мәһабәт Хан-Җәмигъ гөмбәзе астында оя корган кошларның сирәк кенә пырылдап очкан тавышын исәпкә алмаганда, аны һәрвакыт тирән тынлык белән каршылый. Нурсолтан кабер ташлары каршында озын-озак өнсез калып тора. Оста ташъязарларның кул җылысын саклаган бизәкләрне учы белән сыпыра. Ханнарның нindидер хикмәтле хәрефләрдән уелган исемнәрен кыйммәтле ташлар – кан төсендәге кызыл якут, яшел зөбәрҗәт, куе зәңгәр якут, алтын сыман топаз яктыртып тора. Әмма таш плитәләр астында яткан ханнарга инде бу ялтыравыклар хаҗәт түгел. Аларның күңелен алтын парчадан, бәрхеттән энҗеләр, матур чигешләр белән тегелгән япмалар да кузгата алмый. Дөньялыкта калган фикер килешмәүләр, үзара юл куешмаулар булмаган да кебек, алар хәзер бер-берсе белән янәшә тыныч кына йоклыйлар. Нурсолтан, астында Ибраһим җәсәде яткан плитә янында тынып, аның белән сүзсез әңгәмә корып алды: «Кадерле ирем, галәмнең үзе кебек мәңгелек һәм гаҗәеп зур тоелган мәхәббәт йөрәгемә шушы салкын, авыр таш плитә шикелле ятар, дип уйладыммы икән мин? Безнең бәхет чәчәк атсын өчен кирәкле ут юк иде, күңелемне җылытмадың шул. Миңлегәрәйне яратуым да җилдә таралган төтен, диңгез суында эзсез югалган кыйммәтле шәраб шикелле эреп бетте, суынды. Сөю китте, сагыш кына калды. Туган өемне, Казанымны, балаларымны сагыну ул. Бердәнбер кызым әнисен йөрәгенә якын китермәгәнгә әрнү калды. Аһ! Ибраһим, әгәр арабыздагы өстебезгә басып торган аңлаша алмау болытлары таралса, Гәүһәршадны күкрәгемә кысып, аның хәсрәтләрен үземә алыр идем! Ләкин кызыбыз, синең шикелле үк, кире һәм башбирмәс булып чыкты, бөек хан! Ул коеп куйган син инде, Ибраһим...»

Вәлидә Хан-Җәмигътан чыкканда, күңелен тирән бер тынычлык биләп алды. Никах җепләре бәйләп торган һәм инде күптән бу дөньядан кичкән кешеләр, аны тыңлап торгач, хаталарын кичергән, каушап калуын һәм сагышлануының сәбәбен аңлаган кебек тоелды. Бу ак ташлы мәһабәт төрбә шикелле, алар тын гына тыңлады, ул мәрхүмнәр белән сөйләшә, аларны тыңлый алды.

Дәвамы бар ■

Ризаэддин Фәхреддин *гыйбарәләре*

• Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр.

• Гыйлем вә тәрбия орлыкларын хәзер ихлас мәхәббәт илә чәчсәгез, киләчәктә файдалы җимешләрне дә үзегез җыярсыз.

• Бала тәрбиясе хакында булган хезмәтләрнең иң бөеге – аналар өстендәдер.

• Адәм баласы үзен-үзе тәрбияләргә һәм камилләштерергә тиеш, буй җиткән һәр кеше үзен-үзе тәрбияли ала.

• Дөньяда алтын булырлык кешеләрнең күбесе, кирәк булган тәрбия күрә алмыйча, туфрак булып җирдә калалар.

• Билгеле бер вакыты җитмичә, алдан йөк тартып, атын имгәтеп эштән чыгару кебек, вакыты җитмәстән сабак укыту да баланы имгәтеп калдыра.

• Милләтләрнең әсирлекләренә, бетүләренә сәбәп булуның иң көчлесе – наданлыктыр.

• Әдип вә галимнәре булмаган кавем – бәхетсез, мәшһүр кемсәләрен оныткан халык – көчсез, әдәбияты булмаган милләт – рухсыз.

• Әхлак белән әдәбият бергә булырлар. Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса, әхлагы да шул рәвештә булыр.

• Мәшһүр кешеләрнең яки халык вә мәмләкәтләрнең гомер итүләрен, тереклек итү рәвешләрен сөйләгән гыйлемгә «тарих гыйлеме» диләр.

• Балаларыгызны үзегез яшәгән заманга һәм башка заман өчен дә яраклы итеп укытыгыз.

• Бер милләт һәм кавемнең тәрәккыяте дә уку, һөнәр һәм сәнәгать белүгә бәйле.

• Тырышлык – акыл вә фикергә, шулай ук тән һәм әгъзаларга зарар китермәс рәвештә тырышу.

• Бәхет – гаиләсе эчендә рәхәт гомер итүдән гыйбарәт булып, гаилә эчендә рәхәт күрмәгән бер кеше гаилә тышында рәхәт күрә белмәс.

• Ата вә анагызны, якын кардәшегезне ничек сөйсәгез – милләтегезне шулай сөегез, милләтегез өчен хезмәт итүне җаныгызга зур табыш дип санагыз.

• Артыгызда гүзәл бер исем калдырыр өчен тырышыгыз. Чөнки адәм баласы вафат булыр, ләкин гүзәл исеме вафат булмас, мәңге калыр.

• Хатын – фәкыйрьлеккә каршы бер гаскәрдер: ватаны – өй, хәрби ныгытмасы – тырышлык, хәрби фәне – йорт белән идарә итү, коралы – энә белән кайчыдыр.

• Гыйффәт – падишаһлыктан да зур камиллектер. Гыйффәттән өстен дөньяда бер камиллек тә булмас.

• Гыйффәтле кыз, бик күркәм һәм гүзәл булмаса да, ләкин бик тәрбияле, кешелекле, камил, мөлаем, мәхәббәтле, дип мактауга лаек булыр. Кешеләрнең тормыш-яшәү рәвешендә бу эшләр, бер кагыйдә шикелле, асылда, беркайчан да үзгәрми.

Диләрә Гыймранова *әзерләде.* ■

Безнең мирас №7 июль 2018

Казан ханлыгының язмышы

Булат Хәмидуллин

Казан ханнары төрбәсе. Казан Кремле

Күренекле тарихчы М.Г.Худяков, «Казан ханлыгы тарихыннан очерклар» дип исемләнгән китабында, Олуг Мөхәммәд хан варисларыннан соң Казан тәхетен биләгән кырымлы Гәрәй ханнар нәселе вәкилләре идарә иткән чорны «милли яңарыш чоры дияргә мөмкин», дип бәяләгән иде. Утыз биш елга сузылган әлеге кыска вакытны шулай ук Казан ханлыгы язмышы хәл ителгән иң фаҗигале чор дип тә атый алабыз, чөнки Казан ханлыгын нигезләүдә катнашкан Олуг Мөхәммәд хан варисларыннан соң, төрле тарафлардан китерелгән килмешәк ханнар белән җирле ыруг вәкилләренең бердәм эш йөртмәүләре нәтиҗәсендә ханлык әкренләп көчсезләнә барган. Хәер, М.Г.Худяков та шул ук хезмәтендә Сафагәрәй хан идарә иткән соңгы елларны тотрыксызлык чорына тиңли. Ул әлеге вакыт аралыгында ханлыктагы идарәче төркем нигездә кырымлы бәк-морзалардан гына торган, җирле аксөякләр идарәдән читләштерелгән, дигән фикерне алга сөрә, «хөкүмәт җирле халыкка таянмаган», дип яза. Димәк, ханлыкның үз кешеләре, бәк һәм морзалары ил язмышы өчен җаваплылыктан читләштерелгәнлектән, дәүләттә

тотрыклылыкка ирешү мөмкин дә булмаган, дип әйтергә тиешбез. Шулай да кырымлы Гәрәй ханнар Казанда идарә итә башлаган елларны шуңа омтылыш чоры буларак бәяләргә урын бар.

* * *

Алтын Урда империясенең таркалу елларында, ягъни XV гасыр урталарында берничә төрки-татар дәүләте барлыкка килә. Мөстәкыйльлеккә омтылган яңа татар ханлыклары арасында беренчелекне Кырым ханлыгы били. Аның идарәчеләре Алтын Урдадан чыккан Хаҗигәрәй хан нәселе вәкилләре – Гәрәй ханнар була. Хаҗигәрәй әүвәл Барын белән Ширин ыруглары башлыклары ярдәмендә Алтын Урданың Кырым олысына хан итеп билгеләнә һәм 1440 нчы елларда әкренләп үз олысын мөстәкыйль дәүләт рәвешенә китерүгә ирешә. Аның тәхеттә утыру вакыты дип 1441-1466 еллар күрсәтелә. Шул рәвешле элекке Кырым олысына буйсынган җирләрдә, Кырым ярымутравы белән Кара диңгезнең төньягындагы далаларда мөстәкыйль Кырым ханлыгы барлыкка килә. Аның үрнәгендә соңрак Казан, Әстерхан ханлыклары, Нугай Урдасы да оеша. Ширин ыругыннан чыккан Мөхәммәд Хөсәен улы тарафыннан 1298 елда нигезләнгән Мишәр йорты (Мещерский юрт) олысы җирлегендә (элекке Рязань белән Мәскәү кенәзлекләре чигендә) шул ук XV йөз урталарында Касыйм ханлыгы да барлыкка килә. Әмма әлеге ханлык оешкан көннәрдән үк диярлек аның идарәчеләре Мәскәү кенәзлеге йогынтысында була.

Төрле вакытта бу дәүләт-ханлыкларның берничәсендә Хаҗигәрәй хан нәселе вәкилләре идарә иткән. Мәсәлән, Әстерхан ханлыгы тәхетендә – Баһадур Гәрәй хан, Касыйм ханлыгы тәхетендә – Нурдәүләт Хаҗигәрәй улы (1486-1491) һәм аның варислары Сатылган (?-1506) белән Җанай (1508-1512) ханнар утырган. Кырымнан кала, Гәрәй ханнар нәселе вәкилләренең иң озак идарә иткән урыны, мөгаен, Казан ханлыгыдыр. Аның тәхетен алар чирек гасырдан артыграк вакыт биләгәннәр.

Алтын Урда дәүләте таралганнан соң оешкан күпчелек дәүләтләрдә тәхет биләү тәртибе Чыңгыз хан заманында хөкем сөргән кануннар һәм традицияләр буенча дәвам иттерелгән. Хан титулын йөрткән хөкемдар фәкать элекке ханнар нәселеннән генә тәгаенләнергә тиеш булган. Шул сәбәпле, мөстәкыйль бер дәүләт белән идарә иткән хан тәхетенә еш кына балигъ булмаган затлар да утыртылган. Ә Нугай Урдасында идарәче бәк тәхетенә үз ыруг башлыклары – морзалар гына сайланган. Анда тәхет биләү тәртибе үзгә булган. Чыңгыз хан керткән борынгы тәртипкә тугрылыклы булып калырга омтылу исә Казан ханлыгы өчен аянычлы тәмамланган. Үз дәүләте белән мөстәкыйль рәвештә идарә итәрдәй җирле ыруглар башлыклары – шул ук Ширин ыругыннан чыккан бәкләр һәм морзалар тәхет биләүдән читләштерелгәннәр. Читтән китерелгән яшүсмер ханнар исә алар белән уртак тел таба алмаганнар.

ТАРКАУЛЫКНЫҢ БАШЛАНУЫ

Казан ханлыгы оешып, Олуг Мөхәммәд хан нәселе идарә итә башлаудан сиксәнтуксан еллар чамасы вакыт узгач, әлеге дәүләт тәхетенә дә кырымлы Хаҗигәрәй хан нәселе вәкилләре чакырып китерелә. Иң әүвәл ханлык белән өч ел чамасы (1521-1524) Кырым ханы Миңлегәрәйнең улы, Хаҗигәрәй хан оныгы Сәхибгәрәй (1501-1551) идарә итә. Аннары ул тәхетне якын туганының улына – яшүсмер Сафагәрәйгә калдырып китә. Кайбер тарихчылар, шул исәптән М.Г.Худяков та, Сафаны 1507 елда туган, 42 яшендә вафат булган дип исәпли. Башка язмаларда исә ул 1510 елда туган, Казан тәхетенә тәгаенләнгәндә аңа 13 яшь булган дип күрсәтелә.

Сафагәрәй ханлыкта чирек гасыр чамасы идарә итә (1524-1549). Дөрес, шул чор-

XVI гасырның беренче яртысындагы садак – җәя һәм ук савыты. Казан Кремлендәге казу эшләре вакытындагы табыш нигезендә Н.Х.Кумысникова реконструкциясе. 2006 ел

да аны ике мәртәбә Казаннан куып та җибәрәләр, нәтиҗәдә, ул яу белән килеп, тәхетне сугышып алырга мәҗбүр була. Әлеге ханның вакытсыз һәм серле үлеменнән соң, тәхеткә аның ике яшьлек улы Үтәмешгәрәй тәгаенләнә. Кайбер елъязмачылар ул 1546 елда, икенчеләре исә бер елга соңрак туган дип исәпли. Үтәмешгәрәй Казан ханлыгы тәхетен ике ел чамасы биләгән (1549-1551) дип санала. Егерме яшендә ул, ярым тоткын хәлендә, Мәскәүдә вафат була. Бала чагында ук Александр исеме белән чукындырылган әлеге затны, хан нәселеннән булуын истә тотып, «патша нәселе әгъзалары янәшәсендә, Мәскәүнең Архангель соборы гүрстанында җирлиләр».

Сәхибгәрәй Кырымда Миңлегәрәй хан гаиләсендә туган һәм егерме яшенәчә шунда гомер иткән. Ун яшендә, 1510-1511 елларда ул үги анасы, элекке Казан ханбикәсе Нурсолтан белән Мәскәү һәм Казан калаларында булып кайта. (Нугай Урдасында туган Нурсолтан башта Казан ханы Хәлилгә ярәшелә. Ул вафат булгач, шул заман йоласы һәм тәртибе кушканча, аның энесе Ибраһимга кияүгә бирелә. Ул да үлгәч, аны Кырым ханы Миңлегәрәй икенче хатынлыкка ала.) Нурсолтанның бу сәяхәте Мәскәү белән Кырым һәм Казан арасындагы кайбер каршылыкларны бетерергә тырышу ниятеннән оештырылган дипломатик сәфәр санала. Ибраһим хан белән әлеге ханбикәнең кече улы, 1496-1502 еллар аралыгында Казан ханлыгы тәхетен биләгән Габделлатыйф Мәскәү кенәзе тарафыннан тәхеттән төшерелгән һәм сөргенгә җибәрелгән була. Кырым ханы Миңлегәрәй белән ханбикә аны сөргеннән азат итү, Мәскәүгә якынрак бер шәһәргә кайтару турында башта бөек кенәз белән хат язышалар. М.Г.Худяков, Нурсолтан бикә Мәскәүдә Бөек кенәз Василий III нче белән очрашып сөйләшкәч, Габделлатыйф «баш кенәз белән тигез хокукка ия исәпләнеп, Кашира шәһәре кенәзе итеп билгеләнә», дип яза. Ханбикә, Мәскәүдән соң, Казан тәхетендә утырган өлкән улы Мөхәммәдәмин янына китә. Аның бу сәфәре Кырым, Мәскәү һәм Казан арасында үзара килешү төзү белән тәмамлана. Бу килешүләр вакытында Нурсолтанның кече улы Габделлатыйф та катнаша һәм уңай нәтиҗәгә ирешүгә булышлык итә, дип язалар. Казанның булачак ханы, ун яшьлек Сәхибгәрәй исә, бу вакыйгаларның шаһиты сыйфатында, Нурсолтанга ияреп йөри.

Олуг Мөхәммәд хан нәселеннән соңгы хан буларак Казан тәхетен биләгән Мөхәммәдәмин Ибраһим улы 1518 елның декабрь ае ахырында дөнья куя. Аңарчы, 1516 елда ул бөек кенәз Василий III нчегә Габделлатыйфны Казанга кайтаруын үтенеп хат юллый. Әмма ул вакыйга Габделлатыйфның 1517 елгы «очраклы» үлеме белән тәмамлана. Икесенең дә тәхет биләрдәй ир балалары калмый. Икенче анадан туган агалары Ходайкол углан күптән инде Мәскәүгә күчкән, башка дин кабул итеп, «кенәз Пётр»га әверелгән була. Шул сәбәпле, Казан тәхете язмышы Мәскәүдә хәл ителә. Василий III теләге белән ул урынга Касыйм ханы, яшүсмер Шаһгали билгеләнә.

Хан сараеның нигезе. Казан Кремле

Казанның Мәскәү кенәзлеге белән элемтәдә торган бер төркем бәк-морзалары унөч яшьлек Шаһгали (1506-1567) кандидатурасын кабул итәләр. Ризаэддин Фәхреддин: «Шул хәбәрне җиткерү өчен Мәскәүгә 19 февральдә илче килә», – дип яза. Шаһгали Касыйм ханлыгы тәхетендә атасы Шәех Аллаһиярдан (1512-1516) соң ике ел чамасы, 1516-1519 елларда идарә иткән санала.

Казан бәкләре үсмер ханны тәхеткә утыртып үзләре идарә итәргә ниятлиләр. Әмма Шаһгали чорында ханлык белән асылда Мәскәү кенәзлеге илчесе Федор Карпов идарә итә. Аның үз гаскәри берәмлеге дә була. Казанга билгеләнү алдыннан, Шаһгалине шул илчегә буйсынып эш йөртергә ант иттерәләр. Шул сәбәпле Казан аксөякләре алдында аның абруе булмый. Ике ел ярымлап вакыт үткәч тә, ханлык хөкүмәте (диваны) әгъзалары – бәкләр Шаһгалине тәхеттән төшерү турындагы карарга киләләр.

Ризаэддин Фәхреддиннең «Казан ханнары» хезмәтендә күрсәтелгәнчә, «Мөхәммәдәмин хан үләр алдыннан анасының үги улы Сәхибгәрәйне хан итеп кую турында васыять әйткән» була. Васыять әлеге ике шәхескә дә ана тиешле Нурсолтан ханбикә йогынтысында әйтелгән (яисә язылган) булса кирәк. 1521 елда Шаһгалине куганнан соң, Казан ханлыгы тәхетенә Кырымнан шул 20 яшьлек Сәхибгәрәй чакырып китерелә. Чыганакларда аның Казанга 300 кешелек атлы отряд белән килеп керүе хәбәр ителә. «Ул килгәч, Мәскәүгә йөз тотучы кайбер аксөякләр кулга алына», – дип яза Ризаэддин Фәхреддин. Шаһгали исә үзенең атлылары белән шәһәрдән чыгып кача һәм янә Мәскәүгә китә.

Ә М.Г.Худяковның искә алынган хезмәтендә Кырым хөкүмәте вәкилләренең Сәхибгәрәйне 1516 елда ук Касыйм ханы итәргә омтылулары турында да мәгълүмат бар. Алар үзләренә карата тискәре мөнәсәбәттә торган Шәех Аллаһияр хан нәселенең Касыймда калуына каршы булганнар. Димәк, Шаһгали белән Сәхибгәрәйнең язмыш юллары шулвакытта ук үзара каршылыкка кергән икән. Ләкин Кырымның көчәюен теләмәгән Мәскәү кенәзлеге Миңлегәрәйнең «дустанә» тәкъдимен кабул итмәгән. Шул рәвешле Касыйм ханлыгы тәхетенә Аллаһиярның улы, яшүсмер Шаһгали билгеләнгән.

Шаһгалинең анасы Шаһисолтанның да Нугай Урдасы морзасы Ибраһим кызы булганлыгы М.Г.Худяков хезмәтендә күрсәтеп кителә.

Мәскәү кенәзлегенең тәхеттән куылган Шаһгалине якларга тырышуы ике дәүләт арасында сугыш чыгу куркынычын тудыра. Әмма бу очракта Казан ханлыгының иминлеген Кырым белән Нугай Урдасы көчләренең Мәскәүгә һөҗүме коткара. Кырымның яңа ханы Мөхәммәтгәрәй, башка дус дәүләтләрдән дә гаскәри ярдәм алып, шул ук җәйдә Мәскәү тарафына зур яу оештыра. Ул яуда Сәхибгәрәй дә катнаша. Аның гаскәренең башта Түбән Новгородка һөҗүм иткәнлеге Австрия дипломаты Сигизмунд Герберштейн язмаларында да теркәлгән. Бу яу вакытында Мәскәү кенәзлегенә кергән җирләргә зур зыян китерелә. Күмәк көчләр Мәскәүдән көньяктарак урнашкан Коломна каласы тирәсендә тупланып, кенәзлекнең башкаласына һөҗүм башлыйлар. Тарихчыларның хезмәтләрендә зур яу килүен белгән бөек кенәз Василий III нченең гаскәр туплау сылтавы белән, Мәскәүдән көнбатыш тарафка чыгып китүе икърар ителә. Р.Фәхреддин: «Шәһәрне яклаучылар башлыгы итеп киявен, чукынган Пётрны калдыра. Ул чукынган кияү Ибраһим ханның улы Ходайкол иде», – дип яза. Тарихчы С.М.Соловьев хезмәтләрендә дә бу шәхес «крещённый татарский царевич Пётр» буларак теркәлгән. Ул Василий III нченең сеңлесенә өйләнгән була. Әлеге Пётр һәм боярлар, шундый зур яуга каршы торып булмауны аңлап, Мәскәү халкын ясак түләп котылырга өндиләр. Мәскәүлеләр таләбенә кенәз Василий III нче дә каршы килми, солых килешүенә үз мөһерен сугарга мәҗбүр була. Дәһшәтле яу шул рәвешле 1521 елның 29 июлендә зур бәрелешләрсез һәм күпләп кан коюларсыз тәмамлана, дип язалар. «Мәскәү тарафыннан һәр ел (Кырымга) ясак түләп тору шарты белән солых килешүе имзалана», – дип яза Р.Фәхреддин. Бу вакыйга турында М.Г.Худяков: «Василий III нче кимсетелүле солыхка кул куярга, үзенең Кырым ханына бәйлелеген танырга һәм аңа ясак түләргә мәҗбүр була», – ди. Ул да, башкалар да әлеге җиңүне: «Казан ханлыгының 1487 елдан бирле Мәскәү йогынтысында яшәвеннән котылуы», – дип бәялиләр.

Василийнең атасы, бөек кенәз Иван III нче, ике бертуганның – Илһам хан белән аның энесе Мөхәммәдәминнең тәхет өчен көрәшеннән файдаланып, 1487 елда Казанны яулап алган була. Тәхеткә аңарчы Мәскәү карамагында – Кашира шәһәрендә яшәгән Мөхәммәдәмин углан утыртыла. Аның «киңәшчесе» итеп Мәскәү илчесе һәм гаскәри берәмлек калдырыла. Илһам исә Вологда шәһәренә сөргенгә озатыла. Берникадәр вакыттан соң, ул шунда үлә. «Хатыны, төрки ханлыклар йоласы буенча, Мөхәммәдәмингә хатынлыкка бирелә». Шушы вакыйгалардан соң чирек гасыр узгач, ниһаять, Мәскәүгә баш иеп яшәүгә – «Мәскәү протектораты» тәртибенә чик куела. Казан ханлыгы ирек ала. Казан тарихындагы бу уңышның үзәгендә, әлбәттә, Сәхибгәрәй хан торган дип исәпләнә. Кайбер тарихчыларның хезмәтләрендә ул хан Мәскәүгә баш иеп яшәүгә чик куючы буларак теркәлә.

Р.Фәхреддин язуынча, 1522-1523 еллар кышында Сәхибгәрәй хан, ике ил арасында аерым солых килешүе төзү өчен, Мәскәүгә үз вәкилләрен җибәрә. Ләкин илчеләр уңышка ирешә алмыйча кала. Елъязмачылар хәбәр итүенчә, шул җәйдә Казанда зур халык кузгалышы була. Р.Фәхреддин: «Мөхәммәдгәрәй ханның Әстерханны яулап алуын ишеткәннән соң, Сәхибгәрәй Казанда булган Мәскәү илчесен вә иярченнәрен үтертте», – дип яза. Рус сәүдәгәрләре дә талана, алар һәм Шаһгали белән Казанга килгән кайбер йомышлы татарлар үтерелә. Янәсе, Кырым ханы Мөхәммәдгәрәй Әстерханны алганнан соң Казанга ярдәмгә килмәкче, бергәләп Мәскәүгә яу оештырмакчы булган икән. Ләкин шул ук 1523 елда Мөхәммәдгәрәй хан үзе дә үтерелә. Кырым ханлыгы тәхете бушап кала.

Дәвамы бар ■

КЕРӘШЕННӘРДӘ «ИМНӘҮ», СИХЕР ҺӘМ КҮРӘЗӘЛЕК

Радик Исхаков

Атаклы совет этнографы С.А.Токарев фикеренчә, имнәү яки имләү – кешелек тарихының бишегеннән үк формалашып, гасырлар дәвамында бик аз гына үзгәргән сакраль, ягъни изге дип саналган гореф-гадәт. Иҗтимагый үсешнең нинди баскычында булуга да карамастан, бу әйбер дөньяның бар халкына да хас. Керәшеннәрдә имче (күрәзәче, күремче, имче, багучы, тел белүче) борынгы дини йолалар белән тыгыз бәйләнештә. Этнографик әдәбиятта аларның җәмгыятьтә шактый өстенлеккә ия булганлыгы турында язалар. Авыл халкы имче карчыкларны хөрмәт иткән, киңәшләрен тыңлаган һәм күрсәтмәләрен карусыз үтәргә тырышкан. Кеше гадәттә имченең хезмәтенә авырып киткәндә, бәхетсезлек очрагында яки нинди дә булса яшерен мәгълүматны белергә теләп мөрәҗәгать иткән. Һәр очрак өчен дә имченең өшкерү, әфсен сүзләре булган. Әлеге сүзләрне әйтү төрле йола һәм аерым ритмика белән башкарылган. Бу очракта имченең сөйләмендә метафора, гипербола, аллегория кебек сәнгати алымнар чагылыш тапкан.

Янсуар авылы керәшеннәре чиркәү алдында. Лаеш өязе

[1] Хөрмәтле укучылар! Мәкаләдә китерелгән мисалларга тарихи, мәдәни мирас һәм кешелекнең рухи үсешендәге бер этап кына буларак каравыгызны, алар белән гамәл кылмавыгызны һәм кылырга да омтылмавыгызны үтенәбез. Сихер, күрәзәлек кебек нәрсәләрнең ислам һәм христиан динендә кичерелмәслек олы гөнаһ икәнен онытмыйк.

Һәр чир, сырхау гайре табигый дөньяның ниндер бер абстракт көче дип күзалланган. Ул, кешенең тәненә үтеп кереп, сырхау-сызлану барлыкка китерә. Шулай итеп, имченең вазыйфасы – хастаның тәненнән авыру китереп чыгара торган явыз рухны куып чыгару һәм кешене дәвалау. Имчеләр, гайре табигый көчкә ия булып, рухлар белән аралаша алганнар. Башка дөнья, андагылар белән гаять серле бәйләнештә билегеле бер йолаларны башкаруы аның явыз рухларны җиңүенә сәбәпче булган.

Керәшен имчеләр тарафыннан башкарыла торган имнәү (керәшеннәрдә шулай әйтелә), әфсен уку һәм аңа бәйле йолалар этнографларда зур кызыксыну уята. Аларның бу гамәлен 1870 елда православие миссионеры һәм этнографы И.Софийский җентекләп язып калдырган. Ул имнәүнең берничә төрен аерып чыгара: *очан имнәү* – эч күбү белән бәйле балалар авыруын дәвалау; *арпа имнәү* – күзгә чыккан арпаны бетерү; *кайрак имнәү* – каты шешне дәвалау; *бизгәк, шом имнәү* – бизгәк тотудан дәвалау, *сызлавык өшкерү* – бетчә-үлектән дәвалау, *кискәнне өшкерү* – киселгән урынны дәвалау; *кот өндәү* – рухи көчне күндерү. Болардан тыш имчеләрнең авыру китереп чыгаручы явыз рухлар белән «эш итә» торган махсус сүзләре – *«авыру теле»* дә булган.

Им-том вакытында төрле предметлардан файдаланганнар. Очан имнәгәндә чабата, күн аяк киеме һәм себерке кулланылган. Имче аларны авырткан урынга билгеле бер тәртип буенча куйган да явыз көчне кууга бәйле имнәү сүзләрен укыганнан соң, бусагага ыргыткан. Инде өченче мәртәбә дә көчле авырту бетмәсә, күн аяк киеме урынына бүлмәдә тотылган тере үрмәкүч куйганнар. Башка предметлардан аермалы буларак, үрмәкүчне бусагага ташламаганнар, ә баланың кендеге өстендә сытып, бөтен тән буенча таратканнар һәм бу вакытта аерым ритмика белән: *«Бу үрмәкүч сытылган һәм үтерелгән кебек, баланың да «очан»ы юкка чыксын! Бу имнәү шифа булсын, очан кайдан килгән, шунда китсен!»* – дип әйткәннәр. Балага кергән явыз рух шуның белән чыгып та киткән. Арпа имнәү вакытында йоланы арпа орлыгы һәм ир-ат яки хатын-кызның эчке киеме – *көнчектән* алынган тукыма белән башкарганнар. Каты шешне исә үткенли торган таш – кайрак белән имнәгәннәр. Имченең бизгәкне дәвалау ысулы да гаять кызык. Моның өчен төрле төстәге тукыма кисәкләреннән курчак ясаганнар. Имче аны хастаның башы тирәли өч мәртәбә әйләндереп: *«Ходай! Аны бизгәгеннән арындыр һәм бу чир курчакка күчсен!»* – дигән. Моннан соң курчакны юл чатына алып барып, шунда ташлап калдырган. Юлда барганда һәм кайтканда имче беркем белән дә сөйләшергә тиеш булмаган. Күз авыруын дәвалаганда күкәй сарысына шикәр кушып махсус «дару» ясаганнар. Таң вакытында имче кояшка таба карап тиешле доганы укыган һәм алдан ясалган «дару»ны авырткан җиргә сылаган. Имнәү-өшкерү вакытында чит-ят предметларга кагылмаганнар. Имче чирне дәвалаганда, аерым сүзләр әйтүдән тыш, авырткан урынга өргән, як-ягына төкергән, төкермәгән очракта да шуңа охшаш гамәл кылган.

Имнәүнең бер төре кешедә рухи көч – кот барлыгына инануга бәйле. Кот барлык төрки халыкларның да мифологиясендә бар. Ул җан турындагы күзаллауларның бер өлеше булып тора. Нидән дә булса бик нык курыкканда яки башка төрле хәл булса, кешенең психик чире башланган. Нәтиҗәдә, ул тынычсызланган, йоклый алмаган, юк кына нәрсәдән дә курыккан, хәлсезләнгән, рухи куәтен югалтып, вафат та булган. Мондый очракта татарлар *«аның коты чыкты»*, диләр. Авыруны савыктыру өчен, котны кире кайтырга күндергәннәр. Имчеләр, котны чакырып, махсус сүзләр әйткән һәм хастаның куенына өргән. Курку гаять көчле булган очракта, бу имнәү берничә – ике, өч, хәтта биш мәртәбә кабатланган.

«Авыру теле», чиргә бәйле махсус сүзләр дигәндә, керәшеннәрнең имнәү вакытында әйтелә торган сүзләре күз уңында тотыла. И.Софийский *«зыяндаш теле»* турында әйтә.

Хәзерге заман керәшеннәрен өйрәнгән Ф.С.Баязитова *«җил теле», «бүсер теле», «ут теле», «елан теле», «кан теле», «арпа теле»* булуы турында яза.

Имнәү йоласын башкарганда барлык керәшен имчеләре өчен дә уртак булган гамәлләр бар. Эшне башлар алдыннан һәр имче Ходайга, Бер Тәңрегә яки Аллага мактау сүзләре әйткән. Уфа губернасы керәшеннәре имнәү алдыннан мөселманча «бисмилла...» укыган. Н.Ф.Катанов мәгълүматларына караганда, биредә яшәүче керәшеннәр имнәү йоласын мөселман күршеләре – татар һәм башкортлардан үзләштергән икән. Моңа аларның: «Бу минем сүзләрем түгел, ә Гайшә һәм Фатыйманыкы», – дип әйтүләре дә дәлил булып тора.

Гайре табигый көче бар дип саналган кайбер предметларны да имнәү вакытында файдаланганнар. Әйтик, артык тирән булмаган җәрәхәтләрне урманда яки басуда табылган, гасырлар дәвамында ташка әйләнгән, озын, очланып киткән агач ботагы – шүрәле бармагы белән дәвалаганнар. Шүрәле рухы бар, дип саналган бу агачны тузан бөртеге халәтенә китергәнче кырып яки уып, яра өстенә сипкәннәр һәм, әлбәттә, эфсен сүзләре әйтеп өшкергәннәр. Бизгәк иясеннән котылу өчен, сырлы таякны төрле төсләр белән чуарлап, аны юл чатына куйганнар. Матур предметны күреп алган бизгәк иясе авыруның тәненнән таякка күчәргә тиеш булган. Үтеп баручыларга юлда торган мондый таякка һич кенә дә кагылырга ярамаган. Югыйсә, бизгәк иясе аңа күчеп, ул да чирли башларга мөмкин икән. Явыз рух – «җылан падишаһы» китереп чыгарган күз авыруын дәвалаганда, күзне елан тиресе белән каплап, махсус эфсен сүзләре әйткәннәр. Аннан соң явыз рух күчкән тирене алып, кеше йөрми торган урынга ташлаганнар.

Яман күздән, явыз рухлардан сакланыр өчен, керәшеннәр бөти – төрле металл предметлар, иске тәңкәләр, атның акыл теше, саескан теле, болан сөяге яки мөгез кисәге тагып йөргәннәр.

Күремчеләрнең эш гамәлләрен өйрәнгәннән соң, аларның шаманчылык белән бик зур уртаклыгы барлыгына инанасың. Бу турыда И.Софийский да: «Болар – борынгы мәҗүсилек (шаманчылык) калдыгы», – дип искәртә. Дөрестән дә, Себер һәм Алтайда яшәүче шаманнар белән керәшен имчеләренең магик һәм ритуал алымнарын чагыштырып карасак, шактый гына охшашлыклар табарга мөмкин. Керәшеннәрдә имнәү йоласы Себер җирле халыкларындагы кебек үк нык үсешкә ирешеп, формалашып бетмәсә дә, аларның традицион дини мәдәниятендә зур урын алган. Керәшен имче-күрәзәчесе эш-гамәлләре белән казакъләрдагы шаман культы башлыгы – *бакса*, чуашлардагы – *йомзя*, удмуртлардагы – *туно*, мукшылардагы *содыцяга* охшаш.

Керәшен сихерчесе – убырлы яки убырлы карчыгының да шаманчылык белән тыгыз бәйләнеше бар. XIX гасырда керәшеннәрдә убыр мифологик образ рәвешенә керсә дә, халык авыз иҗатында сакланып калган мәгълүматлар аларда традицион диннең борынгы формалары турында сөйли. Имчеләрдән аермалы буларак, халык сихерче-убырдан курыккан, мөмкин булганча, аңардан качарга тырышкан. Чөнки алар кешеләрдә яки табигатьтә аңлашылмый торган авырулар, психик чирләр, үләт хафасы, янгын, корылык китереп чыгара, дип санаганнар. Сихерченең гайре табигый көче дә аның күзгә күренми торган дөнья белән тыгыз мөнәсәбәт нәтиҗәсе дип аңлатылган. Гайре табигый куәткә ул шайтан һәм явыз көчләр ярдәмендә ирешкән.

Сихерче махсус йолалар ярдәмендә җанвар яки кош рәвешенә керә ала, дип ышанганнар. Дөрес, православие идеологиясе тәэсирендә аларның бу күзаллаулары шактый үзгәргән, риваятьтәге кара магия белән шөгыльләнүче бер образ төсмере алып, явыз рухка әйләнеп калган. Керәшеннәр арасында кара, кешеләргә зыян сала торган сихер белән шөгыльләнүчеләр турында реаль фактлар һәм мифологик сюжетка корылган

хикәятләр саклана. Аларның берсен өчьеллык Казан керәшен курслары укучысы В.А.Петров үзенең этнографик иншасында язып калдырган: *«Элек безнең авылда сихерче булган. Имеш, ул нәрсәгә дә булса әверелергә теләсә, һәрвакыт мунчага барган һәм сәке аша өч тапкыр сикереп, киемнәрен шунда калдырып чыккан. Хатынының сихерче булуы турында ире белгән, диләр. Хатын дуңгызга әверелгәннән соң, ире мунчадан киемнәрен алган. Берникадәр вакыттан соң хатыны кайткан һәм ире аны шундук үтергән»*.

Яшьләр арасында сөйдергечләр популяр булган. Мәсәлән, аерым ысул белән ясалган бөтнек төнәтмәсе эчертеп, егетнең олтан астына, үкчә турысынарак биш яфраклы тукранбаш та куйсаң, сөйгәнең сине өзелеп яратачак, имеш. Бака сөяге дә иң нәтиҗәле сөйдергечләрдән санала. Сөйдергеч белән башкарыла торган гамәлләр өчен дә махсус әфсен сүзләре бар.

Магик йолаларның берсе – күрәзә кылу яки күрәзәчелек. Гадәттә, авыру вакытта, җан сызланганда яки киләчәкне белер өчен, күрәзәчегә мөрәҗәгать иткәннәр. Күрәзәче дә үз эшендә башка дөнья, андагы рухлар белән элемтәгә кергән һәм кешеләр белми торган серне ача торган предметлар – орчык, көзге, су һәм икмәктән файдаланган. Әгәр дә имнәү вакытында хастаның сәбәбе дөрестән дә гайре табигый көчләрдән икәнен ачыкласа, ул сырхауга авыруның сәбәпчесенә гыйбадәт кылырга, аның урынына яки кирәмәткә барып корбан чалырга кушкан.

Күрәзәлек кылу – Нардуган бәйрәменең дә аерылгысыз өлеше. Нардуган – кояш туган көн, ягъни кышкы кояш торгынлыгы киләчәкне багу өчен иң кулай вакыт. Керәшеннәр фикеренчә, бу көндә матди һәм бакый дөнья бергә кушыла. Билгеле бер шартларда яки кинәт кенә кеше рухлар дөньясына үтеп керә алган. Гайре табигый дөньядагы затлар да, үз чиратларында, матди дөньяга җиңел генә үтеп кергән һәм хакимлек иткән. Шуңа да Нардуганны икенче төрле *«Шайтан туе»* дип тә атаганнар. Нәкъ менә бу бәйрәм төнендә явыз рухларның күмәк көченнән файдалану әлеге чараны шактый үтемле иткән. Гадәттә күрәзәлек эшендә кияүгә чыкмаган кызлар һәм егетләр катнашкан. Йоланы башкарыр өчен алар иң әүвәл буш өй тапкан. Катнашырга килүчеләрдән ике кешене, гадәттә ике егет һәм ике кызны – рекрутларны сайлап алып, аларга балта, чиләк, сөлге, чыра, тәңкә, йөзек һәм себерке тоттырып, якындагы елга яки күл буена җибәргәннәр. Яшьләр тәреләрне, ә кызлар моннан тыш көмеш чулпы-тәңкәләрне дә салырга тиеш булган. Су буена киткәндә: *«Без шайтанга киттек»*, – дип сөйләшкәннәр. Шулай итеп, яшьләр символик рәвештә үзләрен явыз көчләрнең хакимлегенә тапшырган. Бәке янына килеп җиткәч, яшьләр көнбатыштан – көнчыгышка, ягъни кояш батышыннан чыгышына таба бозга балта белән берничә эз (фәкать так санда) салганнар. Моннан соң бозны чабып, чиләкне яртылаш су белән тутырганнар. Бу вакытта багуның беренче акты башкарылган: бозны себереп, өстенә тәңкә ыргытканнар. Аның кайсы ягы белән ятуына карап, алдагы елның ничек буласын белгәннәр. Әгәр дә бөркет икән – ел яхшы, ә инде кире ягы чыкса, начарга юраганнар. Шуннан соң бу тәңкәне йөзек белән чиләктәге суга салганнар да өстен сөлге белән каплап куйганнар. Рекрутлар, төрле җырлар җырлап, кулга яндырылган чыралар тотып, авылга юнәлгән. Чиләкне кызлар фәкать чәнти бармак белән генә күтәреп алып кайткан. Йорттагы кызлар чиләкне идән уртасына куеп, аның тирәли түгәрәк ясап җыелган. Чиләкне ачып, аның төбендәге йөзекнең торышына карап, елның ничек буласын фаразлаганнар. Багу эшен дәвам итү өчен, янә бер мәртәбә кияү куенын күрмәгән чибәркәйне сайлап алганнар. Ул чиләктәге суга салынган башка йөзекләрне дә болгатырга тиеш. Бу йоланы башкарган чакта чиләк сөлге белән капланган һәм махсус җыр башкарылган. Җырга карап, күрәзә кылуда катнашучыларны алданиләр көтә икәнлеге фаразланган. Катнашучыларның санына нисбәтле рәвештә шулай берничә мәртәбә

күрәзәлек кылганнар. Әмма гомуми сан фәкать так булырга тиеш икән.

Мәлки керәшеннәре дә Нардуган бәйрәме вакытында балдак белән күрәзәлек иткән, әмма аларның йолалары берникадәр үзгә. Кияүгә чыкмаган кызлар кич белән буш өйгә җыела. Елгадан су алып менеп, аны зур тазга салып бүлмә уртасына куялар. Күмер кисәге, тукыма, икмәк һәм балавыз салынган суны кызлар чиратлашып болгата. Су тынганда бу предметларның кем каршында тукталуына карап, кызларның киләчәктә бай яки ярлы булачагы һәм ни белән шөгыльләнәчәге (игенче, сәүдәгәр, умартачы һ.б.) ачыклана.

Кайбер керәшеннәр җәйге кояш торгынлыгы вакытында да (20-21 июнь) елга буйларында яки мунчаларда күрәзәлек иткән. Этнограф Н.Одигитриевский Казан губернасы керәшеннәрендә *көзге карау* – көзге ярдәмендә багу; *каз тыны* – каз тавышын тыңлап, киләчәкне фаразлау; *тәрәзә тыны* – тәрәзә төбендәге тавышны тыңлап багу; *тире тыны* – хайваннарның тиресеннән чыккан тавыш ярдәмендә багу; *бастырык тыны* – ишек тери торган бастырыкның тавышыннан күрәзәлек итү булганлыгы турында яза.

Гадәттә кызлар күрәзәлек итәргә яраткан. Ә аларның төп мотивы – кияүгә чыгу-чыкмау мәсьәләсе, ә чыга калса, булачак ярым кем булыр, дигән сорауга җавап эзләү. Мәсәлән, Казан губернасының Казан өязе Апаз авылындагы яшь кызлар тавык куу йоласын бик яратып башкарган. Әгәр дә яшь тавык тота икән – яшь егеткә, ә инде картны эләктерсә, өлкән кешегә кияүгә чыгачагы фаразланган. Шундый ук йола Цивиль өязендәге Иске Корбаш авылы керәшеннәрендә дә булган, әмма алар сарык артыннан куган. Әгәр дә ак төсе күбрәк булган сарыкны тота икән, кияү – чибәр, ә кара төсе күбрәк булса, алай ук түгел, шадра йөзле, кәкре борынлы егет тә эләгергә мөмкин икән.

Башка халыклар кебек үк, керәшеннәр дә кара, ягъни кемгәдер золым сала торган сихер белән дә шөгыльләнгән. Мондый йоланы гадәттә пәнҗешәмбе көнне төнлә яки иртәнге якта кеше һәм малга бозым салу, уңышка зыян китерү максатыннан эшләгәннәр. Ананың үз баласына каһәре аеруча куркыныч. Ана кеше аяз көнне кояш чыгар алдыннан көнчыгышка карап, күктәге изгеләргә мөрәҗәгать итә: *«Кояш анакай! Мин аны үз күкрәк сөтем белән имезеп үстердем, киендердем, ашаттып, назлап-иркәләп үстердем. Ә ул хәзер мине анасы дип тә санламый, мине кимсетә, хәзер мин аңа – ана, ул миңа ул түгел. Аны каһәрлим. Ул мәңге бәхет күрмәсен, йөзе сулсын, ябыксын, ким-хур булсын! Миннән аңа бәхиллек юк. Ходай, син дә аңа хәер-фатихаңны бирмә!»* Аңлашыла ки, бу – ананың балага булган коточкыч явыз теләкләре. Ана каргышын алып, фаҗигале хәлләргә дучар ителгән керәшеннәр дә булган. Мондый каргыш алырга Җирдәге бер генә кешегә дә язмасын!

Шулай итеп, керәшеннәрдә «имнәү», сихер, күрәзәлек кылуның һәм башка магик йолаларның төрле формалары булган. Алар төбе-тамыры белән иң борынгы дини ышануларга тоташкан.

Чыганаклар:

1. **Лукин И.** Этнографический очерк о нравах и жизни татар Казанского уезда Казанской губернии // НА ЧГИГН. Отд.1. Ф. Н.В. Никольского. Д.274. Л.396-397.
2. **Софийский И.** Заговоры и заклинания крещенных татар Казанского края (лекция в Казанском миссионерском приюте) // Отдельный оттиск из ИКЕ за 1878 г. №2. – Казань, 1878.
3. **Катанов Н.Ф.** Народные способы лечения у башкир и крещенных татар Белебеевского уезда Уфимской губернии // ИОАИЭ. – Т.XVI, вып.1. – Казань, 1900.
4. **Катанов Н.Ф.** Отчет о поездке, совершенной летом 1898-го года по поручению историко-филологического факультета Императорского Казанского университета в Уфимскую губернию. – Казань, 1900.
5. **Петров И.В.** Этнографическое сочинение о сохранившихся суевериях и религиозно-мифологических представлениях кряшен (1921 г.) // НА ЧГИГН. Отд.1. Ф. Н.В. Никольского. Д.321. Л.154. ■

Безнең мирас №7 июль 2018

Нагайбәк казаклары: саннары, яшәү урыны һәм үзидарә

Рөстәм Әминов

Нагайбәкләр дип гадәттә Казан яулап алынганнан соң чукынган һәм казнага ясак түләп торган нугай яки Арча ягы татарлары атала. Үзатамалары элегрәк Нагайбәк крепосте тирәсендә яшәгәнлектән килә. Алар XVII гасырның икенче яртысында хәзерге Башкортстан җирләренең көнбатышына күченә һәм башкорт җирләренннән файдаланган өчен оброк түли. Анна Иоановнаның 1736 елгы 11 февраль фәрманы буенча, 1735-1736 еллардагы башкорт восстаниесендә катнашмаганы һәм урыс дәүләтенә тугрылыгы өчен, нагайбәкләр ясактан азат ителә, моңа өстәп, башкортлардан арендага алып торган җирләре үзләренә беркетелеп, барысы да казак сословиесенә күчә. 1842 елның 26 февраль фәрманы нигезендә, Бакалы, Нагайбәк станицаларына караган авыллардан 1250 нагайбәк казагын гаиләләре белән Верхнеуральск өязенә күчерәләр. Нагайбәкләр шунда Париж, Фершампенауз, Кассель, Остроленко, Требия исемле авылларга, соңрак рус казаклары белән бергә Троицк өязендәге Астафьевкага нигез сала. Ә инде 1748 елда Оренбург казак гаскәре оешкач, алар шул гаскәри берәмлек составына кертелә.

1880 елдагы халык санын алу мәгълүматларына караганда, Оренбург казак гаскәре

Беренче Бөтендөнья сугышында катнашучы нагайбәк казаклары. 1914-1918 ел

территориясендә җәмгысы 288778 ир-ат һәм хатын-кыз яшәгән. Шуларның 5,9 меңе, ягъни барлык халыкның 2,04 проценты – нагайбәк. 1890 елда инде нагайбәкләрнең саны 8709 булып, алар гомумхалыкның 2,64 процентын тәшкил итә. Димәк, ун ел эчендә гаскәри нагайбәкләрнең саны 0,6 процентка арткан булып чыга.

1879 елга кадәр империянең казаклары Казак гаскәрләренең баш идарәсенә, 1910 елдан Баш штабның казак бүлегенә буйсына. Оренбург казак гаскәре Казан хәрби округы командирына карый. Гаскәри идарәнең башында Наказной атаман торып, ул бер үк вакытта Оренбург губернаторы вазыйфасын да башкара. Оренбург казак идарәсенең икенче дәрәҗә хәрби-административ системасы булып хәрби отрядлар, соңрак бүлекләр оеша. Беренче бүлекнең үзәге Оренбургта урнашып, аның составына Оренбург һәм Орск өязләрендәге станицалар керә. Икенче бүлекнең идарәсе – Верхнеуральск шәһәрендә, аңа исә Верхнеуральск, Троицк һәм Орск өязләрендә яшәгән казаклар буйсына. Өченче бүлектә Троицк һәм Чиләбе өязләрендәге станицаларда яшәүчеләр хезмәт итә. Һәр бүлекнең башында полковник яки генерал-майор чинындагы атаман торып, алар Оренбург казак гаскәренең Наказной атаманы тарафыннан сайлана һәм Император фәрманы белән раслана.

Нагайбәкләр беренче бүлектә – Оренбург (Ильинская станицасы, Подгорный, Нежинский поселоклары) һәм Орск өязләрендә (Гирьял станицасы, Алабайтал поселогы), икенче бүлектә – Верхнеуральск өязендәге Париж, Кассель, Сарашлы (Остроленко), Требия, Бакалы (Фершампенуаз), Куликово, Астафьевка поселокларында, өченче бүлектә исә Троицк өязендәге Болотово, Краснокаменка, Ключевка-2, Верхнеувельск, Папау (Попово) поселокларында көн күрә.

1902 елда нагайбәкләрнең саны 11900 кеше тәшкил итә. Беренче бүлектәге авылларда – 400 (3,4%), икенчедә – 8900 (7,4%), өченчедә 2600 (21,8%) нагайбәк яши.

Авылларда Россия империясе казак гаскәрләренең иң кечкенә административ бүленеше – поселок һәм хутор идарәләре оеша. Аларның да үз атаманнары һәм төрле мәсьәләләрне хәл итә торган җыены булган. Станица җәмәгате карамагындагы уртак милек дип саналган җир-су урыс чыганакларында юрт, ягъни йорт дип аталган.

1891 елның 3 июнендә кабул ителеп, 1920 елда гына үз көчен югалткан «Станицалардагы казак гаскәрләре белән идарә турындагы нигезнамә» буенча, поселок (хутор) идарәләре хуҗалык саны 60тан артып киткән, станица юртында үз җир биләмәләре булган барлык авылларда да оеша.

Җирле мөһим мәсьәләләр, хәрби хезмәттән азат итү, тәртип бозучыларны җәмәгатьтән читләштерү, караучысыз калганнарга химаячеләр билгеләү, станица атаманы һәм хөкемдарны сайлау, җәмгыятькә яңа кешеләр кабул итү яки аннан чыгару, гаилә милкен бүлү кебек эшләр хутор җыенында хәл ителә.

Станица идарәсе атаман, аның ярдәмчесе, суд, идарә һәм җыеннан гыйбарәт. Станица суды йөз сумга кадәрге гражданлык эшләрен һәм вак-төяк җинаятьләрне карый. Мондый суд һәр станицада да булган һәм аңа 4тән алып 12гә кадәр кеше сайлана. Аннан тыш, вәкилләр саны 3-6 кешедән генә гыйбарәт шәрәфле хөкемдарлар суды да булган. Гадәттә анда станица судына карата шикаятьләр тикшерелә. Атаман барыннан да бигрәк станица йортындагы тәртип, тынычлыкны кайгырта, суд карарларын гамәлгә ашыру, хәрби хезмәттәге казакларга «шәхси мәнфәгатьләр өчен» өч ай ял бирү кебек мәсьәләләр белән шөгыльләнә. Шулай ук юлларның, күперләрнең төзеклеген тәэмин итү, станицадагы җәмәгать милкен дә күзәтеп тору да аның вазыйфасына керә. Станица һәм поселок атаманы, аның ярдәмчеләренең һәм хөкемдарларның хезмәт срогы өч ел тәшкил итә. Ә башка вазыйфадагылар ел саен сайлана. Станица атаманы итеп шундагы поселокта яшәүче кешене генә түгел, ә читтәгеләр дә сайлап куела. Әйтик,

Нагайбәкләр

Нагайбәк казаклары

1889-1891 елларда Каменно-Озернаяның атаманы Нежинский поселогында яшәүче нагайбәк Иван Максимович Бектеев булганы мәгълүм.

Җыенда станица атманы, хөкемдар, казначы, йөзбашлары, унбашлары, язу-сызу эшләре белән шөгыльләнүчеләр сайлана, уку йортлары ачыла. Моннан тыш, сөрүлек җирләрнең күләме тәгаенләнә. Бу җирне һәм станица мөлкәтен казакларга бүлеп бирү эше дә җыенда башкарылган. Станица һәм хутор җыены карарлары, расланыр өчен, Наказной атаманга җибәрелүе шарт. Хуҗалык саны утыздан күп, әмма 300дән артмаган станицалар җыенга 30 кеше сайлап җибәрә. Ә 300 хуҗалыктан күбрәк булганнар станицаларда һәр ун хуҗалыктан бер кеше катнаша. Меңнән артык хуҗалыклы станицаларда җыенга йөздән дә ким кеше җибәрмәгәннәр. Сайланган вәкилләрнең бер ел дәвамында җыеннарда катнашу хокукы булып, аларны сайлау эшен хәрби бүлекләр атаманы күзәтеп торган.

Атаман, аның ярдәмчеләре, казначы һәм аның ышанычлы кешеләреннән торган станица идарәсендә төрле типтагы хуҗалык кенәгәләре тутырыла. Аннан башка, станица идарәсе мал-мөлкәтнең дә гадел файдалану мәсьәләсен кайгырта, урманны да күзәтеп тора. Станица идарәсендәге карарлар, станица җыены һәм судындагы кебек үк, күпчелекнең тавышы нигезендә кабул ителә.

1860 елда Оренбург казак гаскәриләренең 68 станицасы булып, аның 138 отряд, 171 пүчинкә һәм 7 хутордан торганын, бер юртка 4,64 торак урыны туры килгәнен күрәбез. Бу елдагы тору урыннары исемлегендә поселоклар булмаса, XIX гасыр азагында инде алар станица, зур авыллар, хутор һәм кышлаклар хисабына тулысынча формалашып бетә.

1889 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, нагайбәкләр 17 поселокта яши. Алардагы 18360 кешенең 8709ын, ягъни 47,4 процентын нагайбәкләр тәшкил итә.

XX йөз башында нагайбәк офицерлары нәселеннән булган Бектеевлар үз хуторларын оештыра. Әйтик, 1900 елда Бектеев хуторындагы 30 хуҗалыкта 220 кеше яши. Шундый ук исемдәге хутор Верхнеуральск өязендә дә оеша. Анда исә 17 хуҗалыкта – 103 кеше.

1902 елда Оренбург казак гаскәре карамагында 44 станица теркәлә. Аның составына 370 поселок кереп, бер станицага якынча 8,4 поселок туры килә. Күрүегезчә, XX гасыр башына станица юртлары шактый зурая.

Оренбург казак гаскәре станицаларында нагайбәкләр яши торган поселоклар. 1914 ел

№	Поселок исеме	Станица исме	Хәрби бүлек номеры
1	Алабайтал	Гирьял	1
2	Гирьял	Гирьял	1
3	Ильинский	Ильинская	1
4	Подгорный	Ильинская	1
5	Нежинский	Каменно-Озёрная	1
6	Астафьевка	Березинская	2
7	Куликово	Березинская	2
8	Фершампенуаз (Бакалы)	Березинская	2
9	Париж (Яңавыл)	Великопетровск	2
10	Кассель (Кили)	Верхнеуральск	2
11	Остроленко (Сарашлы)	Верхнеуральск	2
12	Требия	Наваринская	2
13	Верхнеувельск (Варламово)	Коельская	3
14	Попово (Папау)	Коельская	3
15	Болотово	Кундрау	3
16	Ключевка-2 (Лягушина)	Кундрау	3
17	Краснокаменка	Кундрау	3

Таблицадан күренгәнчә, нагайбәкләр 9 станицадагы 17 поселокта яши. Шулардан Ильинский белән Гирьял гына станица статусында, ә калган 15е – поселоклар. Гомумән алганда, 1914 елда 9 станицада 87 торак пункт, шуларның 84е – поселок, 3есе генә пүчинкә. Косачевский, Колодкинский һәм Буровский пүчинкәләре Кундрау станицасына керә.

Нагайбәкләрнең православие динендә булуы башка халыклар, аеруча урыслар белән мөнәсәбәтне шактый җиңеләйткән. 9 станицада да яшәүчеләрнең күбесе – урыс милләтеннән. Алда саналган поселокларда исә, Кулиководан кала, барчасында да нагайбәкләр сан ягыннан өстен. Шуңа да бу торак пунктларда нагайбәкләр җирле мәсьәләләрне үзләре генә хәл иткән. Әмма алар кабул иткән карар станица идарәсе тарафыннан расланырга тиеш. Башка милләтләр бер чама булган поселоклардагы җыенда карала торган мәсьәләләр кайсы якның күпме тавыш бирүенә карап хәл ителә. Ә инде нагайбәкләр аз санда гына яши икән, алар күпчелек кабул иткән карарга буйсынырга мәҗбүр була.

Шулай итеп, XIX гасыр азагы-XX йөз башында Оренбург казак гаскәре идарәсендәге нагайбәк авылларында эчке идарә-административ система тулысынча формалашып, аларда эш җайга салына. Бердәм көч-куәт тәшкил итеп, гаярь, курку белмәс нагайбәк ирләре Россия империясе алып барган төп сугышларның барысында да катнашып, зур батырлык, дан-мәртәбәләргә ирешкән. Ә аларның кылган батырлыклары турында киләсе саннарның берсендә сөйләрбез.

*Фотоларны Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк районы үзәкләштерелгән музей системасы директоры **Надежда Герасимова** тәкъдим итте.* ■

ТАССР 100 лет
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү

ТАТАР ТЕЛЕН ГАМӘЛГӘ КУЮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Хаҗи Габидуллин*

1

Совет аппаратының татар мәсьәләсенә чын-чыннан якынлаштырылуының, гомумән, Татарстан Җөмһүрияте эчендә миллият мәсьәләсен чишүнең иң гамәли моментларыннан берсе – татар телен гамәлгә кую, аны дәүләтләштерү эшедер. Совет власте нинди дә булса берәр миллият эшчеләре һәм крәстияннәре өчен туган власть булсын өчен, бу власть, бу аппарат шул халыкның телендә сөйләве һәм язуы кирәк, бу властьта, бу аппаратта бу миллияттәге хезмәт ияләренең кешеләре булуы кирәк.

***Мәкаләнең авторы Хаҗи Заһидулла улы Габидуллин 1896 елның 7 ноябрендә Пермь губернасы Көңгер шәһәрендә мулла гаиләсендә туа. 1924-1927 елларда ТАССР Халык комиссарлары шурасы рәисе, 1927-1930 елларда РСФСР кече ХКШ әгъзасы, 1933-1937 елларда М.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университеты профессоры, РСФСР төрки халыкларына латин әлифбасын гамәлгә кертү өчен җаваплы булган хезмәткәрләрнең берсе, тарих фәннәре кандидаты. 1937 елның мартыннан СССР ФА «Төркия белән фәнни элемтәләрне ныгыту буенча комиссия» рәисе урынбасары. «Татарстан за семь лет (1920-1927)» (Казан, 1927), «Очерки панисламизма и пантюркизма в России» (автордаш А.Аршаруни, М., 1931); «Младотурецкая революция: исторические очерки» (М., 1936) исемле китаплар авторы. Х.Габидуллин 1937 елда «троцкийчы-милләтче оешманы җитәкләү»дә гаепләнеп кулга алына һәм шул ук елда атып үтерелә.**

Мәкалә авторы – Хаҗи Габидуллин

1919-1920 елларга кире кайтып карасак, без шуны күрәбез: Үктәбер революциясенә өченче яшь тулганлыгына карамастан, хәзерге Татарстан Җөмһүриятенең 5 губернага бүлгәләнгән өлешләрендә, губерна һәм өяз аппаратла-

Бу мәкалә «За 5 лет к V годовщине провозглашения ТССР» (1925) исемле китапта рус һәм татар телләрендә басылган. – **Ред. иск.**

рында гына түгел, бәлки волость башкарма комитетларында да татарларның саны бик аз иде. Революциягә кадәр булган вакыт турында сөйләп торасы да юк.

Татарстан Җөмһүриятенең составына кергән 234 волбашкармаларында татар крәстияннәренең барлыгына карамастан, татарлардан тик 5-6 гына волость секретарьлары, 20-25 кенә кәнсәләрия эшчеләре, 20-25 процентка кадәр генә волость һәм кантон башкармаларының членнары бар иде. Хәлбуки боларда татар халкы зур күпчелек. Казан губернасының башкарма комитетына һәм өяз аппаратларына килсәк, боларда бары 3-4 проценты гына татарлар бар иде. Булганда да, болар күбесенчә мәгарифнең азчылык милләтләр бүлекчәләренә һәм бүтән азчылык милләтләргә караган органнарда җыелганнар иде. Татарстан Җөмһүриятенең хөкүмәте беренче елда башлыча халык комиссариатларының югары урыннарын татарлаштыру һәм волость, кантон башкармалары кебек советларның сайлаулы төп органнарында татарларны арттыру эшендә иде.

2

Татарстан Үзәк башкарма комитетының һәм халык комиссарлары советының «Татар телен гамәлгә кую турында»гы беренче декреты Татарстан Җөмһүрияте төзелү көненең беренче еллык бәйрәмендә – 1921 елның 25 июнендә Сәедгалиев иптәш белән Мансуров** иптәш имзасы астында чыкты. Ләкин татар телен гамәлгә кую эше һәм аның белән багланышта булган аппаратны татарлаштыру эше бер яктан, Татарстан Җөмһүрияте төзелгәнче татарлар дәүләт һәм кәнсәләрия эшенә бер дә тартылмаганлыктан читенләшсә, икенче яктан, халыкның һәр җирдә диярлек тел ягыннан катнаш булып утырганлыгыннан читенләшә иде. Менә шул сәбәптән чакырыла торган эшчеләргә татар телен һәм имлясын белү генә түгел, бәлки урыс телен дә яхшы белүләре кирәк була иде. Тиешле квалификация һәм гадәтләнү турында сөйләп торасы да юк.

Әмма «Татар телен гамәлгә кую турында»гы беренче декреттан соң булган, моңарчы тарихта күрелмәгән каты ачлык, аның юлдашлары һәм нәтиҗәләре Татарстан Совет властеның бөтен дикъкатен ачлык һәм үлем белән көрәшкә таба тартты, суырды. Татарстан Җөмһүриятенең өченче елында гына хөкүмәт татар телен гамәлгә кую мәсьәләләрен конкрет рәвештә алга куя алды. 1922 елның ахырларында «Татар телен гамәлгә кую турында» инструкция чыкты, моннан соң 1923, 24, 25 елларда татар телен гамәлгә кую буенча бер-бер артлы карарлар һәм чаралар чыгып тордылар. Болар аркасында татар телен гамәлгә кую эшләренең асыллары һәм перспективалары билгеле бер юлга салындылар.

3

Татарстан Җөмһүриятенең шартлары буенча, татар телен гамәлгә кую эшләренең төп бурычлары түбәндәгеләр: 1) Татарстан Җөмһүриятенең бөтен дәүләт һәм җәмәгать учреждениеләрендә татар телен һәм урыс телен хокукый һәм гамәли яклардан бертигез итү; 2) күпчелек

****Сәхибгәрәй Сәедгалиев (1894-1938) – журнал укучыларга таныштыр, дип уйлыйк.**

Борһан Хөснетдин улы Мансуров 1889 елның 24 июнендә хәзерге Ульяновски өлкәсе Иске Кулатка районы Иске Зеленай авылында мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Туган авылында, Әстерханда һәм Казандагы Мәрҗани мәдрәсәсендә белем ала. Б.Мансуров – Татарстан Җөмһүриятен төзүчеләрнең берсе, 1920-1921 елларда Татарстан АССР үзәк башкарма комитеты (ТатЦИК) рәисе. Ул милли мәдәният һәм милли тел үсешен кайгырта, җитәкче урыннарга милли кадрларны куюны таләп итә, төрле газета-журнал редакцияләрендә эшли. Сугыш башлангач, авырган килеш Мәскәү өчен утын әзерләргә урман хуҗалыгына җибәрелә һәм 1942 елның августында шунда вафат була.

татар булган урыннардагы бөтен совет учреждениеләрендә һәм предприятиеләрендә кәнсәләрия эшен актив формада татар телендә йөртү, урыслар азчылык булган урыннарда урыс телендә эш йөртүне саклап калу, ягъни урслар өчен урыс телендә язып һәм сөйләп эш кылуга ирек бирелә; 3) халыкның күпчелеге урыс, азчылыгы татар булган урыннарда эш йөртүдә актив тел урысча булып, татар теле пассив хәлендә саклана; 4) азчылык милләтләр өчен ана телендә сүз белән мөнәсәбәт йөртүне тәэмин кылырга, язу мөнәсәбәтләре өчен Татарстандагы ике дәүләт теленең кайсында эш йөртү уңайлырак булса, шуңа юл бирергә; 5) ана телендә язып, сөйләп эш йөртүне түбәндәге аппаратларда: авыл советында, волбашкармаларда, фабзавкомнарда, месткомнарда, кооперациянең беренче баскычында, милиция, суд, тикшерү участокларында үткәрүен беренче нәүбәткә куярга, әмма югары аппаратларда гамәлгә куюны акрынлык белән алып барырга, татар телен Татарстанның үзәк учреждениеләрендә бөтенләй гамәлгә кую мәсьәләсен Җөмһүриятнең унъеллык бәйрәмнәренә табарак куярга.

4

Татар телен гамәлгә куюда төп бурычларыбыз менә шулар, ләкин бу чараларны тормышка кертү башка күп бурычлар берлә нык багланыштадыр. Боларның кайберләрен күрсәтеп үтик: 1) совет аппаратына татар эшчеләрен нык тарту; 2) тиешле специалист буенча кыска сроклы курслар аркылы татарларның җирле хезмәт ияләре арасында яңа эшчеләр хәзерләү, шулай ук хәзерге вакытта булган кәсеп-техника мәктәпләренә һәм бүтән уку йортларына татарларны алуны көчәйтү; 3) урыс хезмәтчеләренә һәм югарылаштырылган типтагы уку йортларындагы укучыларга татар телен өйрәтү; 4) волость чикләрен, шулай ук аерым ведомстволар линиясе буенча районнарның һәм участкаларның чикләрен татар яки урыс теле таралган тупраклар чикләре белән мөмкин кадәр туры китерү; 5) бөтен мәдәни-икътисади терәк пунктларны (мәктәпләрне, кооперация берлекләрен һәм бүтәннәрне татарның хезмәт массасына якынлаштыру); 6) татар телен дәүләтләштерү чараларын гамәлдә күрү (атамалар һәм кәнсәләрия эшен йөртү формаларын эшләп чыгару, нәшрият эше, язу машиналарын хәзерләү һәм бүтәннәр) һәм совет, хуҗалык, профессионал һәм мәдәният төзү эшләрендә эшчеләр чыгарыр өчен, тип-тигез уларак татар пролетариатының үсүе өчен уңышлы шартлар бирү. Татар телен гамәлгә куюда эш менә шул төп тармаклар нигезендә барды да.

5

Татар телен гамәлгә куюда турыдан-туры җитәкчелек итәр өчен Татарстан үзәк башкарма комитеты янында 1922 елда ук татар телен гамәлгә куюның үзәк комиссиясе, кантон башкармалары янында кантон комиссияләре төзегәннәр иде. Кантон комиссияләрендә берәр ыштатлы инструкторлар бар иде, Үзәк комиссиядә гадәттә ике-өч даими эшче була торган иде. Үзәк һәм Кантон комиссияләренең эшләре башлыча директив бирү һәм контроль ясау рәвешендә иде. Болар тиешле закон проектларын хәзерлиләр, хисап һәм ыстатистика материалларын җыялар, докладлар тыңлыйлар, хисап алалар, тикшерәләр һәм инструкторлык эшләрен оештыралар иде. Ләкин шуның белән бергә үк татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе дә, кантон комиссияләре дә татар телен дә, рус телен дә белгән эшчеләрне хәзерләүдә һәм мондый эшчеләрне урнаштыру, боларның саннарын алу эшләрендә дә катнаша иде.

Татар телен гамәлгә кую бу биш ел эчендә Татарстан Җөмһүрияте совет төзелешенең төрле тармакларында түбәндәгечә барды.

АВЫЛ СОВЕТЛАРЫ

Татарстан Җөмһүрияте төзелгәнчегә кадәр дә авыл советларының сайлана торган составы һәм боларның рәисләре авылның үз халкы эченнән, миллият составына карабрак сайланалар иде. Шул сәбәптән авыл советларының составы авыл советлары тарафыннан берләштерелә торган авыллардагы халыкның миллият составы белән бергә баралар иде. Татар авылларындагы советларның секретарьларына һәм боларның кәнсәләрия эшләренә килсәк, монда гадәттәге хәл: урыс телендә кәнсәләрия эшен йөртерлек квалификацияле кешеләр булмау сәбәпле, кәнсәләрия эше аз гына да юлга салынмаган иде. Кайбер вакыт урыс авылларыннан аерым түләү биреп секретарьлар чакыралар иде. Бөтен кәнсәләрия эшен, бөтен протоколларны һәм карарларны татар халкы урыс телендә язарга мәҗбүр ителде. Авылдагы татарлар, нәрсә язылганын һичбер дә аңламасалар да, урыс телендәге приговорлар астына үзләренең имзаларын һәм тамгаларын куялар иде. Мондый хәлләр күп вакыт төрле аңлашылмаулыклар тудыралар иде. Урыс телендә үтенеч язып бирерлек ышанычлы кеше булмау сәбәпле генә крәстиян татарлар күп вакыт нинди дә булса берәр үтенечләрен яки шикаятьләрен әйтә алмый калалар иде. Авыл советларында татар телен гамәлгә кую 1922 елда ук башланды. Ләкин кәнсәләрия эшен татар телендә йөртү беренче мәртәбә генә куела башлау сәбәпле һәм кәнсәләрия эшен йөртүнең билгеле калыпка сугылган формалары, татар телендә атамалары булмау сәбәпле, җитәрлек квалификацияле секретарьлары булган һәм эштә укытучылар катнашкан авыл советларында гына татар телен гамәлгә кую мөмкин иде.

Бераздан соң татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе авыл советларында кәнсәләрия эшен йөртү турында, кәнсәләрия эшенең формаларының үрнәкләрен күрсәтеп, татар телендә кулланма һәм инструкция чыгарган иде. Күп волостьларда һәм күп кантоннарда татар телендә кәнсәләрия эшен дөрес юлга кертер өчен кыска сроклы курслар үткәрелде һәм авыл советларының секретарьларына инструкцияләр бирелде. Татар авылларындагы советларда татар телендә кәнсәләрия эше куелуны без 1922 елдан алып 1924 елга кадәр түбәндәгечә күрәбез: 1922 – 20%, 1923 – 50%, 1924 – 80%, 1925 – 85%.

Хәзер Татарстан авылларындагы советлар арасында 1122се, ягъни 85 проценты кәнсәләрия эшен татар телендә куеп җиткерделәр. Авыл советларында татар телен гамәлгә кую, волбашкармаларның бу эшкә хәзерләнүләре белән нык бәйләнгән. Татар телен гамәлгә куюда Алабуга, Тәтеш, Зөя һәм Спас кантоннары артта калганнар. Шуның өчен дә боларның волбашкармалары һәм авыл советлары да бу эштә башкаларга караганда арттараклар.

Хәзер инде авыллардагы бүтән учреждениеләргә килсәк, татар авылларындагы, мәктәпләр, көтебханәләр үзләренең кәнсәләрия эшләрен бөтенләй үк татар телендә йөртәләр, дип әйтергә мөмкин. Крәстияннәрнең бер-берсенә ярдәмләшү җәмгыятьләре, татар телен гамәлгә куюда, авыл советлары белән бер баскычта торалар, дияргә мөмкиндер. Кооператив учреждениеләренең хисап йөртүләрендә һәм кәнсәләрия эшләрендә татар телен гамәлгә кую квалификацияле эшчеләр җитешмәү сәбәпле һәм кооперациянең югары органнары җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәгәнлек сәбәпле, авыл советларына караганда түбәндәрәктер.

Дәвамы бар ■

ЭЧКЕН ТАТАРЛАРЫ

Рафаил Исакаев

КЕРЕШ

Һәр кеше үз гомерендә өч чорны үтә. Балалык һәм үсмерлек чоры өчен үткән юк, ә якты һәм бәхетле киләчәк кенә бар. Һәм менә кеше өлкәнәя һәм, беренче (балалык һәм үсмерлек) чорның хыялларын һәм теләкләрен тормышка ашырырга теләп, «үз» бүгенгесен төзи башлый.

Вакыт сизелми үтә, аның беркемгә дә бәйле булмаган үз агышы бар: бөтен нәрсә дә – көннәр, еллар, гасырлар, дәверләр үткәнгә әйләнә бара... Бу чиксез зур чал үткәндә кеше үз нәселе, кавеме, бабалары тарихының зур булмаган үз инешен табарга омтыла.

Төрки халыкларда җиде буын бабаны, аларның игелекле эш-гамәлләрен белү, нәсел шәҗәрәсен саклау һәм алга таба дәвам итү һәркемнең бурычы булып тора. Бабаларыбыз – эчкен-мишәрләр дә нәсел шәҗәрәсен алып барып, аны буыннан-буынга тапшырып килгәннәр. Алар безгә Тынкачевлар, Бәйбулатовлар, Таиповлар язмалары буларак килеп җиткән. Без әлеге шәхесләргә бу игелекле гамәлләре өчен рәхмәтле. Алга таба ул язмаларга мөрәҗәгать итәрбез. Аяныч ки, Исакаевлар нәселенең язмалары сакланып калмаган. Әтием күп еллар буе алып барган язмаларда исә мине кызыксындырган мәгълүматлар аз булып чыкты. Электрон мәгълүмат революциясе гасырында андый

язмаларның кирәклегенә шикләнсәм дә оныкларым китапларымнан һәм язмаларымнан файдаланыр, дигән өметтә калам.

Бәхеткә, әти безгә – балаларына, яшьлегеннән (1914 ел) башлап, узган гасырның җитмешенче елларын кертеп, үз тормышының хроникасын теркәп калдырган. Ул язмалар аның эшен дәвам итәргә васыять булып тора. Әтиемнең, өч буын бабамның исемнәре, Исакаевларның, Морзаевларның һәм Чиняевларның Өчкүл (әтиемнең мираска калган авылы) җирләрен ниндидер хезмәтләре өчен патшадан бүләк итеп алулары һәм аларның Казан астыннан күчеп килүләре турындагы риваять – эзләнүләремнең башында минем карамагымда булган мәгълүматлар менә шулар.

ЭЧКЕННӘР ТУРЫНДА РИВАЯТЬЛӘР ҺӘМ ТАРИХИ ЧЫГАНАКЛАР

Беренче чыганак булып, алдарак искәртүемчә, бабаларыбызга патша тарафыннан Урал аръягында, Исеттән көньяктарак җирләр бүләк ителү турындагы риваять тора. Бу җирләрдә урнашкан авыллар бүгенге көнгә кадәр яшәп килә. Өч күл янында урнашкан авыл Өчкүл атамасын ала. Тагын ике авыл Әлмән һәм Чияле исемнәрен йөртә. Бер чыганаклар бабаларыбызның Сарытау ягыннан күчеп килүен күрсәтсә, икенчеләре, Казан артыннан күченгәннәр, дип белдерә. Моннан тыш, тарихи документларда бабаларыбыз эчкеннәр (безнең як сөйләшендә – «эцкеннәр»), ягъни илнең эченнән күченгәннәр дип күрсәтелә. Халыкта каяндыр күчеп килүчеләрне шул төбәк атамасы белән йөртү гадәте бар. Мәсәлән, Сембер ягыннан килүчеләрне бездә «семберләр», Каргалыдан күченүчеләрне «каргатлар» диләр. Безнең бабаларыбызны да, Казан ханлыгының эчке өлкәләреннән күчеп килгәнгә, «эчкеннәр» дип атаганнар, күрәсең.

Эчкеннәрнең «мишәр» дигән этник төркемгә каравын ачыклаучы бик мөһим факт бар. Ул галим һәм сәяхәтче И.Г.Георги язмалары белән раслана. 1770 елда Урал аръягы буенча сәяхәт иткәндә галим безнең Әлмән һәм Өчкүл аша уза һәм эчкеннәр хакында кызыклы мәгълүматлар бирә: «Бу татарлар эчкен казакларына карый һәм картларның сөйләвенчә, 100 еллап элек, әле Бөек Петр яшүсмер чагында, Казанның эчке өлкәләреннән килгәннәр һәм Исет елгасына койган Эчкен (хәзер Йолдыз) елгасы буенда урнашканнар. Хәзер аларның саны шулкадәр арткан ки, инде 200ләп гаилә тәшкил итәләр, Течь һәм Миас елгалары буенда сибелеп гомер итәләр. Алар – мишәрләр, кирәк булганда хәрби хезмәт үтиләр һәм шуңа күрә салымнардан һәм рекрут итеп алынудан азат ителгәннәр». Академик И.Г.Георги тагын, эчкеннәр – Казан ягыннан күчеп килүчеләр, моны этник төркем атамасы ук күрсәтеп тора: эчкен, димәк, эчке, дип яза.

УРАЛ АРЪЯГЫНА КҮЧЕП УТЫРУ

Икенче чыганаклар буенча, Казан ханлыгының алынуы Сарытау төбәгендә яшәгән бабаларыбызның язмышын кискен үзгәртә. Кардәшләренә теләктәшлек күрсәтеп, бабаларыбыз рус дәүләтенә хезмәт итүдән баш тарталар һәм бу дәүләтнең көньяк чиген ташлап китеп, ул вакытта Себер ханлыгы хакимлегендә булган Урал аръягына күченәләр. Алар баштарак хәзерге Йолдыз (баштагы исеме – Эчкен) авылы урнашкан җирләрдә төпләнәләр. Авыл аша аны су белән тәэмин итеп торган Эчкен елгасы агып үтә. Табигать-климат шартлары буенча бу урыннар бабаларыбыз күчеп киткән төбәккә охшаш: уңдырышлы кара җир, урман-дала, елгалар, күлләр. Бирегә килгәч, алар күнегелгән тормыш рәвешен җайга сала башлый. Эчкен-мишәрләр өчен мөһим әлеге вакыйга 1554-1555 еллар чигендә була.

Себер ханлыгы яулап алынгач, Тынкачевлар нәселеннән булган 12 гаилә – Алферовлар, Әнвәровлар, Әсәновлар, Бәйбулатовлар, Барамыковлар, Барашевлар, Исакаевлар, Копчаевлар, Тынкачевлар, Уразмәтовлар, Юмаевлар, Азаматовлар 1586 елда Эчкен авылыннан күчеп китәләр. Әлеге гаиләләрнең күпчелек өлеше Бәлкау күленең көньяк ярына урнаша. Икенче өлеше көнчыгышкарак китеп, Чияле авылына нигез сала. Берничә гаилә көнбатышка юл тотып, Өчкүл авылына башлангыч бирә. Алар арасында Шаһбай нәселенең аксакалы җитәкчелегендәге Исакаевлар да була. Шуңа күрә авылның икенче атамасы бүгенге көнгә кадәр Шабай. Әлеге өч авыл халкы, гаять зур биләмәләргә ия булып, дәүләтне көньяк күршеләр һөҗүменнән сакларга тиеш була. Себер приказы язмаларында (1595-1768 еллар), Эчкен волостенда яшәүче күчеп килүчеләр «җирле ак казаклар» булып торалар һәм бернинди салымнар да түләмиләр, чик буе хезмәтен үтиләр, дип күрсәтелгән.

Галим И.Э.Фишер билгеләп үткәнчә, «Россиялеләр бу атаманы кабул итәләр», аерым алганда, «жалованье урынына җир алган Себер казаклары аннан казнага бернинди дә салым түләмиләр, ягъни алар «салымнардан азат булган «ак» җиргә ия».

1720 елга Бәлкау авылы яшәү өчен кысан һәм уңайсыз була башлый һәм аның халкы өч өлешкә бүленә. Күпчелеге зур матур Әлмәнкүлнең көнчыгыш ярына күченеп, Әлмән авылына нигез сала. Шунысын искәртеп үтәргә кирәк, Әлмәннән көнчыгыштарак борынгы курганнар була, әмма аларны бу вакытка талап бетерәләр. Урыслар, мөгаен шуңа күрәдер, Әлмәнгә «Могильная» авылы дигән атама бирәләр. 1689 елда Көньяк Уралның бу җирле ак казаклары Петр Iгә акчалата хезмәт хакы бирүне сорап мөрәҗәгать итәләр. Петр I указы белән Урал аръягы җирле ак казакларыннан драгун полкы оештырыла. Аларга елына 3 сум хезмәт хакы түләү һәм азык-төлек (арыш оны, атлар өчен солы) һәм 6 дисәтинә сөрү җире бирү карала. Җәйге һәм көзге чорда полк ерак далага күчерелә.

1720 елда җиде гаилә төньяк-көнбатыштагы исемсез күл буена күченә. Алар нигез салган авыл Тузавыл атамасын ала. Бу эчкеннәрнең элек биредә каен тузы әзерләүләре һәм дегет кайнатулары белән аңлатыла. 1740 елда шундый ук тарих Өчкүл авылы белән дә кабатлана. Аннан берничә гаилә аерылып чыгып, Аманкүл («шифалы күл») буенда урнаша. Шул рәвешле Эчкен волостен тәшкил иткән биш эчкен авылы барлыкка килә. Дөрес, волость халкының саны күп булмый. Швед галиме һәм сәяхәтчесе И.П.Фальк билгеләп үткәнчә, 1770 елда эчкен мөселманнары 126 гаилә тәшкил итә. Монда XVIII гасыр галиме һәм сәяхәтчесе П.С.Паллас туплаган кызыклы мәгълүматларны китерү урынлы булыр. Ул: «Могильная яки татарча әйткәндә, Әлмән авылы бик матур, киң, кәрәкә балыгына бай булган күлнең көнчыгыш ярында урнашкан. Янәшәдә каберләр булганга, ул авылга руслар Могильная дигән атама биргәннәр, ә татарлар Әлмәнкүл дип әйләнәсе 8-10 чакрымлы күлне йөртәләр. Бер авылда 20 татар хуҗалыгы бар... татарлар – эчкен казаклары, алар... Казанның эчке өлкәләреннән килеп, аз санлы булып, Исет елгасына койган Эчкен елгасы янында төпләнгәннәр. Хәзер шулкадәр артканнар ки, 200ләп гаилә тәшкил итәләр. Алар кирәк очракта хәрби хезмәт үтиләр, шуңа күрә салымнардан һәм рекрутлыкка алынудан азат ителгәннәр, карабодай чәчәләр, аның орлыкларын үзләре белән Исеттән алып килгәннәр», – дип яза. Паллас китергән мәгълүматлар Д.Бәйбулатовның бабалары кулъязмаларыннан алган мәгълүматларын, шулай ук Р.Таипов, Тынкачев язганнарны тулысынча раслый.

Төрле чыганаклардан алынган мәгълүматларның туры килүе эчкеннәрнең кайчандыр Сарытау ягыннан килүләрен дәлилли. Шулай ук бабаларыбызның Исет елгасының кушылдыгы булган Эчкеннән яңа җирләргә күченүе, йомышлы мишәрләр икәнлеге, салымнардан азат ителүләре дә фактлар белән раслана.

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №7 июль 2018

«Шул татарны күрәсе иде, нинди кеше икән?»

Ләлә Мортазина

Сан-Франциско шәһәренең үзәге. 1906 елга кадәр

Татарлар арасында дөньяви мәктәп булдыруга, дини белем белән генә чикләнмичә, дөньяви белемнәр алуга омтылыш шактый элек барлыкка килә. XIX гасырда татарлар өчен Европа төрендәге урта мәктәп ачу буенча дистәгә якын проект тәкъдим ителә, иң мәгълүмнәре арасында Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, Р.Фәхреддин проектлары бар[1]. Ләкин аларның берсе дә, кызганыч ки, тормышка ашмый – хөкүмәт тарафыннан кире кагыла. Шулай итеп, үз милли, дөньяви мәктәбен ачу татар зыялыларының бары тик хыялы гына булып кала. Илдәге сәнәгать, мәдәният өлкәсендә күзәтелгән алгарыш, индустриаль үсеш татар дөньясында да чагылыш таба, халкыбыз арасында да заманча шартларга җавап биргән, фән һәм сәнәгать үсешенә туры килерлек белемнәргә ия булган белгечләргә ихтыяҗ артканнан-арта бара. Татар яшьләре арасында рус уку йортларына, алай гына да түгел, Европа университетларына да кереп белем алу киң тарала. Татар җәмгыятендә күзәтелгән тәрәккыят, Европа мәдәниятенә йөз тоту моңарчы Мисырда, Бохарада укыган татар яшьләрен Төркия, Каһирә, соңрак Европа уку йортларына тарта. Бигрәк тә Париж, Льеж, Фрайбург, Лозаннада укучы татарлар саны арта. XX гасыр башында исә милләттәшләребез арасында Америка, Япония кебек илләргә барып белем алу омтылышы көчәя.

[1]Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1997. – Б.154.



Закир Габдуллин – Сан-Франциско шәһәре студенты

Европа һәм Америка югары уку йортларына юл, күп очракта, Төркия, Истанбул университеты аша салына. Мәсәлән, атаклы галим, җәмәгать эшлеклесе һәм педагог Садри Максуди башта Истанбул, аннан атаклы Сорбонна университетын тәмамлый. Заманында аңа укытучысы һәм «рухи атасы» булган мәшһүр И.Гаспралы Парижга барып укырга киңәш бирә: *«Әгәр белем алырга телисең икән, син, һичшиксез, Парижга бар. Париж университеты – дөньядагы иң яхшы уку йорты»*, – ди ул. Галимҗан Идрисинең дә Европага юлы Төркия аша була, ул Льеж, Лозанна университетларында белем ала. 1918-1919 елларда Германиядә дөнья күргән «Татар иле» газетасының мөхәррире Бәдретдин Сәйфелмөлеков, Льеж университетының медицина бүлегенә кергәнче, Төркиядәге «Солтания» мәктәбен тәмамлый[2].

Шулай итеп, XIX гасыр ахырында татарлар арасында Европага барып белем алу шактый киң тарала. Бу фикерне раслау өчен тагын берничә генә исемне атап узыйк. Болар: Париж университетының табигать белеме бүлеген тәмамлаган Гобәйдулла Бубый, Германиянең атаклы Фрайбург университетында тау эше белгечлеген үзләштергән Искәндәр Рәмиев[3], Льежда техник белем алган Гариф Рәмиев[4] (икесе дә Закир Рәмиев уллары), Льеж университетының физика-математика бүлеген тәмамлаган күренекле математик һәм педагог Гаяз Максудов һ.б.

XX гасыр башында, бигрәк тә беренче рус революциясеннән соң, белемгә сусаган, үз милләтен үстерү, башкаларга таныту теләге белән янган татар егетләре ерак Америкага омтыла башлый. Татар җәмгыятендә шактый зур яңгыраш алган әлеге күренешне татар матбугаты, аерым алганда, «Вакыт» газетасы киң яктырта. Әлеге газетаның 1911 елгы 11 сентябрь санында Сан-Францискода белем алучы татар егете Хәбибулла Байбулатовның «Америкадан мәктүб» дигән мәкаләсе басылып чыга. Химия мәктәбенә укырга кергән татар егете яшьләрне андагы уку һәм яшәү шартлары белән таныштыра. Әлеге ерак кыйтгага барып чыгуының сәбәбен аңлатып, ул болай дип яза: *«Максудым – һәр ни кадәр җәфа чигеп булса да, бер һөнәр үгрәнгәннең соңында үз ватандаш вә милләттәшләремә хезмәт итмәк вә файда китермәктер»*[5]. Кызыксынучылардан бик күп хатлар килә. Газетаның 1912 елгы 9 март санында Х.Байбулатовның җавап хаты урнаштырыла[6]. Әлеге мәкаләдән күренгәнчә, Америка мәктәпләрендә белем алырга теләүче татар яшьләре арасында «Галия» мәдрәсәсе шәкертләре, шулай ук Омск, Петербург, Оренбург һ.б. шәһәрләрдә яшәүче егетләр була.

[2] Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). – Казан: Татар. кит.нәшр., 2001. – Б.364.

[3] Вакыт. - 1914. – 1 август.

[4] Шунда ук.

[5] Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. – 1911. – 11 сентябрь.

[6] Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. – 1912. – 9 март.

Шул ук «Вакыт» газетасының 1915 елгы 23 сентябрь санында Американың Индиана штатындагы Вальпараисо университетында белем алучы ике татар егете – чыгышы белән Себердән булган Фуад Әнвәров һәм Ташкент шәһәреннән Галимҗан Сәйфелмөлековның фоторәсеме басылып чыга[7]. 1914-1915 елларда «Шура» журналы укучылары игътибарына Ф.Әнвәровның «Вальпараисо университеты (Америкада)» дигән мәкаләсе тәкъдим ителә[8].

1913 елда «Вакыт»та Американың Айова шәһәрендә белем алучы тагын бер татар егете – чыгышы белән Уфа губернасының Бәләбәй өязеннән булган, әүвәл Истанбулда, Мисырда укыганнан соң, 1913 елда Америкага күчеп, авыл хуҗалыгы институтына кергән[9] Закир Габдуллинның «Америка мәктүбләре» дигән мәкаләсе басылып чыга[10]. Соңрак шул ук газетада аның фоторәсеме һәм «Америкада әҗнәби мәмләкәт талибәләре» дигән тагын бер мәкаләсе дөнья күрә[11].

Нәрсә белән кызыклы соң әлеге мәкаләләр? Беренчедән, татар яшьләренең мәгарифкә, мәдәнияткә, алгарышка мөнәсәбәтләрен, уй-фикерләрен күрсәтү ягыннан әһәмиятле. Чит илләрдә белем алган бу студентлар татарлар өчен әлегә аз таныш булган яңа дөнья, яңа илләр, милләтләр һәм мәгариф турында үзләренең фикерләрен белдерәләр, андагы вазгыятьне үзләре яшәгән шартлар, белем алган мәктәп-мәдрәсәләр, гимназияләр белән чагыштыралар, шунда яшәүче кешеләр, төрле милләт вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләрне күзәтәләр. Закир Габдуллинны, мәсәлән, аеруча Америкада ярлы балалары белән бергә миллионер балаларының бер табыннан ашап-эчеп, бергә укулары гаҗәпкә калдыра. Аны шулай ук Америкада укучы Кытай, Мексика, Филиппин, Япония кебек илләрдән килгән студентларның, нинди милләттән һәм диннән булуына карамастан, үзара дус һәм тату яшәүләре сокландыра. *«Бик гариб вә бик гаҗиз бер вакытта бу чит мәмләкәт талибәсе миңа зур бер ярдәм итте. Яныма киләләр, сораша, мотаябә кылалар (уен-көлкеле сүзләр белән күңелне күтәрү. – Л.М.), йөргергә алып чыгалар, әлхасыйль, нинди булса бер юл табып, минем ялгызлыгымны оныттыралар иде. Болар арасында мин иң гариб булырга тиешле бер вакытымны да иң күңелле бер сурәттә уздырдым. Болар миңа шулкадәр рәхимле, шулкадәр шәфкатьле иделәр, болар арасында булган вакытта мин үземне Русиядә, туган гаиләм янында кебек хис итә идем»,* – дип яза ул бу хакта[12].

З.Габдуллинның әлеге мәкаләләрне язудан төп максаты татарларны инженерлар әзерләү буенча Америкада – беренче, авыл хуҗалыгы белгечлеге буенча икенче урында торган, бик күп күренекле шәхесләр-белгечләр тәрбияләп чыгарган, мәртәбәле[13] Айова университетына керү һәм уку шартлары, анда яшәүнең нечкәлекләре белән таныштырудан гыйбарәт. Автор фикеренчә, Америкада белем алырга уйлаган һәр кеше, анда барып ирешкәнче, үзенең теләкләрен, мөмкинлекләрен тагын бер кат күздән кичерергә тиеш. Чөнки бирердәге шартлар укучылар өчен гомумән алганда шактый уңайлы булса да, чит илдән килүчеләр өчен бик үк гади түгел. Шуңа күрә ул мондый ерак җиргә килгәнче, аларны белеп тору һәркем өчен мөһим дип саный. Иң беренче шарт, әлбәттә, үзең укырга теләгән белгечлеккә караган фәннәр

[7] Америкада татар шәкертләре // Вакыт. – 1915. – 23 сентябрь.

[8] Әнвәров Ф. Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. – 1914. - №22. – Б.697-699; Әнвәров Ф.Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. – 1915. - №2. – Б.54-56.

[9] Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). – Казан: Татар. кит.нәшр., 2001. – Б.361.

[10] Габдуллин З. Америка мәктүбләре // Вакыт. – 1913. – 25 октябрь.

[11] Габдуллин З. Америкада әҗнәби мәмләкәт талибәләре // Вакыт. – 1914. – 11 февраль.

[12] Габдуллин З. Америкада әҗнәби мәмләкәт талибәләре // Вакыт. – 1914. – 11 февраль.

[13] Габдуллин З. Америка мәктүбләре // Вакыт. – 1913. – 25 октябрь.

буенча билгеле бер дәрәҗәдә белемнәрең булу. Сәләте, мөмкинлеге булмаган яшьләрне биредә кабул итмиләр. Шунда баргач, әзерлек курслары (ибтидаи сыйныфлар) үтәргә дә мөмкин, ләкин бу өстәмә вакыт һәм чыгымнар таләп итәчәк. Һичшиксез үтәлергә тиешле мөһим шартларның тагын берсе – уку теле булган инглиз телен белү. Шуңа күрә бу мәсьәләдә дә, мәшәкатен алдан күреп, ватанда вакытта ук инглиз телен өйрәнеп киленсә, «эшне яртылай җиңеләйтү» була. Гәрчә эшләп уку мөмкинлеге булса да, матди як турында да алдан кайгырту мөһим, чөнки, автор билгеләвенчә, бигрәк тә беренче елны «профессорлар эшкә ышанып килүне муафыйк күрмиләр»[14].

Мәкаләләрдән Америкада укучы чит ил студентларының тормышы-яшәеше турында да кызыклы гына мәгълүматлар алырга мөмкин. Мәсәлән, Американың һәр уку йортында чит илләрдән килеп укучы студентларның үз җәмгыятьләре, оешмалары булган. Әлеге җәмгыятьләр үзара аралашып торганнар, уртак җыелышлар, съездлар үткәргәннәр, һәр чит ил студентына хас булган проблемаларны ачыклаганнар, аларны бергәләп чишәргә омтылганнар. Шул ук вакытта ел саен Американың төрле шәһәрләрендәге уку йортларында белем алучы чит ил талибәләренең бердәм, уртак җыелышлары да булган. 1914 елда ул Закир Габдуллин укыган Айова университетында узган. 1915 елда исә Сан-Францискода шундый зур җыелыш үткәрергә карар кылына. Анда, автор билгеләвенчә, Америкадан гына түгел, дөньяның төрле кыйтгаларыннан студентлар җыелачак. Бу җыелышның «Космополитан» дип аталуы һәм «Бөтен милләтләр өстендә бер инсаният» дигән шигарь астында үткәрелүе аның гаять киң мәсләкле булачагы турында сөйли[15]. Шунысы кызык, «Вакыт» газетасында басылган шушы хатлардан Америкадагы шул берән-сәрән татар студентлары да безнең өчен ерак булган чит илләрдә татар дигән милләтне күрсәтә алган, дигән фикергә килергә мөмкин. Чөнки, Закир Габдуллин язуынча, әлеге җыелышларның берсендә җыелышның рәисе аңа: *«Татар мәктәпләреннән вәкил килсә, һич шөбһәсез, сезгә дә, безгә дә файдалы булыр иде»,* – дип белдергән. Татар шәкерте бу фикерне үзе дә бик мәслихәт дип кабул итә һәм: *«Татар шәкертләре йә татар яшь зыялылары исеменнән һич булмаганда бер вәкил күндерелсә, бик яхшы булыр иде»*, – дип газета аша белдерә.

Гомумән алганда, татар яшьләрен иң яхшы дип саналган чит ил университетларында укыту мөмкинлеген тудырып (студентларга матди яктан, туганнар, таныш-белешләрдән тыш[16], аерым хәйриячеләр, мәсәлән, Закир Рәмиев, Әхмәт Хөсәенов һ.б. ярдәм иткән, мөселман илләрендә, аерым алганда, Каһирәдә, Истанбулда һ.б. укучыларның шундый махсус җәмгыятьләре дә булган[17]), белем һәм мәгърифәт аша гомумән милләтне күтәрү, татарларны башка милләтләр арасында лаеклы итеп күрсәтү, Америкада белем алган татар шәкертләре фикеренчә, иң зур һәм әһәмиятле бурычларның берсе. Мәсәлән, алда искә алынган Фуад Әнвәров татар яшьләре дә Вальпараисо университеты[18] кебек танылган уку йортларында укырга тиеш дип саный: *«Без дә башка милләт яшьләре кебек бар-*

[14] Габдуллин З. Америка мәктүбләре // Вакыт. – 1913. – 25 октябрь.

[15] Габдуллин З. Америкада әҗнәби мәмләкәт талибәләре // Вакыт. – 1914. – 11 февраль.

[16] Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. – 1911. – 11 сентябрь.

[17] Миннуллин З. Землячества и благотворительные общества татарских учащихся в мусульманских странах (начало XX века) // Мир ислама. – 1999. - №1. – С.137-139.

Закир Габдуллин укыган Айова университеты. АКШ

лыгыбызны күрсәтик, татарның нәрсә икәнлегеннән хәбәре булмаган америкалыларга аның Шәрыктан туып килә торган кояш шикелле төрле вә өметле бер милләт булганын белдерик. Үземездән гали булган башка милләтләр арасында таралыйк. Алардан дәрес алып бераз дөнья күрик»[19].

Шул ук вакытта, татарлар – әлеге ерак кыйтгалар өчен таныш булмаган, билгесез милләт. Америкалылар татарлар турында һични белмиләр, күп очракта аларны ниндидер үзгә, кыргый халык дип күзаллыйлар. З.Габдуллинның Америкага укырга килүе дә, мөгаен, беренче очрак булу сәбәпледер, Айова җәмгыятендә «сенсация» буларак кабул ителә. Ул уку йортына керү белән, җирле газеталарның берсендә аның турында *«Айова зәригать мөһәндислеге (авыл хуҗалыгы инженерлары. –* **Л.М.***) мәктәбенә ерак Русиядән бер татар егете килде»,* – дип хәбәр иткән мәкалә басылып чыга[20]. Бу мәгълүмат белән танышкан америкалылар, тере татар кешесен күрергә теләп, мәктәпкә киләләр. Тик башкалардан берни белән дә аерылмаган гадәти бер кешене күргәч, аптырап калалар. «Шул татарны күрәсе иде, нинди кеше икән?» – дип кызыксынучы Америка кешеләрен күреп, Закир Габдуллин, мөгаен, татарларның чын мәгънәсендә кем икәнлеген күрсәтергә вакыт җитте, дип уйлап куйгандыр. Ул заманда татар милләтен бөтен дөньяга күрсәтү, танытуның иң мөһим юлларыннан берсе – мәгърифәткә омтылу, башка илләр һәм милләтләр арасында югалып калмаслык ныклы белемнәргә ия булу икәнлеген чит илләрдә укучы барлык татар студентлары яхшы аңлаган. Шуңа күрә алар башкаларны да, үзләре артыннан ияреп, дөньякүләм танылган мәшһүр уку йортларында белем алырга чакырганнар. ■

[18] Вальпараисо университеты 1859 елда Кушма Штатлардагы ир балалар һәм кызлар бергә укый торган беренче колледжларның берсе буларак барлыкка килә. Гражданнар сугышы вакыйгалары белән бәйле рәвештә 1871 елда ул ябыла. Кабат 1873 елда эшли башлый. 1900 елда университет статусын ала.

[19] Әнвәров Ф.Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. – 1915. - №2. – Б.56.

[20] Габдуллин З. Америка мәктүбләре // Вакыт. – 1913. – 25 октябрь.

Безнең мирас №7 июль 2018

Америка мәктүбләре

Закир Габдуллин

«Вакыт» гәзитендә минем Америкага килгәнлегемне күреп, бәгъзе ватандашларымнан («Вакыт» идарәсеннән адрес алып булырга кирәк) хатлар килде. Америкага килеп укырга теләгәнлекләрен белдереп язалар. Уку шартларын, тормыш җайларын сорыйлар. Ихтимал, моннан соң да шул рәвеш сораучылар булыр. Шунлыктан мин бу әфәнделәрнең һәркаюсына аерым хат язу урынына «Вакыт» аркылы шул мәслихәтләрне язып китим, дидем. Миңа хат язып, уку җайларын сорашкан әфәнделәр хатларында шул түбәндә язылачак сөальләрнең җавапларын тиешледерләр:

1.Нинди мәктәпкә керергә тиешләр, ягъни мәктәп бетергәннән соң кем булырга вә нинди эшкә керергә уйлыйсыз?

2.Моңа кадәр кайда укыдыгыз? Татар мәдрәсәләренең берсендә укымыш исәңез, дөньяви фәннәрдән нинди һәм никадәр беләсез?

3.Яурупа лисаннарыннан (тел) нинди лисан беләсез?

4.Акчаңыз бармы? Күпме бар һәм монда килгәч җибәреп торуларына ышанасызмы? Булса, күпмегә ышанасыз?

5.Яшегез ничәдә?

Бу сөальләр монда һәр мәктәпкә кергән вакытта сорала торган сөальләрдер. Шул язылган вакытта хат язып сораучыларга җавап бирү җиңел булачак, тәкрар сорашып торырыга хаҗәт булмаячактыр.

Монда беренче дәфга *(тапкыр)* килүчеләр, булмаганда беренче елларын тәэмин итеп килү тиештер. Ят җир булгач, аннан башка да авырлыклар булачагы шөбһәсездер. Безгә дә байтак зәхмәт килде. Сабыр вә мәтанәт *(чыдам)* булып түзгән вакытта ничек тә максудка җитеп була икән. Максудка җиткәч, эш табылып, иптәшләр күбәйгәннән соң, күргән, горбәт чиккән *(илдән аерылып, читтә булу)* зәхмәтләрнең бары да онытылды.

Америкага килергә теләүчеләр шуны да белергә тиешлеләрдер ки, монда татар мәдрәсәләре, Истанбул җәмигъләре юк, мәктәпкә кергән вакытта шул мәктәптә укыла торган дәресләрне яхшы, монтазам *(тәртип белән)* алып барырлык булсаң гына кабул итәләр. Эш бик катгый. Икътидарың *(мөмкинлек, сәләт)* юк икән, туп-туры: кабул итә алмыйбыз, диләр. Затән *(нигездә),* бу хәл Европа мәктәпләрендә дә шулайдыр. Шуның өчен кабул булуына ышана алмаган кешеләр теләдекләре мәктәпкә кирәк өчен хәзерлек үтәргә кирәк булачагын да уйлап килергә тиешлеләрдер. Монда һәр мәктәп янында дип әйтерлек ибтидаи сыйныфлар булып, инглиз телен белмәгән кешеләргә шунда кереп инглизчә үгрәнергә, шуннан соң, икътидарлары булган кешеләргә, турыдан-туры гали сыйныфларга имтихан кылынырга мөмкиндер.

Гомумән, Америкага килүчеләр, монда килмәстән борын, аз булса да инглизчә үгрәнеп килергә тиештерләр. Инглизчә белү монда эшне яртылай җиңеләйтәдер.

Хаслап *(аеруча)* үзем укыган мәктәп хакында хәзергә шуны яза аламын: бу мәктәп «Iowa State College» исемле булып, бу көн Америкада мөһәндислектә *(инженерлык)* – беренче, зирагатьтә *(авыл хуҗалыгы)* икенче урын тотадыр. Монда зирагать, мөһәндислек, икътисад, мал докторлары кыйсемнәре бар. Зирагать кыйсеме үз башы-

на: зирагать мөһәндислеге, агроном, судчылык шөгъбәләренә аерыла. Моннан башка ялгыз зирагатьтән мәгълүмат бирә торган бер шөгъбәсе бар. Бу шөгъбәләрнең зирагать шөгъбәсеннән башкалары бар да дүрт сәнәлек гали сыйныфлардыр. Мөһәндислек кыйсеме тагы шулай берничә шөгъбәләргә бүленә. Мәгъдән *(рудник, шахта),* тимер юл, электрик, машиначылык, биначылык кыйсемнәренә аерылып, һәрберсе бишәр еллык гали сыйныфлардыр.

Бу мәктәптән чыккан кешеләр байтак эш күргәзәләр. Америкадагы Панама каналының бер кыйсемен, Сан-Франциско портын, Колорадода диңгезгә салынган тимер юлны, Чикагода дөньяның беренче станцаларыннан булган станца бинасын, Филиппин әдаләрендә Манила портын бу мәктәптә укып чыккан кешеләр эшләтмешләрдер. Америкада булган бөек эшләрнең һәрберсе дип әйтерлек бу мәктәптән чыккан кешеләр тарафыннан яки аларның катнашы белән эшләнәдер.

Бу мәктәптә еллык расход 800 сум тирәседер. Эш эшләп шуны 300 сумга калдырырга була. Фәкать безнең профессорлар беренче елны эшкә ышанып килүне муафыйк күрмиләр. Җәй көннәрне утарларда эшләп ашау-эчү өстенә айга 45-50 сум чамасы табарга буладыр.

Бу мәктәп шул губернаның үз әһалисеннән *(халык)* алынган налогтан салынмыштыр. Хәзерге тәрбиясе шул вилаятьтә булган халык өстендәдер. Шунлыктан уку хакы үз губернасыннан килгән шәкертләрдән генә алынмыйдыр. Башка губерна яхуд башка мәмләкәтләрдән килеп укучылардан еллык уку хакы 100 сум алынадыр. Фәкать анда да түли алмаслык фәкыйрь кешеләр шул губерна тәбгысы *(подданные)* булып язылып, акча түләүдән котылалар. Хәзер дә мәктәпнең бөтен мөлкәте 5 миллион 44 мең 980 сум 44 тиен торадыр. Бу ел бу мәктәптә 2 мең 600дән артык талибә бар. 220 мөгаллим-мөдәррис дәрес итәдер.

Монда чит хөкүмәтләрдән хәзинә хисабына җибәрелгән шәкертләр дә бар. Күбесе Җәнүби *(көньяк)* Америкадан килгәннәр. Кытайдан – бер, Мексикадан бер хәзинә хисабына укый торган шәкерт бар. Монда 120 миллионер баласы укый. Монда һич бай, ярлы аермасы юк. Шул миллионер балалары белән бер табында ашап-эчеп йөриләр.

Минем татарлык монда үзенә күрә кечкенә бер сенсация (кызык вакыйга) булып калды. Зур мәкли *(җирле)* газеталарның берсендә минем бунда килүемне: «Айова зирагать мөһәндислеге мәктәбенә ерак Русиядән бер татар егете килгән», – дип язганнар иде. Бик күп кешеләр мәктәпкә килеп, күрешеп чыктылар. «Бу нинди кеше икән?» – диделәр бугай.

Минем гади бер адәм баласы булып, башкалардан күп аермам юклыгыны күргәч, үзләре дә килеп йөрдекләренә үкенми (разочароваться итми) калмаганнардыр. **Бервакыт трамвайда барганда шулай янымда утырган ике ханым, газетада күреп булырга кирәк: «Шул татарны күрәсе иде, нинди кеше икән?» – дип баралар иде. «Шулай бигүк күрәсеңез киләмени?» – дип каршыларына чыгып, американча: «Менә ул күрергә теләдекеңез татар егете мин инде, туйганчы күрергә кулыңыздан килә, хак алмыйм», – дидем.** Аптырап калдылар. Монда татар дигәч тә әллә нинди бер халык, дип уйлыйлар шикелле. Күргәч, бик озак ышанмый тордылар.

Габдуллин З. Америка мәктүбләре // Вакыт. – 1913. – №1329. – 25 окт.

Текстны басмага ***Ләлә Мортазина*** *әзерләде.* ■

ГАРИФҖАН МӨХӘММӘТШИН:
*«Әхлакның тамыры – авылда!»**

Бернинди дәүләт яки башка хакимият органы кушуы белән түгел, халыкның үз теләге, үз омтылышы, үз ихтыяры белән барлыкка килгән туган төбәгеңне өйрәнү, аның шанлы-фаҗигале, уй-моңнарга сала торган тарихын барлау хәрәкәте бүген республикабызның кайнап торган җәмәгать тормышының бик тә йогынтылы юнәлешенә, тармагына әверелеп бара. Бу мине, 30 елдан артык гомеремне шушы хәрәкәткә багышлаган өлкән кеше буларак, бик тә сөендерә. Исән булсалар, Бакый ага Зыятдинов, Илдус Юнысов кебек районыбызда бу эшнең башлангычында торган элгәрләребез дә шат булыр иде моңа.

Мин шунысына да сөенәм: безнең республикабыз бу юнәлештә дә илнең әйдәп баручы, иң нәтиҗәле эшләүче төбәге булып тора. Кайда гына яшәсәк тә, без әле бердәм фикер йөртә, бердәм омтылышлар белән яши торган, үзенең милли үзаңын, милли горурлыгын җуймаган бөек татар халкы балалары булып калабыз. Бүген, халкыбызның милли тамырларына балта чабу очраклары көчәя барган чорда, моның ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын сөйләп-аңлатып торуның кирәге юктыр. Халкыбызның, туган төбәгебезнең, авылларыбызның тарихын барлауга керешкәндә әлеге хәрәкәтнең халкыбызны берләштерүнең бер нәтиҗәле чарасына әвереләчәге турында уйламаган да идек юкса.

Безнең җәмгыятькә хас булганча, бу фикер дә буш шигарьгә, буш лозунгка әйләнеп калмасын өчен, «Авылны сакларга!» дигән тәгъбирнең тирән асылын ачыкларга тырышып карыйк әле. Чыннан да, бүген авылларны саклау, саклау гына да түгел, югалган авылларны торгызу – ил, бөтен Россия алдында торган иң әһәмиятле, иң актуаль стратегик бурыч. Ни өчен? Беребезгә дә сер түгел, Россия бүген дөньяның иң әхлаксыз иленә әйләнә бара. Күптән түгел бер Мәскәү газетасын укыйм – зур хәрефләр белән «Ты честный? – Значит у тебя нет денег!» дип язылган. 1990 нчы елларда билгеле бер даирә кешеләре арасында йөремсәк булган гыйбарә бүген инде газета рубрикасына ук күтәрелгән! Кайчандыр Россиядә һәрбер танышу-сөйләшү «Честь имею!» дип башланган. Ә бүген намус, әхлак төшенчәләре кешене кимсетү, түбәнсетү чарасына әверелгән. Нинди әхлаклылык турында сүз алып барырга мөмкин соң бу илдә?! Нәтиҗә – Кемерово шәһәре үзәгендәге бөтен дөньяны тетрәндергән фаҗига. Бүген дистәләгән «служба»лар, чатыр чабып, сәбәп нәрсәдә, кем гаепле, дигән сорауларга җавап эзлиләр. Сәбәп һәркемгә аңлашыла һәм бер генә – бөтен җәмгыятьне иң югарыдан түбәнгә кадәр үтәли биләп алган әхлаксызлык. Ә гаеплеләр? Калебләрендә кечкенә генә әхлак чаткысы булса, дистәләп: «Мин гаепле, мине хөкем итегез!» – дип тезелешеп килергә тиеш иде бит алар мондый жан өшеткеч фаҗигадән соң. «Сегодня вся Россия – «Зимняя вишня», дип бик урынлы язалар матбугат чаралары бүген! Чыннан да, бер генә җәмгыять тә, хәтта үзен иң бөек җәмгыять дип санаганы да әхлаксыз яши алмый. Әхлаксыз җәмгыятьнең

Авыл – ул илнең, җәмгыятьнең әхлак тыюлыгы. Авылны саклау, авылны торгызу – Россиянең игелекле киләчәген саклау, тәэмин итү дигән сүз ул.

*Бу мәкалә авторның 3-5 апрельдә Казанда узган II Бөтендөнья татар авылларын һәм төбәкләрдәге татар тарихын өйрәнүчеләр җыенында ясаган чыгышы нигезендә әзерләнде.

Моңлы-мәкамле телебез, милли йөзебез шулай ук авылда. Авылларыбызны саклый алсак кына без үзебез булып кала алабыз. Татар авылларын саклау, торгызу татарлар буларак безгә бигрәк тә актуаль.

киләчәге юк, үзен-үзе юк итә, «Зимняя вишня»га әверелә ул. Димәк, Россиягә дә, әгәр яшәргә исәбе булса, якын киләчәктә әхлакка кайтырга туры киләчәк! Ә каян алыр соң ул әхлакны? Барыбызга да билгеле булганча, җәмгыять әхләгының тамырлары авылда. Сәбәпләрен тәфсилләп тормыйча гына ассызыклап китик – бу борынгы чорлардан шулай булган һәм шулай булып калачак та. Авыл – ул илнең, җәмгыятьнең әхлак тыюлыгы. Авылны саклау, авылны торгызу – Россиянең игелекле киләчәген саклау, тәэмин итү дигән сүз ул. Менә нәрсә өчен күз карасы кебек сакларга, торгызырга кирәк авылны!

Икенчедән, авыл гомер-гомергә илнең туендыручысы булган, шулай булып кала да. Безнең буын гомерендә генә дә авылларны юк итүнең өченче омтылышы тормышка ашырыла бүген. 1960 нчы елларда ул барып чыкмады. 1990 нчы елларда да авыл үзен мең газаплар белән саклап кала алды. Ә менә бүгенгесе инде безнеке кебек рухи ныклыгы булган төбәкләрдә дә үзен көннән-көн ныграк сиздерә, авылларның нигезе какшый бара. Авыл хуҗалыгы өчен чиксез мөмкинлекле Россия, акыллы аек караш, эзлекле уйланылган сәясәт булганда үзен генә түгел, ярты дөньяны менә дигән югары сыйфатлы азык белән тәэмин итә, ил өчен мул табыш чыганагы була ала, моны нигезләп аңлатып торуның кирәге юк. Әмма бүгенге миллиардерларыбызга түземлек, ерак перспективага юнәлтелгән эзлекле сәясәт белән авылны торгызу, яңарту, үстерү кирәк түгел шул, алар өчен акыл кысаларына сыймый торган бәяләргә чит ил «отходын» кертү, ил халкын шуның белән туендыру өстенрәк. Илнең сәясәтен дә шулар билгели бит инде!

Ил бөтен дөнья белән дошманлашып беткәч, санкцияләр кертелеп, чарасыз хәлдә калгач, авыллар барын исенә төшерде төшерүен. Әмма әз генә өнгә килү белән, кызганыч ки, кабат онытты. Соңгы чорда сөт җитештерү һәм сатуда туган акыл кысаларына сыймый торган мәгънәсезлек моны бөтен чирканыч асылы белән ачып салды. Каяндыр китерелгән шикле «сөт порошогы» авыл хезмәтчәне җитештергән саф сөттән өстен булып чыкты! Кыскасы, авыл кешесенә хөрмәт юк, аның хезмәте бәяләнми. Иртәгә сиңа, синең мең газаплы хезмәтеңә нинди караш булачагына ныклы ышанычың булмаган хәлдә ничек итеп авыл хуҗалыгы кебек мең четерекле тармакта җиң сызганып эшкә алынырга мөмкин?! Ил авылга батканда ябыша торган салам итеп карарга түгел, ә аны үзенең ышанычлы туендыручысы буларак сакларга тиеш.

Соңгы берничә ай дәвамында үзебездән ерак булмаган тирәдә яшәүче өч ир-атны җир куенына иңдердек. Иң олысына – 53 яшь. Канатланып яшәргә дә яшәргә тиешле ир-егетләр. Өчесенең дә диагнозы – «тромб». Бик тә абруйлы таныш табибка сорау бирәм: «Нәрсәдән соң бу, әле дистә еллар элек кенә андый диагнозны ишеткән дә юк иде бит!» – дим. «Тукланудан инде, Гарифҗан абый, бөтен дөньяның отходын ашыйбыз бит!» – ди.

Күрәбез, авыл илнең туендыручысы гына түгел, ил халкының сәламәтлеген, аның генофондын саклаучы да. Менә ни өчен күз карасы кебек сакларга, торгызырга кирәк авылны!

Минем сезгә бер сорау бирәсем килә: бүген бездәге җитештерү тармакларының кайсы иң артта калган? Сүз дә юк, ул – демография тармагы. Илдә балалар аз туа. Димәк, бу тармакта иң түбән хезмәт җитештерүчәнлеге. Юкса, монда хезмәт тә ялыктыргыч авыр түгел, әллә нинди инновацияләр дә, нанотехнологияләр дә таләп ителми. Әмма җитештерүчәнлек түбән, түбән генә түгел, елдан-ел түбәнәя бара. Моның илнең киләчәге өчен аяныч нәтиҗәләре турында озын-озак итеп сөйләшергә булыр

Безнең яшьләребез озын-озак 11 ел мәктәптә укып чыкканда Мисыр фиргавене Тутанхамон турында, Л.Н.Толстой «зверь», «чудовище» дип атаган Петр патша хакында, шул ук Гитлер турында әллә ниләр белеп чыга. Ә менә күршесендә яшәгән Әхмәтгали бабайның, шул ук Гитлерны тар-мар итеп, Берлинга барып җитүен, Берлинны алгандагы батырлыгы өчен орден белән бүләкләнгәнен белми.

иде. Сүзне озакка сузмыйча гына шуны әйтәсем килә: ничек кенә булмасын, әле авылда балалар туа. Мин үзебезнең Татарстаныбыз мисалыннан чыгып фикер йөртәм, билгеле. Авылларда балалар туу күрсәткече шәһәрләрнекенә караганда сизелерлек югары. Авылда балалар туа гына түгел, сәламәт, әхлаклы булып үсә. Димәк, авыл ул илнең ныклы, ышанычлы демографик фундаменты да икән әле! Менә ни өчен күз карасы кебек сакларга, торгызырга кирәк авылны!

Татар халкы бүген авыр тарихи сынау алдында тора – телебезне, мәдәниятебезне, үз-үзебезне югалту куркынычы яный безгә, халкыбыз милли горурлык хисен бөтенләйгә югалту алдында тора. Ә бит моңлы-мәкамле телебез, милли йөзебез шулай ук авылда. Авылларыбызны саклый алсак кына без үзебез булып кала алабыз. Татар авылларын саклау, торгызу татарлар буларак безгә бигрәк тә актуаль, бигрәк тә кирәк бүген.

Ә менә авылны ничек сакларга соң? Халкыбыз бу сорауга да үзе җавап биргән – «Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк». Шуның өчен дә чын тарихи документаль нигездә, борынгы чорыннан алып бүгенгәчә, объектив язылган үз тарихын булдыру кирәк һәр татар авылының. Нәкъ менә бүген кирәк! Илдә буыннар алмашыну процессы бара. Безнең ил өчен бу буыннар алмашу гына түгел, халыкның дөньяга, җәмгыятькә, гомумән яшәешкә карашы, фәнни тел белән әйтсәк, менталитеты алмашыну процессы. Яңа буынның гаме инде авыл тарихында түгел. Моны бүген, безнең буын, бүгенге илле яшьтән югарылар буыны эшләп калдырырга тиеш.

Авыл тарихына багышланган китап һәр укыган кешедә туган авылыннан аерылмау хисе тәрбияләсен! Эчтәлеге белән дә, сюжеты белән дә, уйсызларны да уйга сала торган моңлы-мәкамле теле белән дә. Менә шул таләпләргә җавап бирә торган итеп язылса, авыл тарихы китабы авылны саклау буенча өстәл дәреслеге була инде. Бүгенге авыл тормышын оештыруның иң зур кимчелеге шунда – анда авыл җәмәгатьчелегенең бернинди дә диярлек катнашы юк. Авыл җәмәгатьчелеге пассив. Бу җәһәттән авыл тарихы китапларында үрнәк итеп алырлык мисаллар бихисап. Шуларның берсен генә атап китик. Революциягә кадәрге чорда авыл мәхәллә булып яшәгән. Мәхәлләнең үзәге – мәчет, җитәкчесе мәчетнең имамы булган. Авылда җирле үзидарә дә, күмәк хуҗалык та, урта яки тугызъеллык мәктәп тә, мәдәният йорты да... юк бит. Авыл тормышында хәл итәсе нинди генә проблема барлыкка килсә дә, мәхәллә халкы мәчеткә җыйналган һәм сөйләшеп-киңәшеп ул проблеманы хәл итү юлларын тапкан һәм хәл иткән. Өлкәннәр фикере абруйлы булган. Авылның мәчете тузган, яңа мәчет салырга кирәк, яки балаларны укыту өчен мәдрәсә кирәк, яки мәчет имамына хезмәт хакы билгеләргә кирәк, яки авылның зиратын, сулыкларны чистартырга кирәк... Менә бу мәсьәләләрнең барысын да мәхәллә үз хисабына, үз көче белән хәл иткән. Район хакимиятенә дә, күмәк хуҗалык идарәсенә дә, җирле үзидарәгә дә бармаган, кайларгадыр шуны да хәл итмиләр, дип шикаять тә язмаган. Иң кадерлеләребез – борынгы изге бабаларыбыз, кайсыларыбызның әти-әниләре, хәтта газиз балалары ята торган татар авыллары зиратларының торышына игътибар итик әле. Шулардан да шапшаграк, шулардан да пычраграк, шулардан да ташландыграк урын бармы авылларыбызда?! Бүген авыл җәмәгатьчелегенең шуларны тәртипкә китерерлек тә көче юк! Көчле бердәм җәмгыять булып яшәгән авыл саклана инде ул, таркалмый. Менә ул авылларны саклауның борынгыдан сыналган бер чара-

Төбәкләрдәге татар тарихына багышланган китаплар күргәзмәсе. 2017 ел, апрель

сы. Мин бик сөенәм: Балтач җирлегендә әнә шундый мәхәлләләр әкренләп булса да оешып килә бүген – Куныр, Кариле, Сәрдек кебек авылларыбызда, мәсәлән. Андый авылларның киләчәге өметле.

Билгеле, китап язу белән генә эш бетми, ул эшләргә тиеш. Авылда уздырыла торган һәрбер чараны хәзерләгәндә, бигрәк тә яшьләр белән эшләгәндә, нигез итеп алынсын. Мәктәптә дәресләрдә, класстан тыш эшләрдә аның мәгълүматлары бирелсен. Безнең яшьләребез озын-озак 11 ел мәктәптә укып чыкканда Мисыр фиргавене Тутанхамон турында, Л.Н.Толстой «зверь», «чудовище» дип атаган Петр патша хакында, шул ук Гитлер турында әллә ниләр белеп чыга. Ә менә күршесендә яшәгән Әхмәтгали бабайның, шул ук Гитлерны тар-мар итеп, Берлинга барып җитүен, Берлинны алгандагы батырлыгы өчен орден белән бүләкләнгәнен белми. Кайвакыт таңнар каласың безнең мәгънәсезлегебезгә, хәтерсезлегебезгә! Патриотизм хисе каян килсен соң? Тарих дәресләрендә Петр патша чорын өйрәнгәндә ул керткән рекрутлыкның туган авылың кешеләре иңенә нинди газап булып төшкәнен, лашманлыкның күпме авылдашының башына җиткәнен сөйләп булмыймыни?! Булмый шул, бүген мәктәп укытучысы тикшерүләрдән куркып беткән инде. Ул кемне тыңларга да белми – прокурорнымы, инспекторнымы, мәгариф бүлеге мөдиренме, мәгариф министрынмы? Министрны икән, кайсысын – Казандагысынмы, әллә Мәскәүдәгесенме? Ә бит белем бирүнең борынгыдан килгән нигезе – ул нинди генә фән булмасын, физикамы, биологияме, географияме, тарихмы, әдәбиятмы – һәр мәгълүматны җирле мисалларга нигезләп аңлату. Шулчакта гына ул баланың бәгыренә гомерлеккә сеңеп кала, иманга әверелә. Патриотлык әнә шулай тәрбияләнә ул, халыкларның иң изге ядкәре булган теленә вето салу юлы белән түгел. Халыкларның теленә вето салу юлы белән ватанпәрвәрлек түгел, илгә нәфрәт хисе генә тәрбияләп була.

Һәрбер җирлектә шундый китапларны язарлык зыялы кешеләрне табарга, аларны бергә тупларга, кызыксындырырга, хупларга, ярдәм итәргә кирәк. Мин – Мәскәү, Казан, Уфа, Киров архивларында атналар буе казынган, әллә никадәрле архив тузаны ашаган кеше. Бүген архивларда эшләү авыр, күп акча таләп ителә. Энтузиастларга ярдәм, аларны хуплау кирәк. Дәүләт тарафыннан кызыксындыру булырга тиеш.

Мин ышанам: якын киләчәктә һәр татар авылының үз тәфсилле тарихы язылыр һәм нәшер ителер, ул китаплар үсеп килүче яңа буын өчен тормыш дәреслегенә әверелер. ■

Марат Юнысов: «Сабан туена зур өмет баглыйбыз»

Эчкен татарлары үзәге, бай тарихлы Әлмән авылында узачак IX Бөтенроссия татар авыллары Сабан туе уңаеннан Курган өлкәсе татарлары конгрессы рәисе, эшкуар, туган төбәгенә иминлек, бәрәкәт, иман нуры китерүче, чын мәгънәсендә милләтпәрвәр шәхес ***Марат Равил улы Юнысов*** *белән очрашып сөйләштек. Аның сөйләгәннәре, ягъни курган татарларының милли һәм дини тормышы белән сезне дә таныштырырга уйлыйбыз, хөрмәтле укучылар!*

Курган өлкәсендә 23 мең чамасы татар Шадринск, Шатров, Әлмән, Сафакүл, Целинный районнарында, Курган, Шумиха, Шадринск шәһәрләрендә таралып урнашкан. Барлыгы 18 татар авылы бар. Тарихлары 1530-1540 еллардан килә. Өлкәдәге күп татар авылларының скиф курганнары янында урнашуын да игътибарга алсак, биредәге төрки-татар тарихының тагын да борынгырак икәненә инанырбыз. Иң әүвәлге авыл – Шадринск районындагы Йолдыз. Аны, бозып, «Юлдус» дип язганнар. Борынгы исеме – Эчкен. Соңгы көннәрдә урынбасарым Әхмәдулла Хәбибуллин белән, аның әүвәлге исемен кире кайтаруны сорап, рәсми оешмаларга хатлар яздык. Авылда яшәүче

Киңәшле эш таркалмас. Сулдан уңга: Марат Юнысыв Курган өлкәсе губернаторы Алексей Кокорин һәм Әлмән районы хакимияте башлыгы Дамир Сөләйманов белән Өчкүл авылы мәчете янында

кешеләрнең яртысы борынгы атамага күчәргә риза. Губернатор һәм җирле хакимият бу мәсьәләне безнең үз ихтыярыбызга калдырды.

Ә инде IX Бөтенроссия татар авыллары Сабан туе узачак Әлмән авылына халык 1586 елда шушы Эчкеннән килеп төпләнгән. Күчеп килүчеләр барлыгы 12 гаилә булып, алар Әлмәннән кала тагын ике авылга – Бишнәк һәм Өчкүлгә нигез салган. Соңрак Әлмәннән – Билкәү һәм Тозау, ә Өчкүлдән – Иванково, ягъни, татарча әйткәндә, Изге Күл исемле авыллар аерылып чыккан. Алар барысы да патша заманында Эчкен волостена кереп, биредә яшәүчеләрне эчкен татарлары дип атап йөрткәннәр.

Хәзерге район үзәге булган Әлмән авылында заманында зур мәдрәсә эшләгән. Бу авылны бөтен дөньяга таныткан дүрт шәхес булган. Аларның берсе – Ибраһим Тынкачев. Ул – 1767 елда Әби патшаның Уложенная комиссиясендә катнашырга эчкен татарларыннан вәкил булып Мәскәүгә барган кеше. Аның улы – Фазыл Тынкачев. Әлмән, Бишнәк, Тозау, Изге Күл, Өчкүл авыллары һәм аларның тирә-ягындагы биләмәләргә хуҗа булган бу кеше Госманлы дәүләтенә юл тота, шунда солтан белән дуслашып, алар бергә хаҗ кыла. Соңрак исә бу дәрәҗәле шәхесне патша Бохарага илче итеп җибәрә. Без бу факт турында тагын ни дә булса ачыклап булмасмы, дип, Төркиягә рәсми хат юлладык. Әлмән авылында 1750-1845 елларда Габденнасыйр әл-Әлмәни-Әл-Эчкени Сабитов яшәгән. Ризаэддин хәзрәт Фәхреддинов аның үз гомерендә 230 китап күчереп язганлыгы турында әйтеп калдырган. 1867-1871 елларда Әлмән мәдрәсәсендә булачак дин галиме Габдерәшит Ибраһимов укый. Әлмән олуг мәгърифәтченең әнисе Гафифә туган авыл да әле.

Кызганыч, Әлмәннең борынгы зираты өстенә совет чорында парк эшләнгән. Анда Фазыл Тынкачев җирләнгән урынны иске фоторәсем һәм бабайлар күрсәтүе буенча ачыкладык. Шушы каберне чистартып, Әлмәндә Фазыл Тынкачевка һәйкәл дә куелачак. Минем уемча, бу парк киләчәктә мемориаль урын булырга тиеш.

Совет чорының беренче елларында Әлмән балалары барлык фәннәрне дә татар телендә генә укыган. Соңыннан укыту рус теленә генә күчкән, татар теле онытылган. Бу уку елында татар телен беренче класска төп предмет буларак керттек. 1 «А» классында урыс исемле балалар да татарча укый, мөгаен, аларның әтисе яки әнисе татар милләтеннәндер. Татар теле түгәрәге дә эшли башлады, балаларны Татарстан лагерьларына җибәрү турында да уйлыйбыз. Район хакимияте башлыгы Дамир Сөләйманов киләсе уку елына татар теле сәгатьләрен тагын да арттырырга вәгъдә бирде.

Туган авылым Өчкүлнең башлангыч мәктәбендә дә татар телен төп фән буларак өйрәнәләр. Өчкүлдә әтием Равил, әнием Гарифә укыган чорда мәктәптә барлык фәннәр дә татарча укытылган. Әтием тарих белән бик кызыксына иде, әнием гомере буе татар әдәби әсәрләре белән танышып барды. Без мәктәптә укыганда әнием алгебра һәм геометрия буенча өйгә бирелгән эшләрне татарча сөйләп аңлата иде. Дүрт бала үстек, гаиләдә татар телендә тәрбияләндек. Бүген дә, Аллага шөкер, туганнарым һәм балаларым белән ана телендә аралашам.

Нижневартовскида Муса Җәлилгә һәйкәл ачып йөргәндә беренче тапкыр Бөтендөнья татар конгрессы хезмәткәрләре белән очраштым. Шул килүемдә алар мине Казанга чакырды. Татарстанга тәүге баруымда татар дөньясының эчкен һәм себер татарлары белән генә чикләнмәгәнен күрдем, халкыбызның зур һәм бай булуына инандым. Күкрәк ачылып китте, кәеф күтәрелде. Шуннан үземдә дә эчкен, сафакүл татарларының милли хисләрен уяту теләге туды. Иң әүвәл туган авылымда мәчет салдырдым, клуб ачтым. Медпункт урынында, гаять игелекле фельдшер, Бөек Ватан сугышы ветераны Нурулла абый эшләгән нигездә музей һәм татар утары оештырдым. Шулай итеп, безнең Өчкүл авылы өлкә буенча оештырыла торган этнографик экскурсияләр маршрутына

Татар утары. Өчкүл авылы

кертелде. Бирегә төрле шәһәрләрдән автобус белән аена 2-3 мәртәбә туристлар килә. Аларны авылдашым Рөстәм хәзрәт каршы ала, татар тормышы турында сөйли, милли ризыклар белән сыйлап озатып кала. Татар теленең байлыгын һәм халкыбызның затлы-зыялы әдипләре барлыгын белсеннәр өчен, клуб диварларына эчке яктан татар теле сүзлеге һәм язучыларыбыз иҗатына багышланган стенд элдердем. Өчкүлдәге элмә такталарның барысын да татар телендә куйдырдым. Чат, Сырлы, Локман урамнары, Чөй (Цөй), Сөлекле һәм Ялангач күлләр... Һәр урынның татарча, борынгы атамасы бар. Аларны биредә булган һәр кеше белергә тиеш. Беркөнне комиссия килеп, безнең белән киңәшми-нитми, бу урамнарга «Зеленое», «Красное», «Белое» исемнәре биреп киткән. Бу – гаять зур мәгънәсезлек!

Кызганыч, безгә мәктәптә татар телен предмет буларак укырга насыйп булмады. Әмма, аңа Аллаһның рәхмәте яусын, Идея Каюмовна Абдеева исемле укытучым безгә яшереп кенә булса да татар телен укытты, туган телебездә басылган китапларны таратты. Аның ире Әнвәр абый мәктәп директоры иде. Соңрак, йөздән артык бала укыган урта мәктәпне бетереп, безне 20 чакрым ераклыктагы Малышево исемле урыс авылына җибәрә башладылар. Андагы мәктәп җимерелгәннән соң, укуны колхозның бер канторасына күчерделәр. Бина – иске, автобус вакытында йөрми... Аллага шөкер, соңгы елларда, егетләр белән киңәшкәннән соң, үзебезнең акчага микроавтобус сатып алып, балаларыбызны җиде чакрым ераклыктагы татар авылы Изге Күлгә илтә башладык. Башта «Газель»нең яртысы да тулмый иде, хәзер исә Өчкүлдән Изге Күлгә барып укучыларның саны илледән артты. Автобуска берничә рейс йөрергә туры килә. Балаларыбызны татар авылында укыта башлаганга бик сөенәбез. Бу милләтебезне саклап калуда бер гамәл булыр, дип уйлыйм. Дөрес, әлеге эшебезгә каршылык белдерүчеләр дә табылды. Ник дигәндә, урыс авылыннан татар балалары киткәч, анда да укучы калмады, мәктәпләре дә тиздән ябылачак. Ә бит 40 ел дәвамында Өчкүл һәм Изге Күл авыллары балаларын бергә укытып, аларда милли рухны саклап калып булыр иде.

Изге Күл авылында татар теле атнага бер сәгать иде, бу елдан ике сәгать төп предмет буларак, ә зурларга факультатив рәвештә кертелә башлады. Бишнәк авылында мәктәп юк. 1969 елга кадәр бу авылда да татар теле укытылган.

Әлмән районындагы һәр татар авылында да мәчет бар, Малышевода яшәүче милләттәшләргә район хакимияте башлыгы элеккеге авыл советы бинасын бирде. Шуны мәчет итеп эшләдек. Әлмәннең үзендә яңа, зур җәмигъ мәчет салырга җир алдык. Аллаһ боерса, Сабан туе көнне ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында аңа беренче нигез ташы салыначак.

Тозау мәчетенең борынгы, революциягә кадәр үк төзелгән бинасы бар. Мин анда Курган һәм Чиләбе өлкәләре мөфтие Ринат Раевны алып килдем. Ташландык, җимерек мәчет бинасы хәзерге вакытта клуб карамагында. Әмма халык белән очрашкач, безгә картлар көне үткәрергә клуб ясап бирегез, шул очракта гына мәчет бинасын алырсыз, дип шарт куйдылар. Авылда яшьләр аз. Киләчәктә аның бинасын тарихи-мәдәни истәлекләр реестрына кертергә уйлыйбыз. Тозау атаклы шагыйрь Макс Гатауның туган авылы да бит әле.

Күптән түгел Казакъстан чигендә, Тобол елгасы буенча урнашкан Звериноголовскида да татарларның революциягә кадәрге борынгы зираты, кабер ташлары һәм таш мәчете бар икәнен белдем. Мәчетне чик буенда хезмәт итүче татар казаклары һәм сәүдәгәрләре 1821-1852 елларда салдырган. Мәчет салынганчы ук балалар татар мәктәбендә белем алган. 1939 елда милли мәктәп крестьян яшьләре мәктәбенә кушылгач та татар телендә укыту берникадәр вакыт сакланган әле. Звериноголовски – «Бүз егет» белән «Таһир-Зөһрә»ләрнең авторы Әхмәд Уразаев-Кормаши (1855-1883) туган авыл! Аның әтисе Мөхәммәдзариф биредә имам булып торган. Звериноголовскида мөфти, дин эшлеклесе Шакир Шәйхелислам улы Хыялетдинов (1890-1974), күренекле татар язучысы, журналист, педагог һәм драматург Абдулла Сафа улы Әхмәтов (1905-1976) та туган. Тарихи мәчетнең гаять зур булуы биредә татарларның күпләп яшәгәнлегенә турында сөйли. 1926 елгы мәгълүмат буенча гына да милләттәшләребезнең саны меңнән артык. Мәчет манарасыннан яңгыраган азан тавышы Тобол елгасы буенча ике чакрымга кадәр яңгыраган. Кызганыч, кайчандыр татар тормышы гөрләп торган мәхәллә мәчетенең бинасы бүген инде хәрабә хәлендә. Ул реставрациягә мохтаҗ, тарихи ядкәрләр исемлегенә дә кертелмәгән. Архитектурасы белән бу мәчет Томскидагы Кызыл мәчеткә охшаш.

Сафакүлдә җиде татар авылы бар. Кызганыч, Сафакүлнең нибары бер генә авылында татар теле укытылган булган. Ул да булса – Мансур авылы. Элегрәк татар теле бер сәгать укытылса, бу уку елында 1 нче класстан алып 9 нчыга кадәр ике сәгать итеп куйдык. Авылда, Аллага шөкер, гаиләдә йогынтысында балалар татар телен онытмый. Мансурда «Ямалдорстрой» АҖ президенты Марс Әхмәт улы Гайнетдиновның матди ярдәме белән Курган өлкәсендәге иң матур мәчет салынды. Карасуда һәм Атҗитәр авылларында мәктәп бинасы булса да, анда балалар булмау сәбәпле, укулар туктатылган. Әлхәмдүлилләһ, ике авылда да мәчет бар. Бахарево-Күбәкәй исемле татар авылы халкы балаларын укырга күршедәге Боровичига йөртә. Уйламаган җирдән, бу авылда да татар телен укыта башладылар. Аларга китаплар китердем, мөмкин булганча ярдәм дә итәргә тырышабыз. Аллаһ боерса, бу эш дәвамлы булыр, дип уйлыйм.

Сафакүлдә татар теле 1972 елга кадәр укытылган. Бу уку елында аны факультатив рәвештә керттек. Киләсе уку елына татар теле дәресләре төп предмет буларак укытылачак дип вәгъдә бирделәр. Сөлекле – мишәрләр авылы. Соңгы елларда татар теле укытучысы пенсиягә китү сәбәпле, эш тукталган иде. Хәзергә туган телне укыту түгәрәк буларак кына оештырылды. Халык белән очрашу вакытында бу хәлне күреп, сездә дә татар телен укытыйк, дип агитация үткәрдек. Район хакимияте башлыгы Рәшит

Хәернәсов та киләсе елдан татар теле мәҗбүри рәвештә төп предмет буларак укытылачак, дип вәгъдә бирде.

Сафакүлдә бу уку елында шәкертләр даими яшәп укый торган мәдрәсә оештырып җибәрдек. Әлегә анда җиде шәкерт белем эсти. Чиләбе һәм Курган мөфтие безгә бу мәдрәсәдә татар теле һичшиксез укытылачак, диде. Эш җайга салынып китсә, без дә, үз чиратыбызда, аларга дәреслекләр һәм методик әсбаплар белән ярдәм итәргә әзер.

Чиләбе шәһәре якын булу сәбәпле, Сафакүлгә татар концертлары еш килә. Концерт-тамашаларга халык бик яратып агыла, бер генә урын да буш калмый. Әмма ара ерак һәм туры юл булмау сәбәпле, Курган шәһәре белән Әлмән районына татар артистларын бик китертә алмыйбыз. Халык татар әдәбияты китапларына да бик мохтаҗ. Совет чорында «Казан утлары»н укып, китап укырга тәрбияләнеп үскән буын, шөкер, исән әле.

«Газпром»ның директорлар советы рәисе Виктор Зубковның авылы Мартыновкада теплица комплексы төзелеп килә, завод та ачарга ниятлиләр. Аның районга газ кертүдә дә ярдәме бик зур. Шуларны ишетеп тә булса кирәк, Сафакүлгә кайтучы татар яшьләре бар. Чөнки Чиләбедә эшсезлек һәм экологик вазгыять начарлану сәбәпле, халык зур каладан кача. Төньякта эшләп, пенсиягә чыкканнар да туган җирләренә кире кайта. 50 яшьлек пенсионерларны алай ук өметсез, дип әйтеп булмый. Иң мөһиме – алар кайчандыр татар мәктәбендә укыган һәм туган телләрендә иркен сөйләшә.

Целинный районында Кара Елга, Мәһәди, Өчкүл исемле татар авыллары бар. Өчкүлгә халык минем туган авылым Зур Өчкүлдән күченгән, ә Кара Елга халкы шуннан аерылып чыккан, диләр. Кайчандыр аларның борынгы бабалары казак булып, Россия дәүләтен көньяктагы күчмәннәр һөҗүменнән саклаган. Мәһәдинең халкы исә – XIX гасырда Казан ягыннан килгән мишәрләр. Совет чорында ул иң зур һәм бай татар авылы иде. Кызганыч, хәзер балалар саны аз булу сәбәпле, ике катлы мәктәп буш тора. Биредә кайчандыр татар теле дәресләре дә укытылган. Дөрес, күршедәге рус мәктәбендә татар телен укыталар, әмма мохит булмагач, бу эш тиешле дәрәҗәдә түгел. Һәр өч авылның бала-чагасын якындагы өч урыс авылына таратып укыту һәм аларга татар телен өйрәнү мөмкинлеге чикләнгән булу сәбәпле, татар балаларын берләштереп, район үзәгендә укыту мәсьәләсен күтәрдем. Алар 120ләп укучы җыелачак. Шулай да Целинныйның үзендә татар теле түгәрәген оештыруга ирештек. Биредә йөзгә якын бала йөри. Аларга, мөмкин булганча, татар теленең кирәклеге, Татарстан, төрки дөнья турында аңлатырга һәм төшендерергә тырышам. Әле күптән түгел генә Әлмәннән бер татар егете Целинныйда хәләл кибет булдырды. Бер ягы мәчет итеп эшләнгән бу бинаны мөфти катнашында тантаналы итеп ачтык. Шул ук кибеттә татар китапларын да сату мөмкинлеге бар. Мәһәди авылында җәмигъ мәчет эшләп килә. Аллага шөкер, халык телне һәм динне онытып бетермәгән. Целинный районында чирәм җирләрне күтәрүчеләр һәм аларның балалары яши. Кызганыч, совет чорында татарлар күтәргән бу җирне Чиләбенең бер агрокомпаниясе арендага алган, нәтиҗәдә, эшче һәм белгечләрнең барысы да читтән килеп, биредәге халык эшсез калган.

Шумиха, дигәч, туган авылым Өчкүл искә төшә. Безнең авылның ике урамында каргатлар яшәгән. Алар шул ук безнең халык, әмма телләре катырак яңгырый. Каргатлар эчкен татарлары белән гаилә кормаган, бик динле кешеләр булып, репрессия шаукымында исән калган халкы Шумихага күченгән. Бүген Өчкүлдә аларның йорт нигезләре генә бар. Шумихада хәзер биш мең татар яши, мәчет эшли. Анда ике мәртәбә өлкә Сабан туен үткәрдек.

Курганның үзендә 1950 нче елларга кадәр татар балалар бакчасы һәм мәктәбе булган. Кызганыч, кайчандыр татар мәхәлләсе үзәге дип саналган мәчетнең имамы Рафаил Галиуллин авырый башлагач, идарәдән милләттәшләребезне читләштерделәр, имам да

Марат Юнысовның әтисе Равил абый, әнисе Гарифә ханым һәм Ләбиб Лерон. 2017 ел, август

башка милләт кешесе. Мәдрәсә юк, читләр анда үз бизнесларын җәелдереп җибәргән.

Зурлыгы буенча Курганнан кала икенче урында торган шәһәр Шадринскида да мәчет ачылды. Шәһәрдә «Дуслык» татар-башкорт йорты да бар. Шунда ук татар телен укыту да оештырылган. Бу шәһәргә халык Шадринск районының татар авылларыннан юл, газ һәм су булмау сәбәпле күчеп килгән.

Шатров районындагы Кызылбай – өлкәдәге иң бай татар авылы. Биредә меңгә якын кеше яши. Авылда нефть-газ станциясе бар. 400 кеше шунда эшли. «Газпром» ике катлы кунакханә, затлы мәктәп, балалар бакчасы, хоккей мәйданчыгы, бассейн, мәчет, хезмәткәрләренә ике катлы йортлар салды. Кызылбай халкы татарча сөйләшә, әмма әлегә кадәр татар теле укытылмый иде. Укытучыларның 99 проценты – татар, кызганыч, мәктәп директоры гына урыс.Узган ел Курган өлкәсендә татар мәгарифе көннәрендә бу авылга килгән ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Нәвап улы Фәттахов: «Биредә ни өчен татар теле укытылмый?» – дигән сорау бирде. Халык исә: «Безнең балаларга техник белем кирәк, алар заводта эшләячәк, татар теле кирәкми», – дип җавап бирде. Мәктәптә йөз бала белем ала. Әмма бу елдан анда татар теле укытыла башлады, Сабан туен да үткәрергә ниятлибез. Кызылбайда заманында иң мәгърифәтле, укымышлы халык яшәгән бит. Аның мулласы Әмир Морат күренекле тюрколог И.И.Гигановка рус-татар сүзлеген төзүдә булышкан. Сүзлек исә 1804 елда Петербургта басылып чыккан.

Гомумән, Курган өлкәсендә ике-өч авылда гына Сабан туе үтә иде. Район хакимияте башлыклары, бюджетта акча юк, дигән сылтау белән милли бәйрәмебезгә игътибарны суытты. Әмма без һәр татар авылында Сабан туе үткәрелүен телибез. Бу – татар халкының ЮНЕСКОга кергән бердәнбер бәйрәме. Ул халкыбызның милли хисләрен аз булса да уятыр иде. 2016 һәм 2017 елларда Татарстанның ярдәме белән беренче тапкыр өлкә күләмендә Сабан туен уздырган идек. Тиздән Әлмәндә узачак IX Бөтенроссия татар авыллары Сабан туена да зур өмет баглыйбыз.

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №7 июль 2018

КАТАЙ АВЫЛЫҺӨНӘРЧЕЛӘРЕ

Таһир Кәримов

Туксанынчы елларда районыбыз гәзитендә Бакалы төбәге тарихына багышланган 5 язма бастырган идем. Аларның икесе туган авылым Катай тарихын яктыртты. Зур күләмле «Катай авылы тарихы» гәзитнең 1993 елгы 15 һәм 17 июль саннарында дөнья күрде. 5 елдан соң, «Туган ягыбыз тарихыннан» рубрикасы астында, икенче зур күләмле язмам – «Катай авылы мәчетләре һәм дин әһелләре» басылды (гәзитнең 1998 елгы 18 һәм 20 август саннары).

Туксанынчы елларның күркәм традициясенә кире кайтып, «Безнең мирас» журналы укучыларына дәвамлы язмалар тәкъдим итәргә булдым. Бу язма – шуларның беренчесе. Авторга тәкъдимнәрегез булса, редакция аркылы яисә турыдан-туры авторның үзенә (tkarimov@bk.ru) җиткерсәгез иде.

Автордан

Халкыбызның тормыш рәвешен, зәвыгын чагылдыручы традицияләре бик күп. Һөнәрчелек – шуларның берсе. Иген иккән, терлек асраган, шул ук вакытта һөнәре дә булган кешеләр элек-электән зур хөрмәт казанганнар. «Тырыш, эшчән», – дигәннәр алар хакында, башкаларга үрнәк итеп күрсәткәннәр. «Һөнәрле кеше беркайчан да югалмас; һөнәрле – үлмәс, һөнәрсез – көн күрмәс», – дип тә өстәгәннәр, бу хакта сүз чыкса.

Дөрес, иген игеп, терлек асрап гомер иткән авыл кешесе өчен һөнәрчелек даими шөгыль булмаган. Кыр эшләре тукталып торган айларда, бигрәк тә кышын хатын-кызлар киндер сукканнар, җеп эрләгәннәр. Ир-атларның бер өлеше чабата үргән, туннар, бүрекләр теккән, башкалары да шөгыльсез тормаган.

Авылыбыз аша Маты һәм Казыяр елгалары акканлыктан, бабаларыбызның элек-электән килгән бер шөгыле тегермәнчелек булган. Әлеге елгаларны тегермән тоту өчен җайлаштырганнар. Маты елгасының «Габҗәлил буасы» дип аталган урыны әнә шул эшчәнлекне чагылдырган. Старшина Габҗәлил Кучумов корган тегермән буасы шулай аталган.

Тегермәннәрнең тагын берсе 1842 елда авылдан ерак түгел Казыяр елгасында Мөхетдин Бикташев һәм Мөхтәрулла Нигъмәтуллиннар тарафыннан корылган. 1853

елга кадәр ул бер ташлы он тарту тегермәне дип хисаплана. Шул елны Мөхтәрулла тегермәнне тотудан баш тарта, нәтиҗәдә, хуҗа булып Мөхетдин кала. Ул аны үзгәртеп төзи, ярма ярдыру өчен дә яраклы итә. Яңа җиһазларга 300 сумнан артыграк көмеш акча тота. Әмма Бикташевның чыгымнары юкка була, Бәләбәй өяз суды карары белән, 1854 елда тегермән ябыла [БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 3866 сакл. бер., 179-182 битләр].

Сәбәбе – тукбирделеләр белән җир бәхәсе, бу тегермән алар белән килешеп төзелмәгән, янәсе.

Мул сулы елгалар булганда, тегермәннәрнең берсе юкка чыкса, яңа урында икенчесе төзелгән. Буадан өстәрәк Җәмил тегермәне була. Аннары Галим Җәмилев үз тегермәнен кора. Ул зур түгел, урман эчендә (Кирәмәтне төшеп, басудан 400 метр барып) урнашкан була. «Нурулла Нәбиуллинның (Гобәй нәселе) суыргычы, Казыярда тегермәне булган», – дип искә алган иде бервакыт элеккеге укытучым Кыям Кадермөхәммәт улы Ситдыйков.

Башка шөгыльләргә тукталып үтик. Хәмит Габдерәхим улы Маликов сөйли: «Чабатачылар урман очында яшәде. Болар – Хәбир, Габдрахман Йосыповлар иде. Заман карт, Урыс Абдулласы (укымышлы булса да, дин тотмаган, шуңа «урыс» дигән кушамат такканнар), Шакир карт, синең бабаң Шәймөхәммәт Кәримов кәлүшчеләр булды. Абдулла дегет куу белән шөгыльләнде. Хаҗиәхмәт Нәбиев баштарак кибет тотты, аннары дегеткә күчте».

Урман очы, дип, Килкабыз ягына сузылучы урамны атаганнар. Авылның бу очы катнаш (нигездә, имән, юкә, сөян агачлары) урманнан торган булган. Агач эше белән бәйле төрле һөнәр ияләре (балта осталары, чабатачылар, мичкә, тәгәрмәч ясаучылар һ.б.), нигездә, бу урамда яшәгән.

Тире иләү, күннән аяк киеме тегү Катайда шулкадәр киң үсеш алган ки, хәтта бу хакта статистик әдәбиятта да махсус әйтелә: «Иске Катайда 28 хуҗалыкта күн аяк киеме тегү белән 34 һөнәрче һәм 5 ялчы шөгыльләнә. 23 хуҗалыкта бары тик кәлүшләр генә тегәләр. Ел саен 7364 парга кадәр җитештереп, аны Бәләбәй өязенең зур базарларында, еш кына авылдан дистәләрчә чакрым ераклыкта урнашканнарында, ваклап саталар» [Кустарные промыслы Уфимской губернии. – Уфа, 1912, б.13, 16].

Бу мәгълүматларга кечкенә генә истәлек өстик. Аны авылдашым Әшрафьян Шакирҗан улы Закировның бүгенге көндә Златоуста яшәүче кызы Лира Аллаһкулиева сөйләде. Ул үзенең бабасы Закирның итекләр тегүче, ярдәмчеләре-өйрәнчекләре булуын белә икән. Һөнәрченең бер истәлеге булып, өй урынында ул утырткан агач – Закир өянкесе үсә. Закирның улы Шакирҗан да һөнәрле була, тегү эше остасын Бөек Ватан сугышы елларында фронтка киемнәр тегәргә тылда калдыралар.

Хәмит абый үз истәлекләрендә берничә кәлүшченең исемен әйткән иде. Башкалары хакында 1917 елгы хуҗалыклар исәбен алу документларыннан беләбез. Иске Катайда – Әхмәтгәрәй Мөхәммәтгәрәев, Гайфетдин Шәмсетдинов, Шәйхезаман Вәлиәхмәтов, Әхмәтзариф Фазлыйәхмәтов, Мөсәлимвәли Әхмәтов, Фәхретдин Җәләлетдинов һәм Әхәзулла Шаһиәхмәтовлар, Яңа Катайда Муллаян Имамәтуллин кәлүш тегү белән шөгыльләнгән.

Яңа Катайда бур җитештерү үсеш ала. Аның белән, нигездә, Арсланбәк нәселе шөгыльләнгән. Моның өчен бур чыгарасы урынны көздән (чокырын казып) әзерләп куйганнар. Чана юлы төшү белән утын ташыганнар, чималны, утын сыярлык итеп куышлап, түгәрәк чокырга өйгәннәр, аннары унике сәгатьләп яндырганнар. Ташны, чүкеч белән ватып, иләк аша үткәргәннәр. Әзер бурны капчыкларга тутырып, базарларга алып чыгып сатканнар. Хәтта шактый ерактагы Минзәлә ярминкәсендә дә Катай буры сатыла торган булган.

Бур чыгару белән бәйле бер истәлекне Мөнир Габбәс улы Гомәров сөйләде. Матының Екатерининскиi 4 нче спирт заводына (Беренче Бөтендөнья сугышы алдыннан аның хуҗалары булып В.И.Видинеевның варислары тора) дөяләр белән ераклардан икмәк китерә торган булганнар. Буш кайтасы итмәгәннәр, Катай аша юл тотып, моннан бур төяп киткәннәр. Алар шулкадәрле күп булганнар, күрәмсең, Маты елгасы аша чыгышлый су эчәргә тукталгач, елганың аскы өлешендә хәтта су бетеп торган, имеш...

Яңа Катайда чабата үрү дә киң таралган була. Беренче Бөтендөнья сугышы алдыннан 20 хуҗалыкта чабатачылар яшәгән. Әлеге мәгълүматлар махсус әдәбиятта китерелә [Кустарные промыслы Уфимской губернии. – Уфа, 1912, б.64].

Яңа Катайдагы кайбер чабатачыларның исемнәре 1917 елгы исемлектә дә бар. Болар – Мөслихетдин Галләметдинов, Хөснулла Хисмәтуллин һәм Лотфулла Сафиуллин. Хөснулла карт пожар каланчасында каравылда да торган. Иске Катайдан Миңлегалим Җәмилев, Шәрәфетдин Шатбәһаровлар да чабата үрү белән шөгыльләнгән.

Авылның бу ягында җитештерелгән балталар исә, җирле ихтыяҗны гына канәгатьләндереп калмыйча, базарларда да сатылган [Кустарные промыслы Уфимской губернии. – Уфа, 1912, б.101].

Тегүчеләр, нигездә, Яңа Катайда яшәгән. Болар – Фатыйма Мөхәммәтшина, Фәтхетдин Нуретдинов, Дәүләтбай Шәрәфетдинов, Әхмәтгәрәй Кучумов.

Иске Катайда такта яручылар күп була. Әлеге исемлеккә Вәлиулла Сафиуллин, Нәдергол Шәмиголов, Насыйфулла Фәрхетдинов, Сираҗетдин Яхшыголов, Габделкадыйр Габделхаликов, Төхвәтулла Хөснетдинов, Мөхәммәтдин Камалетдинов, Кадермөхәммәт Мөхәммәтситдыйков, Гаязетдин Насыйров, Әхмәтвәли Җәләлетдиновның 2 улы, Исхак Ибраһимов, Мөхәммәтназыйф Шәфиков (үзе һәм улы), Мөхәммәтша Шәрәфетдинов, Кәраметдин Кашшафетдинов, Госмангали Мөхәммәтшәрипов, Мөхәммәтнәби Вәлиәхмәтов, Габдулла Фәрхетдинов, Шәех Дәүләтбаев һәм Дәүләтгир Дәүләтбаевлар керә. Солтан Гәрәев, Фәрислам белән Нурислам Габделихсановлар, Шәйхенур Шәйхелисламовлар агач эше осталары буларак билгеле. 1917 елгы документта, ни сәбәпледер, Яңа Катайдан бары бер генә балта остасы (Галләметдин Сәйфетдинов) күрсәтелә.

Документта бер генә дегет җитештерүче – Фәррахетдин Мифтахетдинов кына теркәлгән. Әмма, картлар сөйләвенә караганда, Иске Катайдан Хаҗиәхмәт Мөхәммәтнәбиев, Мөхәммәтхарис Нурмөхәммәтовлар да дегет куганнар.

Сүз уңаеннан әйтик, әлеге һөнәр авылыбыз янындагы берничә урынның «дегет базы» дип аталуына сәбәпче булган. Кайчандыр каенлыклар булган ул җирләрдә, каен тузын яндырып, дегет куып ята торган булганнар.

Иске Катайдан Әбелфатыйх Гатиятуллин слесарь, тимерче буларак билгеле, аның Маты буенда алачыгы булган. Ул үзе кебекләрдән зур осталыгы белән аерылып торган, ат дагалау кадагына чаклы ясаган, заказга да эшләгән. Әсләм абый Кучумовның сөйләве буенча, Әбелфатыйхның алты улы (Фоат, Мигзам, Локман, Гыйльван, Кыйбан, Габделәхәт) була. Ул гаиләсе белән Чүмәлә Катайга күчә. Бертуганы Шәрифулла исемле, аның уллары Салих һәм Даһид була.

Иске Катайдан Мөхәммәтсолтан Сафин, Габдулла Галләмов сәүдә иткән. Гомәр Йосыпов ит сәүдәсе белән даими шөгыльләнгән. Яңа Катайда Петр Урусов, Шәяхмәт Дәүләтшин, Мөхәммәтзариф Яруллиннар кибет тотканнар – сәүдә иткәннәр. Иске Катайдан Фәррахетдин Шәйхетдинов сирәк һөнәр иясе – айгыр печүче булган.

Умартачылар, нигездә, Яңа Катайда күрсәтелә. Болар – Мөхәммәтсафи Габсаттаров (15 баш умартасы бар), Дәүләтгәрәй Миңлегәрәев (8), Шакир Латыйпов (7), Вәлиәхмәт Мөхәммәтгалин (2), Мөхәммәтнасыйх Җәмилев (1). Авылның урман-ялан-



нарга якын утыруы умартачылык өчен гаять уңай шартлар тудырган. Иске Катайда исә бу шөгыль өчен мондый ук уңайлыклар булмый. Шуңадыр, бары тик Әхмәтлатыйф Мөхәммәтнәбиев кенә 2 баш умарта тота.

Дөньялар ничек кенә, кайсы якка үзгәрмәсен, һөнәр һәрвакыт кешенең таянычы булган һәм булачак та. 1917 елдан соңгы чорга күз салыйк. Алдарак телгә алынган Заман карт егерменче-утызынчы елларда да итек теккән, умарта тоткан. Мулла булып та торган. Шәймөхәммәт Кәримов (әтиемнең әтисе) сугышка чаклы пычак, урак кебек тимер әйберләре ясау белән шөгыльләнгән, аны Бакалы базарына да алып чыгып сата торган булган (ул, алдарак әйтелгәнчә, берара итек, кәлүш тә теккән бит әле). Сакатта гомер иткән кардәшебез Нәҗип абый Мәҗитов бабамның өйрәнчеге булып йөргән, аннан шул авылның колхоз тимерчелегендә мөстәкыйль эшли башлаган. Җәмгыйтдин Кучумов, Гата Хафизовлар оста мебель ясаучылар булдылар. Җәмгыйтдин абый ясаган сандыклар әле дә шактый гына кешеләрдә бардыр. Хәсән абый Шакиров теккән туннар кышларын кемнәрне генә ачы салкыннардан сакламагандыр. Тегүчеләр, дигәннән, Кәшбел абый Әхмәтовны да күрсәтеп үтәргә кирәктер. Аңа сырма, пәлтә ише киемсалым тектерергә ярты авыл йөри иде. Гариф мулла һәм аның уллары Гавис, Әсләм, Мөстәкыйм Кучумовлар мич чыгаручы буларак дан тоттылар. Гавис абый, өстәвенә, сәгать тә төзәтә иде. Балта остасы Рим абый Нәбиев салган йортлар Катайда гына берничә дистәдер. Ат арбалары, тарантаслар, чаналар һәм тәгәрмәчләрне гел диярлек урман очы осталары (Шәйхеразыевлар һәм башкалар) ясый торган булдылар. Сугыштан соңгы елларда Әнгам агай Исмәгыйлев озак еллар такта яра.

Һөнәрнең беркайчан да артык булганы юк. Шуңа күрә яшьләргә, вакытыгызны заяга үткәрмәгез, җитеш тормыш итәр өчен күбрәк һөнәрләргә өйрәнергә тырышыгыз, дип әйтәсе килә. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, дип әйтә торган булган бит борынгылар. Һөнәрле булуның әһәмиятен чагылдыргандай, осталык – иң зур байлык, дип тә әйткәннәр. Үз эшенең, төрле һөнәрләрнең осталары күбрәк булган саен, җәмгыятебез дә алга китәчәк, тормыш итү шартлары да җиңеләячәк. ■

Икшермә чиркәве

Гөлүсә Закирова

Архивларда борынгы документлар актарып утырганда, кайчак шактый кызыклы язмалар да очрап куя. Миңа, мәсәлән, XIX гасырда Сабаның Икшермә төбәгендә чиркәү төзү, аны зурлап ачу вакыйгасы игътибарга лаек тоелды.

Унтугызынчы гасыр урталарында Мамадыш өязе Әбде волостеның Иске Икшермә авылында җәмгысе 890 кеше гомер кичерә. Алар – татарлар, урыслар һәм керәшеннәр. Шул вакытка кадәр авылда чиркәү булмый, христиан дине вәкилләре Әбде чиркәвенә йөри, шунда метрика кенәгәләрендә исәпләнә, Әбде зиратына җирләнә. Әмма төбәктә ваба авыруы (холера) котыра башлагач, Икшермәдә урыс һәм керәшен зиратлары барлыкка килә.

Чиркәү төзү 1891 елда тормышка ашырыла. Май аенда нигез салып, сентябрьдә, изгеләштереп, ачалар да. Гадәти генә вакыйга булмый ул, Казан архиепископы изге Павел атакай авылга үзе кайта!

Бу хакта миссионер Е.Малов «Казан епархия хәбәрләре» газетасында мәкаләләр

Түбәлере салам, кабык төшмәгән, ә мәчет манаралары киселгән

бастыра (1891 ел, №15, №22), «Мөхәммәт өммәтендәгеләр һәм керәшен татарлары арасындагы миссионерлык» дип исемләнгән җыентык (Казан Император университеты басмаханәсе, 1892 ел) та нәшер итә. Гыйбадәтханә салуга сәбәпләре җитди: авылда чукындырылган утыз гаилә (169 кеше!) кире мөселман диненә кайткан. Миссионер язуынча, Икшермә – бу төбәктә икеләнгән керәшен татарлары һәм христианлыктан ваз кичкәннәр арасында христианлыкны ныгыту өчен бик мөһим пункт. Шуңа күрә Епархиаль җитәкчелек күрше Елыш авылында чиркәү өлгертүне дә ашыктыра, Иске Икшермәдә чиркәү салуны да кичектерергә ярамый, ди. Менә бит, озакка сузып тормыйлар. Изгеләштерү тантанасына Казан архиепископы изге Павел атакай үзе белән бер төркем яраннарын да ияртеп кайта. Алар арасында Казан Академиясенең Мөхәммәт өммәтенә каршы миссионер укытучылары – протоиерей Евфимий Малов һәм керәшен татары булган рухани Василий Тимофеев, собор ачкыччысы, протоиерей П.Миловидов, протодьякон, ике иподьякон һәм биш чиркәү җырчысы да була.

Чиркәүне изгеләштерү 8 сентябрьгә билгеләнә. Кунаклар бер көн алда, 7 сентябрьдә өйләдән соң – сәгать дүртләр тирәсендә кайтып төшәләр. Халык аларны иртә таңнан төрле урыннарда көтә. Күпчелеге Елыш ягыннан килгән юлга караган зур булмаган кәшәнә (часовня) капкасы янында туплана. Владыка нәкъ менә шул яктан киләчәк, дип фаразлаучылар төркеме була бу. Ак эскәтер ябылган өстәл куйганнар, табында – Архипастырьга авыз итәргә тәгаенләнгән ипи-тоз. Шунда ук урыс һәм керәшен татарлары хатыннары тукып чиккән төрле сөлгеләр тора. Халыкның бер өлеше яңа салынган чиркәүне урап алган. Болар – Архипастырь, килү белән, шунда ук чиркәүгә юл тотар, диючеләр. Ниятләре – изге атакай фатихасын алып калу. Әмма бу көнне атакайны төн кунар өчен әзерләнгән фатир янында көтүчеләр бәхетлерәк булып чыга. Чөнки ул монда килү юлында кергән төрле авыл чиркәүләрендә, басуларда очраган православ кардәшләрен чукындырып йөреп арыган була, шуңа күрә, Иске Икшермәгә керүгә, туп-туры төн кунар урынына юл тота. Әмма монда да аны бер төркем урыслар, керәшен татарлары каршы ала.

Тантаналы вакыйга кичке сәгать җиде тулгач башлана. Чиркәүнең алтарьдан башка урыннары җиренә җиткереп изгеләштерелә. Анда кафедраль протоиерей Е.Малов, Казаннан керәшен татарлары дин мөгаллиме В.Тимофеев, җирле дин әһеле Н.Боголюбов, Әбде чиркәве рухание К.Богоявленский, шул ук авылдан керәшен татары булган дин әһеле Н.Прокофьев, Албай (Әрнәш) авылыннан килгән рухани А.Тихомиров, Иске Икшермә атакае П.Матвеевский, Юмья авылы рухание – керәшен татары Назарий Герасимовлар катнаша.

Төнге дини хезмәт күрсәтүдә уң якта – Архиерей чиркәү җырчылары, ә сул якта – Елыш һәм Иске Икшермә приход мәктәбенә йөрүче керәшен татар малайлары һәм кызлары хоры җырлый (татарча җырлыйлар!). Чиркәү исемен йөрткән Изге Николайга багышлап догалар укыла. Табыну вакытында чиркәүнең ян ишекләрен ачып куялар: бу бераз һава алмашынсын, храм җилләнсен өчен һәм килгән кешеләргә керергә-чыгарга уңайлы булсын өчен эшләнә. Әлеге вакыйга төнге сәгать уннарга кадәр бара. Ә зәйтүн мае белән майлау төнге унберләргә кадәр дәвам итә.

8 сентябрь иртәсендә чиркәү изге су белән изгеләштерелә. Изгеләштерү иртәнге сәгать унда башлана. Анысын Казан архиепископы изге Павел атакай башкара. Әлеге вакыйгада кафедраль протоиерей Е.Малов, собор ачкыччысы – протоиерей П.Миловидов, дин мөгаллиме В.Тимофеев, җирле дин әһеле Н.Боголюбов, Зөя өязенең Теньки авылы атакае И.Матвеевский, Әбде чиркәве рухание К.Богоявленский, шул ук авылдан керәшен татары булган дин әһеле Н.Прокофьев, Албай-Әрнәш авылы рухание А.Тихомиров, Елыш авылы рухание – керәшен татары Сергей Кузьмин, Юмья авылы

Икшермә авылының планы

рухание – керәшен татары Н.Герасимов, Иске Икшермә атакае П.Матвеевский, протодьякон И.Гранский, Кафедраль собор дьяконы Н.Степанов, Әбде авылы дьяконы, Арташ авылы дьяконы – керәшен татары Феодор Романов һәм үз псаломчылары белән башка дьяконнар катнаша.

Храмны изгеләштергән дини литургия алдыннан изге Павел атакай христиан храмының бу авылга бик кирәклеген, мөһимлеген әйтеп уза. Аның чыгышыннан бер өземтә: «Мәҗүсиләрнең үз храмнары булган, әмма без аларны берничек тә храм дип атый алмыйбыз, – ди ул, – алар фәкать потка табыну гыйбадәтханәләре генә. Мөселманнарның мәчетләре бар, әмма мәчетләрне шулай ук храм дип атап булмый, алар – дога кылу урыны гына. Яһүдиләр храмнары бер Аллаһка (Бог) багышлап төзелсә дә, христиан храмнары кебек әһәмиятле түгел. Мәҗүсиләр гыйбадәтханәләрендә бернинди изге нәрсә юк, фәкать җирәндергеч потлар гына».

Аннан изге атакай яһүд храмнары турындагы фикерләре белән уртаклаша. Сүзен исә керәшен татарларына атап тәмамлый: «Мөселманнар тәэсиренә бирелмәс өчен, чиркәүгә ешрак йөрегез», – ди. Чиркәүдә сөйләгәннәрнең барысын да тыңлап барырга, карусыз үтәргә киңәш итә. Чиркәүне изгеләштергән вакытта архиерей җырчылары гына җырлый.

Литургиядән соң, Казанның Изге Ана рухына дога кылалар. Аның алдыннан чиркәү хуҗалары Казан атакаена олы рәхмәт сүзләре ирештерә. Павел атакайдан Казанның Изге Анасы иконасы каршына ук басуын сорыйлар. Барысы да яңа төзелгән һәм изгеләштерелгән храмның һәйкәл генә түгел, ә христиан дине училищесы булып торуын, урысларның гына түгел, керәшен татарларының да ышанычы ныгуын теләп чукына, иконаны үбә. Чиркәүдә башкарырга тиешле гамәлләрнең барысын да кылгач, христианнар ишеккә юнәлә. Һәр килгән кешегә Павел атакай үзе төзегән брошюра тарата.

Бу вакыйгага башка ерак авыллардан да килүчеләр була. Халык Архипастырьны кунак йортына – чиркәү старостасы, хөрмәтле аксакал Даниил Федорович өенә кадәр озата кайта. Йорт каршында киң киез паласлар җәелгән, ә аңа яңа өзеп алынган яшел, хуш исле ак чыршы (пихта) ботаклары сибелгән. Казаннан килгән изге атакайга сый-хөрмәт тә әлеге йортта күрсәтелә. Аш өстәленә Мамадыш исправнигы А.Спасский, Лаеш исправнигы Н.Покровский, суд тикшерүчесе Н.Ридман, становой Л.Васильков һәм Львов шәһәре становое да чакырыла. Кутәренке кәеф белән күңел ачалар, тостлар

әйтәләр, бөек Императорга да рәхмәтләр яудыралар. Павел атакайның, христиан динен кабул итүчеләр арасында русча сөйләшүне кертергә һәм аларга рус милли киемнәрен кидертергә кирәк, дигән сүзләрен алкышлап хуплыйлар.

Иске Икшермәдәге бу вакыйга әнә шулай тәмамлана.

Иске Икшермә чиркәве – агачтан, түбәсе исә калай белән ябылган. Бер престолы Изге Николай исеме белән аталган. Бу исем бирелүнең үз тарихы бар. Изге Павел атакай ачкыччы П.Миловидовка Иске Икшермә авылында чиркәү салырлык хәйрияче табарга боера. Тегесе иганәче – Казанның беренче гильдия сәүдәгәре Павел Васильевич Щетинкинга мөрәҗәгать итә һәм, ни гаҗәп, ул Иске Икшермәдә чиркәү төзергә бик теләп ризалык бирә – төшемдә Изге Николайны күрдем, ул миңа храм төзергә кушкан иде, ди. Тагын бер кызыклы документтан – 1921 елда Казанда педагогика техникумының өлкән әзерлек курсларында укып йөргән Мария Макарованың (күрше Өч Нарат авылы кызы!) 17 сентябрьдә язган этнография язмаларыннан өзек тәкъдим итәм (ЧР Милли архивы, 1 нче бүлек, Н.В. Никольский фонды, 309 нчы саклау берәмлеге, 47-48 б.): «1887 елның 10 июлендә авылда бик көчле яңгыр ява. Шул вакытта ташу аккан инеш үзәнлегендә бакырга нәкышләп ясалган Изге Николай (Николай Чудотворец) иконасы табыла. Гаҗәеп икона булып чыга ул, каршында дога кылганнан соң, алты очракта шундук дәва табалар, ундүрт очракта – күпмедер вакыт үткәч. Өч Нарат авылында изге икона табылганда Көек авылында (Иске Икшермә авылының тагын бер исеме. – Г.З.) чиркәү юк иде әле, хәзер инде храм бар».

Генерал (ызанлау) планының бер өлеше.
Казан губернасының Мамадыш өязе. 1798 ел

Иске Икшермә чиркәве таш нигезле агач койма белән тотып алынган. Чиркәүдән аз гына читтәрәк – агачтан эшләнгән чиркәү каравылчысы корылмасы. Храм үзе якты һәм җылы, тимер белән каймалап алынган түгәрәк өч мич тора. Иконастас чиркәүдән керүгә үк күзгә ташлана. Иконалар бар да православ рухта матур итеп эшләнгән. Авторы – рәссам В.Семенов. Чиркәүдә халыкка дини хезмәт күрсәтү өчен кирәк-яраклар җитәрлек. Рухани итеп Павел Иванович Матвеевский билгеләнә.

Яшәешнең үз кануннары: кайчандыр көчле ташудан соң изге табыну чарасы табылган кебек, булганнарның кинәт кенә юкка чыга торган гадәте дә бар. Иске Икшермә халкы чиркәү булу турында хәтерләми инде. Өлкәнрәк буын, элек чиркәү булган бинада совет чорында хастаханә эшләде, аннан бала табу йорты иттеләр, дип кенә сөйли. Әмма хәтер бар. Иске Икшермә белән бәйле шактый «табышларымны» китабымда очратырсыз. ■

«Яңа милли юл»

«Яңа милли юл» – 1928 елның декабреннән 1939 елның октябренә кадәр (1930 елга кадәр «Милли юл») Берлинда һәм Варшавада нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси, фәнни-әдәби журнал. Барлыгы 136 саны дөнья күргән. Журналның баш мөхәррире һәм нашире – Гаяз Исхакый. Төрле саннарда басма турында: *«Ирекле ил өчен тартышучы айлык бер мәҗмуга», «Дөньяның җиде почмагында таралган милләтче мөһаҗирләр арасында берсен-берсе таныштыра торган бердәнбер мәҗмуга», «Идел-Уралның котылуына ярдәм иттектә тырышучы вә хәбәрләрне яза торган айлык мәҗмуга», «Милли дәгъвабыз өчен бердәнбер тырышучы, тартышучы...»* – дип язылган. Автор һәм мәкаләләргә килгәндә, журналда: *«Идел-Урал истикъляльна (азатлыгына) хидмәт итүче, илнең һәм халыкның матди вә мәгънәви барлыгы һәм аның киләчәге тугрындагы фикерләрне эченә алган һәрбер язма өчен мәҗмуга эшләре һәркемгә ачык»*, – диелгән. Шуннан аңлашылганча, «Яңа милли юл»ның төп мәсләге – татар халкының азатлыгы, бәйсезлеге өчен көрәшү. Анда халкыбызның тарихы, милли үзаңы, милли мәгарифен, этник үзенчәлекләрен саклап калу турында Г.Исхакый, С.Гыйффәт, З.Кадыйри, Х.Габдүш, Р.Мөхәммәдиш, Л.Каран һәм башкаларның мәкаләләре басылган.



«Яңа милли юл». 1993. – №2.
Милли берлек һәм милли барлык мәсьәләләре – алар һичбер вакыт икенче урынга калдырыла торган мәсьәләләр түгел. Гыйсмәт паша

Журнал, Германия һәм Польшадан кала, Кытай, Япония, Төркия, Финляндия, Румыния, Мисырда таралган һәм шунда яшәүче милләттәшләребез тормышындагы вакыйгаларны яктырткан.

Тәкъдим ителгән мәкаләләр «Яңа милли юл»ның ТР Милли китапханәсендә саклаучы нөсхәләреннән алынды*.

*Без файдаланган саннарны китапханәгә язучы Фәүзия Бәйрәмова бүләк итеп тапшырган иде. Бу турыда журналыбызның 2017 елгы июль санынннан укырга мөмкин. «Яңа милли юл» журналы турында тәфсиллерәк итеп Хатыйп Миңнегуловның «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» исемле китабыннан (2004) укып белә аласыз.

БЕРЛИНДА РАМАЗАН БӘЙРӘМЕ

Мәхәллә имамы тарафыннан бәйрәмнән берничә көн әүвәл чакыру хатлары таратылып, 6 гыйнварда монда яшәүче төрек-татарлар һәм башка милләтләрдән булган дин кардәшләребез, һиндстанлылар тарафыннан салдырылган һәм идарә ителгән мәчеткә җыелып, гает намазы укыдылар. Гает намазы бик яхшы кичте. Бик күп кеше җыелган иде. Безнең милләтче илдәшләребезнең үтенечләре буенча, мәхәллә имамы (һиндстанлы) доктор Габдулла әфәнде, хөтбәдән соң, Русиядәге дин кардәшләрен искә алып: *«Бүген бу олуг бәйрәм көнен бөтен дөньяда булган өч йөз миллионнан артык мөселманнар шатлык берлә каршылап бәйрәм итәләр дияргә теләсәм дә, кызганычка каршы, боларның утыз миллионлык бер кыйсеме бүген большевиклар кул астында вә динсез коммунистларның вәхши рәвештә җәбер-золым итүләре аркасында алар бу көнне үзләре теләгәнчә каршы алып бәйрәм итә алмыйлар»,* – дип сөйләп, илдәшебез Мөхибулла әфәнде Хөсәеннең Коръән укуын үтенде. Мөхибулла әфәнде бик матур мәкам берлә Коръән укып, илебездәге халкыбызның бу бәладән тиз көннәрдә котылуын теләп, бөтен җәмәгать кул күтәреп дога кылды. Дога кылганда безнең илдәшләребез өчен күз яшьләрен агызырлык кайгылы булды.

Соңрак, имамның үтенече буенча, һәр милләттән бер вәкил мөнбәр янына чыгып, үз телләрендә кыска-кыска тәбрик нотыклары сөйләделәр. Безнең илдәшләребездән Фуад әфәнде Казак үзенең тәбрик нотыгында, илдәшләребезгә каратып: *«Үз илебездәге халкыбыз бу көндә большевикларның җәбер-золымнары астында дәһшәтле рәвештә ачялангач, бер телем икмәккә мохтаҗлар. Шул мөбарәк бәйрәмдә аларны хәтерләвегезне үтенәм, халкыбызның бу авыр көннән тизлектә котылып үзе теләгәнчә яшәп, үзе теләгәнчә бәйрәм итүенә дога кылуыгызны үтенәм...»* – дип сөйләде. Шәркый Төркестан җөмһүрияте еглуы төрек дөньясы өчен бик зур югалту булуын сөйләп узды. Башка милләт вәкилләренең дә нотыкларында Русиядәге дин кардәшләрен искә алып сөйләүләре аңлашылды. Хәтта ул телне белмәгәннәргә дә аңларлык, кайгырганнарын

Берлиндагы «Әхмәдия» мәчете. 1923-1925 елларда төзелгән

йөзләренең чыраеннан күреп була иде. Барысы да бер-берсенең кулларын кысып тәбрикләшкәннән соң, безнең илдәшләрнең бер өлеше, үлеләрен искә алып, шәһәрнең икенче бер тарафында булган каберстанга бардылар, анда, һич булмаса, үз күзе берлә күреп вә үз куллары берлә җир астына күмгән илдәшләренең кабере өстенә чәчкәләр куеп, Коръән укып, үлеләргә багышлап дога кылдылар. Гарифә туташ Йосыфның каберен күреп кәефсезләнделәр вә: *«Бу туташ Харбинда бер хәлле гаиләдән иде. Анда язарга кирәк, бәлки акча җибәрерләр. Без дә, шатланып, кабергә таш куярга килер идек. Ауропада укыган милләттәшләрнең каберен ташсыз бу рәвештә күрү безнең өчен бик авыр»,* – диештеләр.

Соңрак берничә илдәшләребез тарафыннан хәзерләнгән чәй мәҗлесләренә йөреп, сыйланып, кич тагы мәчеткә бардылар. Анда бәйрәм програмында булган ике конферанс (алман телендә) тыңланды. Тагы мәхәллә имамы Габдулла әфәнде үтенече буенча, Мөхибулла әфәнде тарафыннан Коръән укылды. Мөхибулла әфәнденең мәкаме безнең илебездә укыла торган мәкам булып, башка милләт мөселманнарына бик ошады. Соңра мәчет бинасында кунакларга чәй бирелде. Үзара сөйләшеп, кунаклар да безнең илдәшләрдән, илебез вә халкыбызның тормышыннан сорашып, мәҗлес бик озак дәвам итте. Бу бәйрәм мөнәсәбәте берлә башка милләтләр арасында үткәргән мәҗлесләрдә безнең илдәшләр үзләренең милләтче, илен, халкын сөюче, диндар вә мәдәниятле халык булганнарын мондагы башка милләт кешеләренә тагы якынрак таныштырдылар.

Инде кадерле илебез, халкыбыз тиз көннәрдә бу авырлыклардан котылып, киләчәк бәйрәмнәрне үз илебездә, үзебез теләгәнчә шатлык берлә каршы алырга насыйп булсын, дип Тәңредән сорыйбыз.

Хәлил Тимербулат

Яңа милли юл. – 1935. – №2 (85). – Б.22-24.

КАҺИРӘДӘ ТУКАЙ КӨНЕ

Без, Әзһәрдә укучы Идел-Урал шәкертләре, саныбыз күп булмаса да[1], милли көннәрне сызып үтәбез. Шул җөмләдән бу ел апрельнең 15ендә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулуы мөнәсәбәте берлә бу бөек көнне сызып бер мәрәсим уздырдык. Мәрәсимгә кырымлы, төркестанлы кардәшләребез, илдәшләребез Хәмзә Таһир бәк, Әзһәрдә төрек шөгъбәсенең рәисе Габделхәмид Таһир бәк чакырылган иде. Мәрәсим бүлмәсе бөек юлбашчыбыз Гаяз бәк Исхакый, бөек төрекче мәрхүм Йосыф бәк Акчура вә искә алучы шагыйребезнең рәсемнәре берлә бизәлгән иде. Мәҗлесебез сәгать 3 ярымда, чакырылган затларның һәммәсе килгәч, Галиулла Агишның кереш сүзе берлә башланды. Ул сүзенең ахырында төркестанлы Сөләйман әфәндедән шагыйребез рухына Коръән укуын үтенде. Сөләйман әфәнде бик матур мәкам берлә Коръән укып, шагыйребезнең рух шәрифенә багышлады. Коръән укылгач, Ибраһим Хәсән тарафыннан авыз гармунында уйналган «Сөембикә маршы» җыелганнар тарафыннан аякка калкып тыңланылды. Моннан соң сүзләр башланды.

Галиулла Агиш Тукайның тәрҗемәи хәлен укып, бөек шагыйребезнең гомере буе рәхәт күрмәвен, шулай булса да, сәламәтлеген югалткач та, ахыр сулышына кадәр шигырьләр язып, халыкны сәгадәткә ирештерергә тырышуын аңлатып, Тукайны онытмаска, шигырьләрен күбрәк укырга киңәш итте вә җыелганнар тарафыннан бик алкышланды.

[1] Андагы шәкертләрнең бер өлеше, шул ук мәкаләдә телгә алынган Габделәхәд Тенешев та Ерак Шәрык Идел-Урал төрек-татарлары мәдәни җәмгыяте иганәсенә дин гыйлемен өйрәнергә Каһирәгә җибәрелгән.

Габделәхәд Тенешев Тукайның иҗатыннан бәхәс итеп, аның төрек-татар әдәбиятында тоткан урыны, төрек-татар милләтенең уйгануында уйнаган гаять зур роле хакында тәфсыйлле мәгълүмат бирде вә шулай ук бик алкышланды. Бу нотыклардан бик тәэсирле булганы – Габлелхәмид Таһир бәк сүз алып, мондый бөек шагыйрьгә ия булган төрек-татарларның тиз көндә кызыл җәлладләр кулыннан котылуына ышануын белдерде.

Моннан соң кырымлылар исеменнән Рәсим әфәнде Туган, төркестанлылар исеменнән Сөләйман әфәнде Мөхәммәд Ибраһим сүзләр алып, илебездән читтә шундый мәҗлесләр тәртип итүебез өчен рәхмәтләрен белдерделәр вә киләчәктә шундый мәрәсимнәрне дошман кулыннан котылган илләрдә уздыруны бөек Тәңредән теләделәр.

Бу сүзләрдән соң, Ибраһим Хәсәннең бик оста итеп гармунда уйнаганы хәлдә, күмәкләп «Туган тел», «Милли моңнар» җырланды вә бик алкышланды. Кырымлы кардәшләребез, «Кырым маршы», «Ант эткенмен»не[2] җырлап мәҗлескә җанлылык керттеләр. Габделәхәд Тенешев үзенең соңгы сүзендә мәҗлеснең рәсми өлеше тәмам булуын игълан итеп, кимчелекләребез булса, җыелганнар гафу итүне үтенде вә тиз көндә газиз илләребезнең бәйсезлеген теләп сүзен бетерде вә аякка калкып тыңланган «Сөембикә маршы» уйналу берлә бу милли рухлы мәҗлес тәмам булды.

«Яшь истикъляльче»
Яңа милли юл. – 1938. – №6 (123). – Б.28-29.

ЯПОНИЯДӘ МИЛЛИ БАРЛЫК[3]

...Гаяз бәк 35 ел дәвам иттергән юлыннан бер адымга да тайпылмады. Төрле тыюларга карамыйча, Япониядә яшәүче төрек-татарлар өстенә ташланган пычракларны юарга кереште, халыкны милли берләштерергә, Идел-Урал җәмгыятьләре төзергә, корылтай тупланышы ясаганда япон әфкяре гомумиясен таныштыру юлында да зур

Токиода төрек-татар мәктәбенең бинасы каршында. Фотода Гаяз Исхакый, Габделхәй Корбангали һәм Габдерәшид Ибраһим да бар. 1933 ел

[2] «Ант эткенмен» – кырым татарларының милли гимны. Авторы – Номан Чәләбиҗиһан.
[3] Мәкаләне кыскартып бирәбез. Аның башында Япония татарларының лидеры Габделхәй хәзрәт Корбангалинең эшчәнлеге тәнкыйтьләнә. Ул «Ислам берлеге» һәм «ислам-япон дуслыгы» идеяләре яклы булган. Г.Исхакый – милли азатлык тарафдары. Г.Корбангали белән Г.Исхакый арасындагы фикри каршылык шәхси дошманлыкка кадәр үсә.

Утырганнар: сулдан уңга – Сабирҗан Мөхәммәдиш, Кәфия Хәбибрахман, Гаяз Исхакый, Өркыя Мөхәммәдиш. Токио, 1934 ел, 15 апрель

уңышлар казана белде. Төрле мәҗмугаләр, җәмгыятьлар төрек-татар җитәкчесен, шәрык халкының танылган әдибен, мөхәррирен ишетер өчен, Гаяз бәктән конферанслар бирүен үтенделәр. Гаяз бәк тә бу үтенечләрне кабул итеп, төрек милләтенең әүвәлге һәм хәзерге хәленнән, киләчәк хәрәкәтеннән конферанслар бирә башлады. Беренче конферансын «Шәрык» җәмгыятендә, шәрык хәлләренең белгечләре тупланышында укыды. Бу конферанс «Тойо» (東洋 – Шәрык) мәҗмугасында икегә бүленеп, апрель-май (1934) нөсхәләрендә басылып чыкты. Моннан соң «Туран» җәмгыятенең зур тупланышында шул ук эчтәлектә җанлы бер конферанс укыды. «Дзэн-рин кёкай» (善隣協会 – Күрше милләтләр берлә дустлык ясау) җәмгыяте, Гаяз бәкнең тәфсыйлле конферансынан соң, «Идел-Урал» китабын япончага тәрҗемә итеп, аена бер мәртәбә чыга торган мәҗмугасында бишкә бүлеп биш ай эчендә нәшер итте. «Исураму шококу но хэнсэн» (イスラム諸国の変遷 – Ислам дәүләтләрендә алмашыну) исемендәге профессор Окубоның китабында төрек-татар халкы хакында озын мәгълүмат бирелде. Япониянең мөгтәбәр гәзитләре «Нити-нити» (日日), «Асахи» (朝日), «Дзи-дзи» (時事) вә башкалар төрек-татар хәрәкәтенә, Япониядәге милли-мәдәни эшләребезгә зур әһәмият биреп, еш-еш язып киләләр. Япон әфкяре гомумиясе төрле яктан төрек-татар хәрәкәте берлә таныша башлады. Мәсьәләләре ачык юлга салынгач, Япониянең иң мөһим җәмгыятьләренең берсе булган «Pan-pacific club» Гаяз бәктән конференс бирүен үтенде. Бу җәмгыятьнең 80 % әгъзасы америкалы, инглиз, чинлы, рус вә башка милләтләр булганга, конферанс шундук инглизчәгә тәрҗемә ителде. Харита буенча төрек халкының үткәне, хәзерге һәм киләчәк хәле бәян ителде. Дөнья тынычлыгын бозучы коммунистларга, русның агына, кызылына һәм карасына нык һөҗүм ителде. Шул мәҗлестә булган рус сәфарәт *(илчелек)* әгъзалары, бу һөҗүмне ишетү берлә, залдан чыгып китсәләр дә, японнар вә әҗнәбиләр *(чит ил кешеләре)* Гаяз бәккә рәхмәтләр укып, бик озак алкышладылар. Иртәгесен инглиз телендә чыга торган «Times» («The Japan times»), «Japanese advertiser»

(«The Japan advertiser») гәзитләрендә тулы көенчә басылып, русларның агын, кызылын тынычсызлыкка төшерергә сәбәп булды. Ишетелүгә караганда, «Pan-pacific club»ының рәисенә совет сәфире рәсми протест биреп: «Ул ак рустан ник алай сөйләтәсез?» – дигән булса да, рәис бәк: «Сез ялгышасыз, ул – рус түгел, ул – төрек, ул – шәрык халкының җитәкчес», – дип озын сүз көрәштергән. Бу конферансларның япон әфкяр гомумиясенә тәэсире бөтенләй башка булды. Моңа кадәр әҗнәбиләр вә руслардан гына мәгълүмат алып килгән япон әфкяре гомумиясе төрек-татар дөньясына бөтенләй башка күз берлә карый башлады. Бу конферанслар Идел-Урал җөмһүриятенең мәдәни хәрәкәтләре, Кобэда булып узган корылтай[4], төрек матбугатыннан алынган тәрҗемәләр, «Япон мөхбире»нең төрек-татар халкы рус йодрыгыннан башка яши алмый, дигән лыгырдамаларын юкка чыгарып, көлкегә калдырдылар, тагы да якынрак танышу теләкләрен тудырдылар. Япон империясенең танылган милләт хадимнәре, Тояма баба вә аның тирәсендәге милли җәмгыять рәисләре Гаяз бәк берлә озын утырышларда кардәшчә сөйләшеп, төрек-татар халкына аерым бер хөрмәтле урын биргәннәрен аңлаттылар. Танышлыкны даими иттерер өчен, мәҗмуга чыгарырга, киң япон дөньясына таратырга кирәк, дигән сүзләр сөйләнде. Рус исемен күтәреп йөрүдән туеп беткәнгә, Японядә яшәүче төрек-татарларның беренче корылтае сайлап куйган мәркәз идарә баш полис (Police) идарәсенә бу хакта мөрәҗәгать итеп, үзенең түбәндәге теләкләрен тәкъдим итте:

1. Идел-Урал җәмгыятьләре әгъзаларын рус дип санап йөрмәскә.
2. Исемнәренең азагына кушылган «оф»ларны алып ташларга.
3. Бу җәмгыятьләрнең эшләрен рус шөгъбәсеннән *(бүлегеннән)* чыгарып, аерым бер шөгъбәгә кую.
4. Полис мәэмүрләре *(полиция түрәләре)* төрек-татарлар берлә мөгамәлләдә моңа кадәр рус телен кулансалар да, моннан соң японча йә инглизчә сөйләшү.
5. Һәрбер эштә мәркәз идарәгә генә мөрәҗәгать итеп, Корбангали кебиләргә төрек-татар вәкиле дип карамау.
6. Милли-мәдәни эшләрне тыныч кына алып баруда мәгънәви ярдәм бирү.

Бу теләкләр полис тарафыннан кабул ителеп, «Нити-нити» (日日) гәзитәсендә басылып чыкты. 10-12 ел Япониядә яшәп үз-үзләрен таныта алмаган, милли барлыкларын сакларга тугры юл таба алмый гаҗиз калган Идел-Ураллы мөһаҗирләр, Гаяз бәкнең берләштерүе вә япон әфкяре гомумисенә киң рәвештә танытуы аркасында күптән эзләгән барлыкларын таптылар. Япониядәге төрек-татарларның муәффәкыяте Манҗурия һәм Кытайда яшәүче кардәшләргә дә зур тәэсир итте. Алар да Идел-Урал җәмгыятьләре төзи вә Гаяз бәкне сабырсызланып көтә башладылар. Япониядә яшәүче милләтчеләрне бер байрак астына җыйган корылтай кеби милли тупланыш Манҗурияда да, Кытайда да ясалачак. Болар, берләшеп, бөтен Ерак Шәрык корылтаен чакырып, юлсыз бара торган Ерак Шәрыктәге эшләребезне Япониядәге кеби тугры юлга салачаклардыр.

Өркыя Мөхәммәдиш[5], Токио
Яңа милли юл. – 1934. – №9 (80). – Б.19-23.
Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

---

[4] 1934 елның 9-12 май көннәрендә Кобе шәһәрендә Япония һәм Кореядә яшәүче төрки-татарларның корылтае узган.
[5] Өркыя Мөхәммәдиш – әдип, публицист, инглиз теле мөгаллиме. Япониядә Гаяз Исхакый сөйләгәннәрне инглиз теленә тәрҗемә итә.

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН ҮРНӘКЛӘР

КЕМ УЛ ПУРХИ АХВАН?

Сәхифәне Ләбиб Лерон алып бара

Чуашстанның М.Сеспель исемендәге Республика премиясе лауреаты (1982), Чуашстан Республикасының Дәүләт премиясе иясе (2001), И.Я.Яковлев (2002) һәм Фатих Кәрим исемендәге (1998) премияләр лауреаты, Чуашстан Республикасының халык шагыйре, тәрҗемәче, журналист Порфирий Васильевич Афанасьев (Пурхи Ахван) 1942 елның 20 февралендә Татарстан Республикасының Чирмешән районындагы Яңа Ильмово авылында чуаш гаиләсендә туа.

Сүз уңаеннан, совет һәм беларусь кинорежиссеры, сценарист, язучы Дмитрий Никанорович Михлеев та чыгышы белән шушы авылдан.

Пурхи Ахван 1976 елда КПССС Үзәк комитеты каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый.

1959 елда Казанда «Херле ялав» («Кызыл байрак») газетасында әдәби хезмәткәр буларак тәүге хезмәт юлын башлый.

1960-1964 елларда Казан педагогика институтында белем алгач, туган авылына кайтып, балалар укыта.

1977-1985 елларда «Хатер пул» («Будь готов») журналының баш мөхәррире булып эшли.

1985-1986 елларда Чуашстан китап нәшрияты директоры вазыйфасын башкара.

1986-1990 елларда Чуашстан Язучылар идарәсенең рәисе.

У.Шекспир, М.Шолохов, Ф.Достоевский, Л.Леонов, В.Распутин, шулай ук безнең шагыйрьләребез Г.Тукай, Һ.Такташ, Р.Харис, Р.Фәйзуллин шигырьләре чуаш укучысына иң әүвәл Порфирий Афанасьев тәрҗемәсендә барып иреште.

Порфирий Афанасьев шигыре



***

Нинди тылсым бу?!
Нинди могҗиза!.. -
Ак урам буйлап
Оча ак тулпар.
Чатнама суык,
Ә йөрәкләрдә
Ут яна, дөрли
Безнең шатлыклар!

Саубуллашабыз,
Гүя озатып,
Кул болгап калган
Яшьлекстан белән...
Янәшәмдәге
сөйгән ярымның
Керфекләрендә
Эри кар, көлә...

Моңсуланулар ят бүген безгә:
Җыр тыңлыйк, әйдә,
Күңелле көе!
Оча ак тулпар...
Безнең сөюнең
Шат авазларын
Күкләргә чөеп!

Яз килер тиздән...

***Л.Лерон** тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №7 июль 2018

ЧУАШЛАР*

Зариф Бәшири

ЧУАШЛАРНЫҢ ДИННӘРЕ ВӘ ИСКЕ ӘСӘРЛӘРЕ

Тарих сәхифәләрендә хакыйкатьләре мәгълүм булмаган милләтләрнең бере дә чуаш кавемедер. Тарих бу милләтнең кайдан таралдыгын белергә мохтаҗ бер хәлдәдер. Чуашларның нәселләрен, асылларын белер өчен, гадәтләрен вә иске әсәрләрен тикшерергә тиешле. Анлар турында мәгълүмат җыеп шөгыльләнүчеләр бу көннәрдә бар. Мәгълүмат җыючылар өчен бер файда булмасмы, дип, мин дә үз белгәннәремне «Шура» ярдәме илә белдермәкче булдым. Мин монда чуашларның иң күп җирләре булган Чуел *(Цивиль.* – **Ред.***)*, Чабаксар, Тәтеш, Буа, Зөя өязләрендәге чуашлар турында сөйләмәктәмен.

Чуашлар хакында мәҗүсиләр, мөшрикләр дип халык арасында бер фикер таралмыш исә дә – хатадыр. Чуашлар Аллаһы Тәгаләнең барлыгы вә берлеген икърар итәрләр вә моның өстенә Нух пәйгамбәрне Аллаһы Тәгаләнең рәсүле дип игътикад әйләрләр. Мин югарыда телгә алган өязләрнең барында да йөрдем вә ошбу игътикадның хилафында булган чуашларга очрамадым вә орлыкларын да ишетмәдем.

Чуашлар бу көндә гомумият илә христиан мәзһәбен кабул итмешләр исә дә, һаман да Нух пәйгамбәрне олыларлар вә аның сөннәте дип игътикад итмеш шәйләрне мөкатдәс санамакталардыр. Араларында чукынмаган чуашлар да бар. Болар исә Аллаһы Тәгаләне бер дип игътикад итәрләр.

Чуашларның Нух пәйгамбәр сөннәте дип санаган шәйләре – җәй вакыты үзләренең мөкатдәс хисап иткән көннәрендә кырга чыгып үрдәк, казны корбан чалмактан вә мазарлыкка *(каберлеккә)* барып чүп чүпләмәктән гыйбарәттер. Чүп чүпләмәкләре көннең төш вакытларында, үзләренең якыннары яннарына утырып бертөрле үлән орлыгын җиргә сачмәк вә соңрадан шуны чүпләмәктер.

Чуашлар арасында ислам гадәте буенча ураза тотучылар, сарык вә кәҗәләрне корбан бугазлаучылар бар.

Чуашларның чукынганнары икегә бүленеп, бере – татардан чукынган вә икенчесе чуаштан чукынган дип аталалар.

Татардан чукынган чуашлар җөмләсеннән Чуел өязе Рум *(Ырым, Урум, Үрем.* – **Ред.***)* суы буендагы Хуҗа Хәсән (гавам арасында «Күләсән» (Куясан. – **Ред.**) дип йөртелмәктәдер карьясендә Хуҗа Хәсән исемендә бер изге кабере бардыр[1]. Чуашлар бу каберне соң дәрәҗәдә ихтирам кылалар. Тирәсен яхшы итеп ихаталаган-

*** Зариф Бәшири бу хезмәтендә этник чуашлар түгел, ә мәлки, ягъни Тау ягы керәшеннәре турында язган, дигән фикер дә бар. Беренчедән, мәлки керәшеннәренең бер өлеше тарихи чыганакларда чуаш дип язылган. Икенчедән, автор үзе үк «татардан чукынган», дип, ягъни кайчандыр мөселман-татар булып, чукынгач чуаш исеме белән аталулары турында искәртә. Татарстан һәм Чуашстан чигендә урнашкан бу авылларда керәшен белән чуаш халкы элек-электән бергә аралашып, үзара йөрешеп, дус-тату, тел-лөгать вә гадәт алмашып яшәгәнен, гаилә бәйләнешләре дә көчле булганын онытырга ярамый. – *Редакция.***

[1] Шул тарафта булган мөселманнар моны «изге кабер» дип йөртәләр. – **«Шура»**.

Хуҗа Хәсән авылына нигез салучы җирләнгән урын

нар. Дога әйткән вакытларында ошбу адәмгә сыгынып дога кылалар. Карьяләре иген сачәргә җир өчен артык фәкыйрь булып, кабернең дүрт тарафыннан берәр дисәтинә җирне үлән үсеп торсын өчен буш калдырмышлар. Монда үскән үләнне изге үлән дип хайваннардан таптатмыйлар, чабып алмыйлар. Бер карт чуаштан моның сәбәбен сорадыгым вакыт, чуаш: *«Ул безнең изге бабабыздыр. Без аны хөрмәт итмәсәк, ул безгә рәнҗер дә, Аллаһы Тәгалә безгә ашлык бирми, авылыбыз зур казага дучар буладыр, бервакытны яшьрәкләребез шул җирне сөрә башлаганнар иде, атлары егылып үлде һәм шул елда авылыбызда күз авыруы таралды!»* – диде. Мин: *«Ул ни өчен сезнең бабагыз булсын? Ул бит мөселман адәм!»* – дидем. Минем бу сүземә ачуланган йөз илә көлде вә: *«Без үзебез дә электә мөселман булганбыз, безнең авылның бабалары Хәсән бабай булып, без шуның балаларыбыз. Шуның өчен авылымызның исеме аңа нисбәт илә Хуҗа Хәсән дип исемләнмештер!» – диде. Моннан соң башны түбән салып бераз торды да: «Хәсән бабай безнең хәзерендә христиан динендә булганыбыз өчен дә ачулана булырга тиеш. Аның өчен үткән сәнә «Казанской Божьей матери»ләрен күтәреп авылдан авылга йөргән монахлар безнең авылга килгәндә авылның янындагы чирәмлектә туктап ял иткәннәр иде. Шул елны башка авылларда иген килешеп, безнең авылда начар булды. Шуның өчен киләчәктә ул тәреләрне китермәскә дә уйлыйбыз»,* – диде.

Бу авылда үз араларында да татарча сөйләшәләр. Хәтта өч-дүрт яшьлек балалары да татар телен мөкәммәл беләләр. Гавам арасында: *«Бу авылның мәсҗеде булган да, үзләре бозылгач (чукынгач), Айдар исемле мөселман авылына күчмеш»*, – дип сөйләнмәктәдер. Ләкин бу сүз хата булса кирәк. Чөнки бу карья илә Айдар арасы 45 чакрымлык ара булып, урманга иң бай авыллардыр. Шулай булганда илле чакрымнан мәсҗед тарттырырга нинди хаҗәт төшмеш булыр? Икенчедән, бу авыл хәзерендә дә 300-400 ир җанлы авыл булып, моннан йөз, ике йөз еллар элек күп булса 50-60 җан булмыштыр. Шунлар өчен дә мәсҗед булдымы икән?[2]

Бу карьядә искедән калма әсәрләр күп. Хәтта бер чалма илә бер таяк та бар, дип сөйләделәр. Ләкин мин күрә алмадым. Фәкать ике иске китап алдым. Моның берсе үзбәк телендә булган бер тарих китабы иде. Икенчесе, артык ертылып, тузып беткәнлектән, нәрсә хакында язылганын аңламадым.

Ошбу татардан булган керәшен җөмләсеннән Чуел өязе Гөбнә суы буенда Югары Корбаш, Тарыбирде *(Тәрбит – Тәңребирде.* – **Ред.***)* карьяләре, Рум суы буендагы Сәед авылы, Рум карьяләре, Тәтеш өязендә Күлбаш, Киксар, Түбән Буа, Югары Буа карьяләре бардыр. Мин бу карьяләрнең һәрберендә булдым.

---

[2] Мәсҗедне күчермәкләре агач кытлыгыннан да түгел, бәлки гыйбадәтханәне ихтирам итү ниятеннән булыр. 60 җан башына түгел, ун җан башына булсын, мәсҗед бина ителү мөмкиндер. – **«Шура»**.

Югары Корбаш карьясендә Мүлкәй *(Мәүликәй, Мәлки. –* **Ред.***)* исемендә бер зиярәт бардыр. Әүвәлдә өстендә язулы таш та булган. Хәзерендә ул таш кисәк-кисәк булып ватылып ятмактадыр. Шулай булса да бәгъзе бер хат сөлес[3] илә язылган хәрефләр күрелгәләде. Бу карья гавам арасында Корбаш дип йөртелсә дә, русчада «село Мулкай» дип йөртеләдер. Димәк, моның да исеме Мүлкәй бабайга нисбәт ителмештер.

Рум карьясендә ике зират вә өсләрендә язулы ташлары һәм бардыр. Ташларның һичбер җире ватылмаган. Язулары берсенеке – хат тәгъликъ[4], берсенеке хат сөлес илә соң дәрәҗәдә яхшы язылмыштыр. Фәкать таш бик каралдыгы сәбәбеннән укымак мөшкел. Таш өстенә зур кәгазьне куеп, өстеннән карандаш каләм илә сызып йөрттек һәм дә яхшы укылырлык булды. Язуы болай: *«Әгүзү билләһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Нәфсин зәикатүл мәүт. Бу кабердә Тәңребирде Тугаш углы дәфен кылынмыштыр. Утыз тукыз сәнәдә»*. Нокта куелган урыннарда булган сүзләрне укып булмады. Гавам телендә Рум дип йөртелгән бу карьянең рәсми исеме Старый Тарыбирдедер. Русчада «ң» хәрефе булмадыгыннан, «Тәңребирде» исеме «Тарыбирде» рәвешендә үзгәрмештер. Икенче бер таштан *«Кармыш, илле ике сәнә»* дигән кәлимәләрен күчереп алдык. Сәед авылыннан ерак түгел урман эчендә бер зиярәт бар. Ташында хат сөлес илә гүзәл язылмыш. Без ошбу сүзләрне таныдык: *«Әгүзү билләһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Әд-дөнья сәгатен фә-әҗгаләһа тагатән»*. Бу зиярәтне чуашлар Сәед Җәгъфәр бабай зиярәте дип йөртәләр. Сәед авылы Сәед Җәгъфәргә нисбәт ителмеш булыр. Күлбаш карьясендәге язулы бер таш илә кабер бар, ләкин язуын укый алмадым.

Югары Буа, Түбән Буа, Киксар карьяләрендә берничә йорт мөселманнар да бар. Монда чуашлар 17 нче октябрьдән соң рәсми мөселман булдылар. Рум карьясендә чукынмаган чуашлар да бар, болар арасында мөселман исемендә ялгыз бер генә хатын барлыгы мәгълүм булды. Чукынганнар арасында Юныс, Йосыф исемле чуашлар да бар.

Чуаш карьяләренең исемнәре күбесе үз якыннарында булган мөселман авыллары илә исемдәш булалар. Чуел өязендәге – Чүти, Сарайлы, Тәтеш өязендәге – Аксу, Буа өязендәге Тимәш карьяләре кеби.

Чуашлар гомумән мөселманнарны үзләренең кан карендәшләре дип беләләр вә шул сәбәптән аларны яраталар, картлары да: *«Без әүвәлдә мөселман булганбыз»,* – дип сөйлиләр.

Чуашлар арасында йөреп борынгы әйберләрдән күп нәрсәләр җыярга мөмкин, фәкать гореф вә гадәтләре илә таныш булырга кирәк. Чөнки боларда искедән калган гадәтләр мөкатдәс саналып, шуңа хилаф булган эшне һич кылачаклар түгелләр.

ТЕЛЛӘРЕ ВӘ СӨЙЛӘШЛӘРЕ

Чуашларның үзләренә махсус язулары булмаса да, телләре бар. Сүзләренең күбесе татарчадан бераз үзгәртелеп кенә алынган булса да, сөйләр өчен бик авырдыр. Үзләре сөйләгән вакытта бик ашыгып, сүзне ике мәртәбә әйтми вә һич тотлыкмый сөйлиләр. Бер-берсенә сөальләре булганда бик оста вә аз сүз берлә генә аңлатып, матур итеп кенә сорыйлар. Безнең татарлар кеби бер мәртәбә кырык төрле сөаль куймыйлар. Сүз башлаганда әүвәл сәламләп, исәнләшәләр, соңра хаҗәтләрен сөйли башлыйлар. Сәламләшү русча бүрек салу илә булып, русчадан алган гадәтләре дә бары шулдыр. Кыскасы, чуашлар асыл мөкәлямәдә *(сөйләшү, гапләшү)* остаз вә әдибанәлекләре илә татарлардан күп дәрәҗәдә алда диярлектер.

Чуашларның байтак сүзләре татар сүзләреннән генә алынып үзгәртелгәндер[5]. *Хёр*

[3] Хат сөлес – гарәп язуының бер төре.
[4] Хат тәгъликъ – гарәп язуының бер төре.
[5] Биредә автор ике халык өчен дә уртак булган төрки сүзләр турында әйтә.

– кыз, пĕлĕт – болыт, чыбыр – ягъмур (Çумăр. – **Ред.***), чулдыр – йолдыз (Çăлтăр. –* **Ред.***), ауландым – өйләндем* кебиләр. Бәгъзе сүзләре һич үзгәрми сөйләнмәктәдер. *Алма, килдем, алдым, күрдем* кебиләр. Моннан башка гарәби, фарси сүзләр дә табылгалый. Русчадан исә һичбер сүз диярлек юк. Мәгәр безнең арада татарлашкан сүзләр аларда да истигъмаль ителенә, ягъни чуашлашкан *самовар, поднос, чәйнек, өстәл, сәхәт (сәгать)* кебиләр.

Дин исламга караган *фәрештә, пәйгамбәр, изге, мәһди, дәҗҗал, шайтан* кеби исемнәрнең һәрберен, үзләрендә юк хәрефләрен алыштырып, мөселманча әйтәләр. Фәкать *Алла, гыйбадәт* сүзләрен генә мөселманча әйтми, Аллага – *турă*, гыйбадәткә *кĕлĕ* диләр. Чуашлар «писмилланы» (бисмилла) бик күп әйтәләр. Ләкин алар, безнеңчә эш башлаганда Аллага сыгынып яки мөкатдәс сүз әйтеп түгел, бәлки гаҗәпләнгән урында әйтеләдер. Бер гадәттән тыш нәрсәне күрсә: *«Әй, писмилла!»* – диләр. Ягъни: *«Әй, бисмилла, гакылымнан шаштым»,* – димәкләр. Аны гади гаҗәпләнүләрдә дә әйтәләр. Атасы базардан соң гына кайтса: *«Әй, бисмилла, әткәм базардан яңа кайта»,* – димәкләр.

МӘКАЛЬ ВӘ ХИКӘЯТЛӘРЕ

Чуашларның иң мәгънәле мәкальләре ошбулардыр: *«НУМАЙ ТА ÇИТЕТ, САХАЛ ТА ПĔТЕТ – ПĔРЛЕ ПУРĂННИНЕ МĔН ÇИЕТ?» (мәгънәсе: «Дөнья мәгыйшәтенә кирәк булган нәрсә – аз булса да җитә, күп булса да бетә, ләкин бергә булып, иттифакъ илә яшәүгә ни җитә?»); «ĂÇТА КАЙСАН ТА ПĔР ХĔВЕЛ» (мәгънәсе: «Кайда барсаң да бер кояш»); «ТУР ХĂТАЛАНМАСĂР ĂНАТĂР ТУЛЛИ КАПАН, КĔСЪЕ ТУЛЛИ УКÇА ПАМАСТЬ» (мәгънәсе: «Алла, тырышмыйча торып, ындыр тулы кибән, кесә тулы акча бирмәс»); «ЙŸН ТАВАР ЧУНА УÇТАРАТЬ, МАНĂН УКÇАНА ÇАВ ТУСТАРАТЬ» (мәгънәсе: «Юнь товар юнь килә, минем акчаны да шул бетерә»).*

Хикәятләре исә күбесе татар тормышыннандыр. Арада бик көлкелеләре дә бар. Бервакыт миңа бер яшь чуаш ошбу хикәяне сөйләп көлдергән иде. *«Бер вакытта мужик, мелла, мөәзин өчәү сәфәргә чыкканнар. Юлда бер җиргә туктап каз пешергәннәр дә, шурпасын кич ашап, итен иртә берлән ашамак булганнар. Ләкин мулла берлән мөәзин, бу казны үзләре генә ашарга хәйлә эзләп, сүз куешканнар: кем дә кем төшендә мөкатдәс вә телдә мактаулы яхшы нәрсә күрсә, казны шул гына ашар. Мелла берлән мөәзин йокуга киткәч, мужик, торып, казны ашап та куйган. Иртә берлән торгач, төшләрен сораша башлагач, мөәзин: «Мин төшемдә Истанбулга бардым», – дигән. Мелла: «Мин аннан да яхшырак, Мәккәгә, хаҗга бардым, шулай булгач, каз миңа тиеш», – дигән. Соңрак мужиктан: «Син ни күрдең?» – дип сораганнар. Мужик та, хәйләсен табып: «Төшемдә сезнең берегез – Истанбулга, берегез Мәккәгә киткәнен күрдем дә, каз миңа калды бугай, ахыры, дип, аны-моны карамый тордым да ашадым», – димеш».* Мин бу хикәяне сөйләгәч тә, безнең меллалардан чуашларның да көлүенә артык тәгаҗҗеб иттем. Чуашларда безнең әбиләр сөйли торган «Хәзрәте Гали», «Салсал», «Убыр» хикәятләре кеби гакылга сыймаган хикәятләр бик күп.

ГАДӘТ ВӘ ИГЪТИКАДЛАРЫ (ЫШАНУЛАРЫ)

Чуашларның үзләренә махсус бер шәригатьләре булмадыгыннан, һәр мөгамәләләрен гадәткә иәртеп йөретәләр. Анлар искедән калган гадәтләрне соң дәрәҗәдә мөкатдәс саныйлар. Игътикадлары зәгыйфь булдыгы сәбәбеннән, гадәтләренең күбесе мәгънәсез вә гакылсызлыктан гыйбарәттер. Аларда игътикад шулкадәр зәгыйфьтер ки, берәү гакылга сыймаган эшләрне сөйләсә, бөтен күңелләре илә ышаналар. *«Фәлән кешене җен урлаган»*, *«Фәлән җирдә бер кешене җир йоткан»*, *«Фәлән җирдә бер йорт күккә*

очкан», «*Япон сугышында русларга каршы күктән чалмалылар төшеп сугышканнар»* кеби сүзләр аларда тәмам игътикад берлә сөйләнә. Кыскасы, аларда юктан шомлану, куркаклык, кешегә тәкълид *(ияру)*, очраган бер урам сүзләренә игътикад, им-том кеби нәрсәләр бик күптер. Ул тугрыда татарлардан да уздыралар.

Иске гадәтләргә шулкадәр нык ябышканнар ки, анлар карашында, иске гадәтләрне кылмау, калдыру да бик начарлык вә гаептән саналадыр. Әгәр дә күлмәкләренең бер җирендә тычкан яки күсе тишкән бер тишек булса, аны һич кимиләр, хәтта йортларында да тотмый, юк бәһасенә саталар. Сәфәргә чыкканда, капкадан чыккач ук, кулына бер төенчек йә башка бернәрсә тотмаган бер кеше очраса, сәфәребез уңмый, дип, кире керәләр.

Эт улаудан, карга кычкырудан шомлану аларда бик шаигъдер. Тукату *(сихерләү)*, җен сугу, су тоту кебиләргә игътикадлары бөтендер. Ләкин сихерләнүдән шикләнсәләр, яхуд бер авыруны шуңардан күрсәләр, мөселман авылларына барып, муллалардан өшкертәләр яки Коръән укыталар.

Чирәмлеккә акча ташлау яки ашамлык нәрсәләр пешереп кую, үлек күмү гадәтләре – бик ихласлы гадәтләрдәндер. Чирәмлеккә акча ташлаулары исә менә болай. Һәр авылның кырда үзенең махсус бер чирәмлекләре була. Үзләре моңа «кирәмәт» диләр. Шуның янынан узган вакытта бер тиен, ике тиен акча ташлап китүне үзләренә фарыз дәрәҗәсендә тиеш беләләр. Әгәр берәү ташламый китсә, ул кешенең аягы, кулы тартыша, диләр. Әгәр берәүгә шундый авыру тисә, тавык пешереп, шул чирәмлеккә илтеп куялар. Ул тавыкны изгеләр килеп ашый да дога кылып тергезә, диләр.

Үлекне күмгәндә күлмәк, ыштан кидереп, агызына тәңкә каптырып табутка салып күмәләр һәм янына чабата калыбы, җүкә кеби нәрсәләр куялар. Игътикадларынча, үлек кабердә кыямәт көтә-көтә эче пошкач чабата тугый, имеш. Көмеш тәңкәсе кыяматтә дус-иш ясаганчы үзен тәрбияли торырга, имеш. Чөнки алар кыямәт, җәннәт вә тәмугка ышаналар. Ләкин җәннәт вә тәмугка фәлән диндәге халык керә димәенчә, кирәк нинди диндә булсалар да булсын, кешегә яхшылык иткән кеше – җәннәткә, яманлык иткән кеше тәмугка керә игътикадындалардыр.

Мөселмандагы кеби, үлгән кешенең өчесен, җидесен, иллесен бик кадерләп уздыралар. Ул вакытта дус вә туганнарын, авыл картларын ашка чакырып үлекне сагыналар һәм аның өчен хәер-дога кылалар.

Питраудан элек тәкә суймыйлар, чемектән[6] башка вакытта йортка килен төшермиләр.

Гадәтләренең иң начары да – кан ашау гадәтедер. Терлек суйсалар, канын бер савытка җыеп ашыйлар. Ләкин бу заманда аны ташлап киләләр. Бер дә мөселман катнашмаган җирләрдә генә калмыштыр.

Чуашларның иң сөекле гадәтләре – базарга чыгудыр. Базардан калуны бик зур бер эшне кылмый калдырудан да артык начарлык саныйлар. Бала-чагасы вә хатын-кызлары һәммәсе төркем-төркем базарга чыгалар. Хатын-кызлары, бәйрәм киемнәрен киеп, җәяү, ирләре, балалары ат илә чыгалар. Базарга барганда бер капчыкка икмәк-тоз салып чыгалар да, кыяр, алма, шалкан кеби нәрсәләр алып, ашый-ашый кайталар. Алма, кыяр вакыты булмаса, тозлы балык, клиндер алып ашыйлар. Кыскасы, базар-ярминкә аларның милли бәйрәмнәре булып, нинди эш вакыты булса да, анда барудан һич тартынмыйлар.

Шура. – 1909. – №10. – Б.300-302; №11. – Б.337-339; №12. – Б.366-367; №13. – Б.404-405.

Дәвамы бар

Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

[6] Бу бәйрәмнәрен Тау ягындагы татарлар да бик шәп уздыралар. Хәтта эчкене чуашлардан да күбрәк әзерлиләр. Ләкин мишәрләр, чуашлар илә бергә катнашып йөрсәләр дә, моны тотмыйлар. – **«Шура».**

Безнең мирас №7 июль 2018

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ[1]

Габдерәшит Ибраһимов

Үзәктә – Хамба-Лама. 1886 ел

ХАМБА ЛАМА БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ: ДИНИ КАНУННАР

Хамба Лама Будда диненең гакаиде, ягъни төп кануннары турында менә нәрсәләр сөйләде:

«Будда динендә галәмнең һәр кисәге – үзен бар итүчесенеке һәм әлеге бар итүче аның тәңресе була.

Без – кешеләр, безнең галәмдә барлыкка килүебез ир һәм хатын дип атала, яисә без бүген «ата-ана» дип йөртә торган ике кеше арасында туган табигый мөнәсәбәт нәтиҗәсе, безнең бар итүчебез һәм тәңребез ул. Менә бу канун сәбәпле, безнең гыйбадәтханәләребезнең эчендә җисми мөнәсәбәт үрнәкләренең бөтен төрләре изгеләштерелгән.

Безнең гыйбадәтханәләребез ике бүлемнән тора: беренчесе – эчке бүлем, ул бүлемгә Будда динендә булмаган кешеләрнең керүе тыелган, икенчесе исә – ачык бүлем, бирегә һәркем керә ала, карый ала.

Бездә инанырга кирәкле нәрсәләрнең нигезе – кеше сурәте. Бу кешенең буе башта – ягъни гөнаһсыз чагында – 80 зира[2] озынлыгында, ул заманнарда кешеләр изге иде. Берзаман кеше гөнаһка

[1] Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

бирелде, дәвердән-дәвергә гөнаһы арткан саен, буе кыскара барды һәм бүгенге хәлгә килде. Шулкадәр кыскарды. Кешенең буе – гаделлек үлчәве булып тора. *(Гыйбадәтханәләрендә буе 80 аршын озынлыгындагы кеше сыны бар.* – **Г.И.***)*

Будда динендә илаһилык та, пәйгамбәрлек тә юк, ләкин кешеләрне өйрәтү, тәрбияләү өчен мөгаллимнәре – Буддалары бар. Хәзерге вакытка кадәр дүрт Будда килгән: Шах Ямуни, Асъяб, Ганганой, Гаргасонди. Әле тагын 996 Будда киләчәк[3]».

ГЫЙБАДӘТ

Хамба Лама Будда диненең гыйбадәтләре турында мондый мәгълүматлар бирде: «Безнең гыйбадәтләребез арасында иң олысы – уйлану. Уйланган вакытта, фикер йөрткәндә җанга бертөрле йомшаклык килсә, шулвакыт гыйбадәт кыла башларга кирәк. Гыйбадәт вакытында ара-тирә хонху, ягъни чаң, кыңгырау кагып, рухларны чакырырга кирәк. Рухлар килгәч, уңга-сулга бодай орлыгы чәчәргә кирәк, бу – сәдака бирү була. Теләсәгез, әйдәгез, сезгә әлеге гыйбадәтнең ничек башкарылуын күрсәтим...».

Шулай диде дә, урыныннан торып, сары төстәге бер бөркәнчек алып бөркәнде һәм кабат урынына утырды. Уң кулына тәсбих, сул кулына кыңгырау алды да укый башлады. Укуы да безнең Коръән-хафизларның йөгерек тел белән кылган гыйбадәте кебек, ләкин монгол телендә. Ара-тирә кыңгырау чыңлатып ала. Янәшәсендә торган табактан бодай орлыгы алып, аз-азлап сибә. Укуы биш минутлап дәвам итте.

«Менә, безнең гыйбадәтебез шуннан гыйбарәт», – диде. Мин соңыннан шундый ук гыйбадәтне гыйбадәтханәләрендә дә күрдем.

ЛАМА

Хамба Лама Будда динендәге ламалык турында ошбу мәгълүматларны бирде: «Лама атамасы төп мәгънәсендә «бөтен нәрсәдән ераклашу, ялгыз калу» дигәнне аңлата. Әгәр кеше һәрнәрсәдән читләшеп ялгызлыкны кабул итсә, гаиләсен калдырып, берүзе генә яши башласа, аны лама дип атыйлар. Ламалык – бу очракта билгеле бер төркемгә керүнең башы гына булып тора, мәзһәп түгел».

ШАМАНИЛЫК

Хамба Лама шаманилык турында болай сөйләде: «Шаманилык Будда диненең тышында тора. Үзләре күпме генә буддист булуларын тәкрарласалар да, шаманилар буддист түгел, чөнки кылган гөнаһларын ярлыкатыр өчен корбан чалалар. Корбанлык хайванны җиргә яткырып, аякларына бау тагалар һәм төрле якка тарткалыйлар. Шулвакыт бауга кем тотынган булса, аның гөнаһы ярлыканган, ягъни кичерелгән булып санала. Аннары шаман килә, хайванның күкрәген ярып кулын тыга һәм йөрәген сыта, хайванның җанын чыгара. Шул рәвешле гөнаһлар гафу кылынганлыкка ышану туа. Ләкин Будда динендә җан иясен үтерү катгый рәвештә тыелган. Шулай булгач, шаманистлар ничек буддист була алсын ди?! Тик шаманилар үзләре Будда динендә булуларын алга сөрәләр».

Алдарак, өченче бүлектә, шаманиларның корбан чалу йоласын күрсәткән рәсемне биргән идем.

ИҖТИМАГЫЙ ХӘЛЛӘРЕ

Хамба Лама бурятларның иҗтимагый хәлләре турында менә нәрсәләр сөйләде: «Бурят кавемнәренең иҗтимагый һәм сәяси хәлләренә килсәк, моның бик

[2] Зира – гарәп телендә зираъ «терсәк» дигән сүз, 0,7 метрга тигез үлчәү берәмлеге. Кайбер чыганакларда 0,75-0,9 метр, 24 бармак озынлыгы, аршын дип тә күрсәтелә (тәрҗ. иск.).

[3] Бу сәяхәтнамә язылганнан соң бер гасырдан артык вакыт үткән. Будда диненә кагылышлы әдәбиятта бүгенге көнгә кадәр килгән Буддаларның саны 28 дип күрсәтелә (тәрҗ. иск.).

сәер мәсьәлә икәнен әйтергә кирәк. Бүгенге көндә безнең мәдәниятебезгә, сәясәтебезгә чит кавем булган руслар күз куйган, кул салган: безнең малыбыз да, җаныбыз да, динебез дә русларның кулында, бөтен барлыгыбыз пыран-заран килгән. Халык саны көн үткән саен кими бара, милләтебез үлемгә хөкем ителгән, бик зур тизлек белән юкка чыга барабыз. Әгәр безгә нindидер бер рухи ярдәм, коткаручы килеп ирешмәсә, бетәчәкбез.

Тик без генә түгел, Русиядәге рус булмаган халыкларның барысының да хәлләре куркыныч астында. Ләкин шунысы бар: без азрак та, көчсезрәк тә булганга, тагын да күбрәк корбан бирәчәкбез».

ХАМБА ЛАМА

Хамба Лама Будда динендәге Хамба Ламалык турында ошбу мәгълүматларны бирде: «Бүгенге көндә мин – Хамба Лама. Безнең Будда динендә рухи һәм җисми яшәештә ике кеше була: берсе – Далай Лама, ул Тибетта яши; икенчесе – Хамба Лама, хәзерге вакытта ул – мин, биредә яшим. Моннан тыш, өченчедән – ә бәлки беренчедәндер дә – Хотото бар, ул исә – Будда вәкиле. Ләкин ул руханилыктан башка бернәрсәгә дә катнашмый, шуңа күрә аңа Хотото, ягъни «тере илаһ» диләр. Хотото кешегә хас үзенчәлекләрдән ераклашкан. [«Фәнафиллаһ[3] дип әйтергә мөмкин булыр иде – **Г.И.**].

Кеше әгәр тәрбия күрсә, алга барса, асыл халәтенә ирешә.

Үзен кеше тәрбияләр өчен акылын – җитәкче, фикерен хезмәтче итәргә тиеш. Фикер көче никадәр алга китсә, кешенең тәрбиясе дә шулкадәр камилләшә. Камиллек «вачрияна» дәрәҗәсеннән башлана, бу дәрәҗәгә җиткән кеше кардәшенең мәнфәгатен үзенекеннән алгарак куяр. Икенче дәрәҗә исә – «махаяна», бу югарылыкка җиткән кеше җәмгыять мәнфәгате өчен шәхесен һәм нәфесен фида итәр. Өченче дәрәҗә – «хайнаяна», бу дәрәҗәгә ирешкән кешеләр матди булган берни белән дә шөгыльләнмәсләр, бөтенләй башка галәмдә яшәрләр.

Менә бу юлга басар өчен «хинйанист» булырга, ягъни бар нәрсәдән ваз кичәргә кирәк. Без исә әлегә бары тик «хинйанист». Кеше, фикер көчен куллану өчен, фикерләүгә комачаулый торган үзенчәлекләреннән ваз кичәргә тиеш, бу исә гөнаһны бар итүче тәңредән ваз кичү дигән сүз.

Будда динендә кешенең буй озынлыгына йогынты ясый торган гөнаһлар дип хатыннар белән мөнәсәбәт, сугыш, җан иясен үтерү, кеше хакын талау, ялган сөйләү, хезмәте кермәгән нәрсәдән файдалану кебек зур гөнаһлар санала. Золым да – зур гөнаһларның берсе.

Кеше гомере буенча берничә тормыш яши, ләкин бу гомердән соң да тагын бер тормыш бар. Нәкъ менә шуңа күрә, хәзерлекле булырга кирәк, чөнки биредәге тормышыбыз да соңыннан булачак тормышыбыз өчен яшәлә».

ҮЛЕМ

Хамба Лама үлем турында болай сөйләде: «Үлем – кешенең үз асылын башка бер мәхлукка корбан итүе дигән сүз. Шуңа күрә рух, җәсәттән аерылып, гәүдәне башка мәхлукка тапшыра. Ошбу рәвешле бу гәүдәдә кешенең дә хакы булган кадәр, теге мәхлукның да хакы бар булып чыга. Шул сәбәпле, һәркемгә, һәр мәхлукка үз хакына ия булуда ниндидә булса бер комачау калмасын өчен, ул рухсыз җәсәдне кешеләр арасыннан чыгарып, бер урманлыккамы яки бер далагамы, кыскасы, аулаграк бер җиргә ташлау, җир астына күмү яки утка ягудан да яхшырак дип саныйбыз.

Дөньяның башы һәм ахыры юк, тик, һичшиксез, һәркем өчен бу тормышыннан соң тагын бер тормыш бар».

---

[3] Фәнафиллаһ – кешенең дөнья белән бәйләнешләрен бөтенләй өзеп, күңел һәм фикер берлеге хөкем сөргән мохиткә талу халәте (тәрҗ. иск.).

Цогшон-дуган.
Көнчыгыш Себер.
XIX гасыр азагы

Хамба Лама җәнапларының сөйләшүендәге олпатлык һәм рус телен куллануындагы осталык игътибарымны бик нык җәлеп итте, сүзләрен өздерепөздереп әйтә иде.

Бу күрешеп сөйләшүнең минем өчен бик файдалы булуын, бик канәгать калуымны кабат белдергәндә, үзләренең безнең белән кан кардәш булуын искәртте. Ул гына да түгел, тәңренең берлеген тануда да хәтта берләшә алуыбызны өмет итүен белдерде. Минем дә «муваххид»[4], диясем килеп калды. «Будда динендә Аллаһ юк» дигән сүзләр белән «(аның) тышында яшәми һәм аң белән кабул ителми», дип әйтергә телиләр, бу мәгънәне күз алдында тоталар икән.

БУДДИСТЛАРНЫҢ ИЗГЕ КИТАБЫ ҺӘМ ХӘЗРӘТ-Е МӨХӘММӘД

Хамба Лама, алда сөйләгәннәренә өстәп, Буддага караган 101 китап булуын да белдерде. «Аларның изге китаплар булуы» инануы белән яшиләр икән. Берара үрелеп телефонны алды да ниләрдер әйтте. Аннары: «Хәзер изге китапларыбызның берсен бирегә китерерләр», – диде.

Шул арада кулына дүртпочмаклы такта тартма тотып бер кеше керде.

Тартманы минем кулыма бирде, нәкъ уртасыннан икегә ачыла торган тартма эчендә монгол язуы белән язылган, юллары югарыдан түбәнгә таба укыла торган язмалы кәгазь битләре бар иде. Һәр биттә җиде юл язу бар, кәгазьнең арткы ягы буш, берни дә язылмаган иде.

Хамба Лама: «Безнең китабыбызда Мөхәммәднең исеме дә телгә алына», – диде.

Бу сүзләрне ишетүгә, куанычымнан, эчендә Мөхәммәднең пакь исеме дә булган китапка, аягүрә торып басып, хөрмәт күрсәттем.

Хамба Лама: «Мөхәммәднең пәйгамбәрлеген инкарь итә алмыйм, бу хактагы фикеремне аерым белдерәсем килә...», – дип, сүзне бераллалык мәсьәләсенә китереп ялгады. Ләкин бу мәсьәләнең үтә мөһимлеге, фәнни телгә булган ихтыяҗ мәсьәләнең бераз ябык калуына сәбәп булды.

[4] Муваххид – монотеист, бераллачылык тарафдары (тәрҗ. иск.).

МИССИОНЕРЛАРНЫҢ БУДДА ДӨНЬЯСЫНА ЙОГЫНТЫСЫ

Кинәт кенә сүз миссионерларга күчте. Мин болай дидем:

– Миссионерларның йогынтысы никадәр? Шул хакта да бераз сөйләгезче, зинһар.

– Берзаман безнең бурятлар күпләп христианлыкка күчә башладылар, ләкин соңыннан бик үкенделәр. Бу соңгы ирек игълан ителгәч, 7000гә якын кеше динебезгә кире кайтты. Гомумән, динебезне яхшы белгән кешеләрнең берсе дә христианлыкка күчмәгән һәм бу мөмкин дә түгел. Ләкин кайбер җаһилләр акча, ә кайбер яшь егетләр рус кызлары өчен, кайбер кешеләр исә хөкүмәтнең золымыннан үзләрен коткарып калу өчен христиан булганнар. Миссионерлыкның йогынтысын да шул нисбәттә билгеләргә мөмкин.

Без шулай сөйләшеп утырганда, ишектән бер хезмәтче керде дә ниләрдер әйтте. Хамба Лама, миңа борылып: «Бер кыргый кунак килгән, сез берәр сәгатькә бүленеп торырга рөхсәт итсәгез, мин аны мөмкин кадәр тизрәк озатып җибәрергә тырышырмын. Кайчанга кадәр күзәтү астында булырбыз икән?!» – диде.

ДАСАННАРДА, ЯГЪНИ ГЫЙБАДӘТХАНӘЛӘРДӘ КҮРГӘННӘРЕМ

Мин шулвакыт эчендә гыйбадәтханәләрне карап чыгарга карар кылдым. Тәрҗемәчедән минем белән бергә йөрүен үтендем һәм без бергә китеп бардык. Башта иң зурына кердек. Биредә нидачылар, ягъни сөрән салучылар зурнай һәм гирнай дип атала торган быргыларын кычкыртып уйныйлар иде. Безне аерым бер көй уйнап каршы алдылар.

Биредә бик биек, 80 аршын озынлыгында бер Будда сыны бар. Алдарак та әйтеп үткәнемчә, гыйбадәтханәләрдә бу сынның булуы буддистларның ышанулары белән бәйле. Бу сыннарда гаҗәпкә калдырырлык бернәрсә бар – скульптура сәнгате ягыннан югары дәрәҗәдә булулары, чөнки бик нәфис һәм искиткеч оста эшләнгәннәр. Мин бу гыйбадәтханәләрдә үзенчәлекле бер матурлык күрдем. Бигрәк тә бу зур дасанда гыйбадәт кылу урыннары бик матур. Сыннар күп түгел һәм бөтен җир искиткеч ару. Ләкин шунысы бар: дин исеме белән бик күп акча сарыф ителеп, шулкадәр кечкенә авыл дип кенә әйтерлек җирдә бик зур биналар төзелгән. Кечкенәләренең дә саны унбишләп бардыр, ләкин боларның күбесе гыйбадәтханә түгел, потханә. Ул потханәләр зиярәт кылу урыны итеп изгеләштерелгән. Менә Будда диненең төп инану рәвешен шул потханәләрдә күрергә мөмкин дә инде. Потханәләрнең күбесе фәхешханәне сурәтләгән диярлек, күңел кайтаргыч сыннар, изге дип саналып, берәм-берәм зиярәт кылына икән. Бу юлы аларны миңа күрсәтмәделәр. «Ачкычлары юк, фәлән», – дигән булып, берәр сәбәп таптылар. Мин исә ни өчен күрсәтмәүләрен сизендем.

Дасаннарны ике-өч сәгать карап йөргәннән соң, кунакханәгә кайттым, чәй эчеп алдым. Бераз ял итеп алуга, хезмәтче килде: «Теләсәгез, Хамба Ламаның хозурына барыйк, Сезне көтә», – диде.

Хамба Ламаның йортына килдек.

– Кунагыгыз киттеме? – дип сорадым.

– Хода безне мондый кунаклардан кайчан коткарыр икән?! Русия хөкүмәте, болай дәвам итсә, бик тиз җимереләчәк.

– Шулаймыни? Шундый ук кадерле кунакмыни? Мин Сезне күрергә килгән гади бер кешедер, дип уйлаган идем.

– Безнең гыйбадәтханәләргә читтән берәр кеше килә калса, шунда ук болар да килеп җитәләр. Сезнең безгә килүегездән шикләнгәннәр. Исемегезне дә беләләр. «Бирегә нигә килгән? Нинди бәйләнешләрегез бар?» – дип сорый. Бу – русларда бер авыру кебек, япон сугышыннан соң бөтен мәмләкәтне күзәтү астына алдылар.

Дәвамы бар

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

Остаз

Рөстәм Галиуллин

«Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон: «Остазыңа 80 яшь тулып килгәнне беләсеңме? Аның тәнкыйть мәкаләләре дә, әдәби әсәрләре дә күз алдында – укучыга алар хакында язу яңалык бирмәс. Әйдә, аны остаз, шәхес буларак ач әле? Киләчәк буыннар өчен дә остазлык үрнәге булып теркәлеп калсын», – дигәч, уйга чумдым. Тәлгат Нәбиулла улы Галиуллин, чыннан да, тормышымда мөһим урын тоткан кеше, инде даими аралаша башлавыбызга да шактый вакыт үткән, ләкин моңарчы аның турында бер генә җылы сүз дә язганым булмаган икән! Телисеңме-теләмисеңме, ирексездән, Габдулла Тукайның сүзләре искә төшә: «Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадрен белү?!.»

Мәктәп елларында «Казан утлары» журналыннан аның Сәет Сакманов исемле яңа заман татары турындагы трилогиясен укып, бу заманча әсәр белән шактый гына «җенләнеп» йөргән идем. Университетка укырга кергәч, шул әсәрнең авторы безне укытачагын белү горурлану хисе тудырганы хәтеремдә. Тәлгат абый белән якыннан танышу шактый ук кызыклы килеп чыкты. Өченче курста ул безгә яңа заман әдәбиятыннан лекцияләр укыды. Ишектән үк сөйләп керә, вакыты тәмамлануга, сөйли-сөйли, әкрен генә чыгып та китә. Бер минутны да бушка уздырмый! Өстәвенә, шулкадәр җайлы-ипле сөйли, кәгазьдән карауның эзе дә юк, әле рус телендә язган татар язучыларын да онытмый – камил дәрәҗәдә рус телендә дә лекцияләр сөйләп ала. Студентлар исемлеген тикшерү ише вак-төяк эшләр белән маташмый. Миннән – төркем старостасыннан – әллә нигә бер генә, студентларың бармы, укырга йөриләрме, дип кенә сораштырып куя. Үзен шактый дәрәҗәле, хәтта эре дип тә әйтимме, тота, гәүдәсе, үзе әйтмешли, уклау йоткандай туры, баш шактый ук артка чөелгән – кыскасы, Сәет Сакманов турында язган язучы-галим ошады миңа. Нәкъ шул елны әдәбияттан курс эше тапшырырга кирәк иде – Тәлгат абый җитәкчелегендә язарга карар кылып, аның эш бүлмәсенә юнәлдем. Ишек шакып керүемә, күз кырые

белән генә карап алды да ниндидер кәгазьләргә имза сырлап утыруын дәвам итте. Ул кафедра мөдире иде.

– Мин – өченче курс студенты. Сездән курс эше алырга телим, – дип, үгезне мөгезеннән алдым.

Профессор бу сүзләремә егылып китмәде, чөнки аннан курс эше язарга теләүчеләр миннән башка да күп. Дәвам ит, дигәндәй, башын кагып куйды да кабат кәгазьләренә текәлде.

– Мин дә Сезнең кебек хикәяләр язам, студентларның «Тәрәзә» газетасыннан укып барасыздыр... – шулай диюгә, кәгазьләрен читкә этәреп, менә дигән студент икән бу, дип сөенеченнән балкыр дип көткән идем – җавап буларак, тагын салмак кына башын изәде – эшеннән аерылмады.

– Минем дә фамилиям Сезнеке кебек үк – Галиуллин...

Тәлгат абый, шуннан соң гына сискәнеп, миңа текәлде. Ниндидер таныш чалымнар эзләгәндәй, төс-кыяфәтемә күзен йөгертте.

– Кайсы яктан син?

– Арчадан...

Бермәл хәтерендә казынып алгач, ниһаять, хәвеф-хәтәр, куркыныч юклыгын уйлап тынычланды, ахры – кәгазьләрен читкә куеп:

–Йә, егетем, нинди тема кызыксындыра инде сине? – диде.

Тарихи әсәрләргә мөкиббән китүемне хуп күрде профессор. Ул елны курс эшен уңышлы гына яклап чыктык. Моңа кадәр дә университетта һәр яңа курс башланганчы – үзебезнең факультет укытучылары булсынмы, башка бүлекләрнекеме – барысы да миңа бер үк төрле сорауны бирәләр иде:

– Гафу итегез, Сез Тәлгат Нәбиевичның кеме буласыз?

Бу сорауларга, беркеме дә түгел, фамилиядәше генә, дип җавап бирергә күнегеп беткән идем, инде курс эшемнең җитәкчесе булгач, ул аның туганы, оныгы диюләр арта төште, моңа мин кул гына селтәдем. Хәер, университетта «Тәлгат Галиуллин туганы» булып йөрүнең бер генә зыяны да юк, киресенчә, староста булганда ректорат тирәләрендә еш йөрергә туры килә иде – бу фамилия ярдәм генә итте.

Диплом эшен дә мин Тәлгат абыйдан яздым, әмма әлеге эш бик авыр барды. Бу вакытта «Шәһри Казан» газетасында эшлим, берничә егет Боровое Матюшино, Зеленый Бор якларындагы дачаларда вак-төяк төзекләндерү эшләре белән шөгыльләнәбез, кичен исә Казанның җиденче хастаханәсендә каравылда торам. Кыскасы, дөнья куып, диплом эшенә тотынырга һич кенә дә вакыт юк. Инде яклау көне якынлаша, минем исә бер генә бите дә язылмаган. Шулай йөргәндә, университет коридорында Тәлгат абый очраклы гына тотып алды:

– Егетем, син диплом эше язасы бар икәнен хәтерлисеңме ул?

Оятымнан:

– Көн-төн язам, Тәлгат абый, инде тәмамланып килә, мин инде бүлекләп-бүлекләп биреп тормам, тоташы белән китерермен, – дип алдашырга мәҗбүр булдым.

Аңламыймы инде зирәк профессор студентның беркатлы ялганын?!

– Юк, өзекләп китер. Иртәгә беренче бүлегең белән кил, – диде.

Нишлисең, төн утырып диплом эшенең беренче бүлеген яздым да, икенче көнне билгеләнгән вакытта Тәлгат абыйга китердем. Шул ук көнне кафедра лаборанты чакыртып алды. Тәлгат абый эзләткән икән.

– Егетем, синең, хикәя, дип әйтимме, повесть, димме, әмма һич кенә дә фәнни эш булмаган язмаңны укыдым. Шәп укыла, теле әйбәт, анализларың да яхшы, әмма безгә диплом эшен югары дәрәҗәдә башкарып чыгарга кирәк. Монда фәнни аппарат юк,

кайларда дөнья куып йөргәнеңне чамалыйм, кырык эшеңне кырык якка ташла да, ныклап чум диплом эшенә. Фәнни аппаратны ныгытырга кирәк!

Инде ишектән чыгып бара идем – Тәлгат абый туктатты да үзенә хас хәйләкәрлек белән елмаеп әйтте:

– Яклауда катнашкан галимнәрнең – комиссия әгъзаларының хезмәтләрен онытa күрмә! Алар эшне иң әүвәл үз фамилияләрен эзләүдән башлый...

Китапханәгә керүгә, иң беренче эш итеп Тәлгат Галиуллинның фәнни китапларын, мәкаләләрен соратып алдым. Фәнни аппаратны ныгытыпмы-ныгытам хәзер, дип үҗәтләнәм үземчә. Ничектер кулга беренче эләккән китабын – «Шәхесне гасырлар тудыра»ны йотлыгып укый башлаганымны сизми дә калдым. Тәлгат абыйның истәлекләрендә, университетның соңгы курсында укыганда аның ничек итеп баш-аягы белән эшкә чумуы, вакыты тыгызлыктан, диплом эшен бер-ике көндә генә «әвәләп» бирүе турында язылган өлешкә тап булдым.

Менә бит! Эзләгән табар, дип, сөенә-сөенә шушы өзекне күчереп алдым. Диплом эшен кабат карауга тапшырганда, шушы сүзләр язылган кәгазь кисәген дә кыстырдым. Кафедра лаборантыннан Тәлгат абый каралтып-чуарлатып, кыскартып-төзәтеп бетергән диплом эшен кире алып чыкканда, үземнеке шикелле үк кәгазь кисәгенә күзем төште: «Шәкертнең күп белүе, күп укуы, әлбәттә, күркәм гамәлдер. Әмма ни-нәрсә укырга кирәген аера белү шәкерт өчен тагын да мөһимрәк...» ише сүзләр сырланган иде анда. Ниһаять, шундый мәктүп-хатлар кыстырылган диплом эше ике арада шактый гына йөри торгач, ниһаять, «адәм рәтенә» керде – аны уңышлы яклап, университет белән саубуллашыр көннәр җитте.

– Нишлибез? – диде Тәлгат абый. – Аспирантурага кал, әйдә!

Әлеге тәкъдимне кабул иткәч, моңарчы тикшерелмәгән язучы иҗатын өйрәнергә дигән фикергә килдек.

– Тәүфикъ Әйди дигән язучының әсәрләрен укыганың бармы? – дип сорады ул.

– Тәлгат абый, ихластан әйтәм: андый язучының барлыгын беләм, әмма әсәрләрен укырга туры килмәде.

Ул миңа бер атна вакыт бирде. Китапханәдән Тәүфикъ Әйдинең бөтен китапларын җыеп кайттым. Аның иҗаты мәктәп программасында өйрәнелмәгәнлектән һәм университетта да әсәрләренә зур урын бирелмәгәч, әлеге әдип онытылып барган исемнәрнең берсе иде. Иң беренче итеп Тәүфикъ Әйдинең сәяхәтнамәләрен укырга кушты Тәлгат абый. Шулай эшләдем дә. Дөнья буйлап сибелешкән татарларыбыз тормышына кереп чумганымны сизми дә калдым. Бер атна узмады кебек – Тәлгат абыйга шалтыраттым:

– Тәүфикъ Әйди иҗатын өйрәник!

Тәлгат абыйның чын мәгънәсендә остаз булуын, кешелеклелеген яклау көнендә ачтым. Диссертация якларга берничә көн кала – бу декабрь азагы иде – Тәлгат абый, үпкәсенә суык тидереп, хастаханәгә эләкте. Иртәгә яклау дигән көнне хатыны Фәүзия апа шалтыратты:

– Яклауга чыгар өчен табиблардан рөхсәт сорап маташа икән бабаң. Анда карантин, ди! Ачуландым үзен! Син дә әйт инде, чыга күрмәсен, авыруы көчәячәк аннары, – диде.

Яклаучысыз калган сабый хәлендә, университетка килдем. Моңарчы фикер алышуларда гел Тәлгат абый катнашып, кайбер мәсьәләләрдә мине тулыландырып килгәнгә, моңарчы һәр этап та чагыштырмача җиңел узды. Кандидатлык диссертациясен яклаганда җитәкченең абруе аз роль уйнамый!..

Борчылуым юкка булган икән. Яклау башланыр алдыннанрак ни күрим – шактый ук агарынган, әмма елмаюы бөтен йөзенә таралган Тәлгат абый кафедрага килеп кермәсенме!

– Фәүзия апаң белмәсен, яме, качып чыктым! – диде ул.

Иңнән йөкне алып ташладылармыни – яклау уңышлы узып, комиссия әгъзаларының унтугызы да бердәм уңай тавыш бирде. Яклау тәмамлануга, Тәлгат абый кире хастаханәгә юл тотты...

Диссертация яклаганда Тәүфикъ Әйди әсәрләрен кабаттан эшкәртеп, киң җәмәгатьчелеккә җиткерергә дигән тәкъдим әйтелгән иде. Ул тәкъдимне онытып, кабаттан дөнья мәшәкатьләренә чумып, инде әдәбият-сәнгать, фән дөньясыннан читләшергә карар кылып, башка өлкәдә үземне сынап йөргән көннәрем иде, Тәлгат абый шалтыратты:

– Егетем, Тәүфикъ Әйдинең юбилее якынлашканын беләсеңме син? Яклау вакытында аның күптомлыкларын төзим, дип вәгъдә биргән идең кебек? Вәгъдә – иман...

Остазга каршы килеп булмый, җиң сызганып, бергәләп эшкә керештек. Тиздән әдипнең дүрт томлык «Сайланма әсәрләре» басылып та чыкты. Шундый көннәрнең берсендә:

– Җитте, үз ояңа кайт, акча тирәсендә синнән башка да йөрүчеләр күп, һәр кеше үз эше белән шөгыльләнергә тиеш. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Мөгаллимович белән сөйләшеп тордым беркөн, алар күп проектларга алынганнар анда...

Гыйльми сәркатип булып эшли башлагач, Ким Мөгаллимович әйтә иде:

– Тәлгат абыең сорашып кына тора инде үзеңне. «Минем шәкерт ничек анда, эшен алып барамы?» – дип гел кызыксына. Остаз шундый булырга тиеш инде ул!

Тәлгат абыйның шәкертләре бик күп. Аның кебек күп яшьләргә фатиха биргән остаз бармак белән генә санарлык. Бүген дә ул һәммәбезнең шатлык-кайгысын уртаклаша. 80 яшен тутырган көннәрдә дә чын мәгънәсендә егет булып калуының сере – үзенең хөрмәтле остаз икәнлеген тоеп, шәкертләренең уңышына ихластан сөенә белеп яшәүдәдер, мөгаен.

Дәлилсез булмас өчен, аның хакындагы фикерләрнең берсенә генә тукталам: «*... 90 нчы еллардагы татар яңарышы дулкынында яңа факультет һәм анда аспирантура оешу бик күпләрнең язмышында хәлиткеч рольне уйный, Тәлгат Нәбиевичка бик күпләр рәхмәтле. Ул, шушы елларда үзе аспирантлар белән җитәкчелек итеп, фәнни кадрлар, галимнәр үстерүгә зур хезмәт куйды. Мин дә Тәлгат Нәбиевич кул астында кандидатлык диссертациясе язып якладым, нәкъ менә аның киң карашлы, яшьләргә һәрвакыт хәерхаһлы булуы, фәндә чикләр юк – барлык өлкәләрдә дә үз сүзеңне әйтеп карарга мөмкин дигән фикерне ассызыклап килүе мине докторлык диссертациясе темасына алып килде. Мин диссертацияләр язган вакыт – Тәлгат Нәбиевичның бик тә мәшгуль, факультет деканы, докторлык диссертацияләре яклау советы рәисе, кафедра мөдире, Тукай җәмгыяте рәисе һ.б. бик күп вазыйфаларны берьюлы башкарып килгән чагы. Ләкин алып килгән мәкаләләрне, фәнни хезмәтнең аерым өлешләрен укырга ул һәрчак мөмкинлек таба, алар тиз арада, бер-ике көн эчендә, төзәтелеп, киңәш-тәкъдимнәр белән үземә әйләнеп кайта. Миңа гына түгел, һәр укучысы өчен ул энциклопедик белемле, игелекле, ярдәмчел остаз булды һәм шулай булып кала да...*» – дип яза «Яңа юллар салучы»* мәкаләсендә Тәлгат абыйның иң яраткан шәкертләренең берсе, ТР Фәннәр академиясенең вице-президенты, академик, профессор Дания Заһидуллина.

Мондый җылы сүзләрне Тәлгат Нәбиулла улының һәр шәкерте күңелендә йөртә, остазымның йөзенә кызыллык китермәсәм иде, дип гамәл кылып яши. Инде аның үз шәкертләре арасында да остаз исемен йөртүчеләр аз түгел. Димәк, Тәлгат Нәбиулла улының эшен киләчәк буыннар да дәвам итә. ■

*Д.Ф.Заһидуллина. Яңа юллар салучы//Тәлгат Галиуллин: галим, остаз, язучы. Казан: «Идел-Пресс», 2008 ел. – 16-35 б.

Сандугач

Габдулла Галиев

Җил-гарасат бераз тынса да, тирә-як дөм караңгы иде. Эшкә барганда бу тирәне күп тапкырлар күзәткән идем: сул якта, бер чакрымлап юл үткәч, урманнар башлана. Мин шул күгелҗем караңгылыкка таба йөгердем дә йөгердем. Бераздан баш өстемдәге болытлар кисәк-кисәк булып таралыша башлады. Аяк асларын яктыртып ай күренде. Җил дә, үз эшеннән канәгатъ булгандай, каядыр китеп югалды. Тирә-як тып-тын. Урман эченә кергәч, йөгерүдән туктадым. Агач артына ышыкланып тыңланып тордым. Шикләнерлек нәрсә ишетмәгәч, төп башына утырдым да тез башымны карарга керештем, тик аңа кул белән дә тотынып булмый, бик нык авырта иде. Мин тиз генә бөтен аягымны капшап чыктым. Ярый әле, аягым сынмаган, сынган булса, шунда ук каптырып алган булырлар иде. Шуңа эчемнән куанып бетә алмадым. Авырткан аягым оеганчы тизрәк хәрәкәт итәргә, лагерьдан ничек тә ераккарак китәргә кирәк. Ашыгып, аягыма бастым, аксый-аксый алга таба киттем.

Инде тәмам яктырды. Миңа хәзер артык барырга ярамый, яңадан караңгы төшкәнен көтәргә кирәк иде. Мин яшь агачлар үсеп утырган куелыкка кердем. Вак ботаклар җәеп сузылып яттым. Тез башым сулкылдап сызласа да, алҗуым үзенекен иткән, йоклап киткәнмен. Бервакыт этләр өргән тавышка сискәнеп уянып киттем. Миңа бик таныш тавыш: немец овчаркаларының өрүе иде бу. Мине эзләп киләләр! Эземә төшкәннәр. Бетте, барысы да бетте! Йөрәгем урыныннан чыгардай булып тибә башлады. Тәнем буйлап чемердәп салкын йөгерде. Яткан җиремнән сикереп тордым. Йөгереп китәргә теләдем. Әмма шунда ук моның мәгънәсез эш икәнлеген аңлап, тукталып калдым. Яңадан яткан урыныма сеңдем. Овчаркалар, гырылдык өрү тавышлары белән урманны яңгыратып, миңа якынлашалар иде. Миңа әле һаман да овчаркалар мине эзләмиләрдер, өрә-өрә янымнан узып китәрләр кебек тоела. Ләкин бу фикернең нииндидер бер хыял гына сыман нәрсә икәнен шунда ук аңлап алдым. Чөнки мин немец овчаркаларының лагерьдан качкан әсирләрне тоту өчен махсус өйрәтелгәннәрен белә идем. Урман арасыннан овчаркалар, алар артыннан автомат аскан ике солдат килеп чыкты. Солдатларның этләр тоткан каешлары бик нык тартылган. Овчаркалар өрә-өрә алга ыргылалар, хуҗалары алар артыннан көч-хәл белән генә җитешеп баралар иде. Күңелемдә әле һаман да зәгыйфь кенә булса да өмет уты яна. Мин авыз эчемнән генә: «Йа Раббым, ярдәм ит! Болай да җәфаланган тәннәремне этләргә талатма! Борыннарының ис сизүләрен, башларындагы зиһеннәрен томала, янымнан үткәреп җибәр шуларны», – дип пышылдыйм. Ләкин теләкләрем кабул булмады, энекәш. Овчаркалар, чиный-чиный өреп, мин яшеренгән куелыкка ташландылар.

Фашистларның әсирләрне овчаркалардан талатканнарын күргәнем бар иде. Этләр корбаннары өстенә ач бүреләр кебек ташланалар. Аны аяктан егып, рәхимсез рәвештә талыйлар. Бу талату әсирнең үлеме белән тәмамлана торган иде. Мин тиз генә кулларым белән битемне каплап, йөзтүбән әйләндем. Овчаркалар яман ырылдап мине таларга керештеләр. Алар җилкәмнән, терсәкләремнән кабып мине чалкан әйләндерергә

---

* Ахыры. Башы журналның 6 нчы (2018) санында.

тырышалар. Шулай әйләндереп муенымны әләктереп алырга телиләр. Мин, бөтен көчемне куеп, әйләнмәскә тырышам. Мине үз ихтыярларына буйсындыра алмаганга алар тагын да ныграк котырындылар. Мин хәлсезләнә бардым. Этләр мине чалкан да, йөзтүбән дә әйләндереп йөртә башладылар. Овчаркалар шулай әйләндергән-талаган арада авызларына сигаретлар кабып бу күренешне зур ләззәт белән күзәтеп торучы солдатлар күзләремә чалынып китә.

Өстемдәге гимнастеркам берничә урыннан шартлап ертылды. Ике як җиңем аерылып җиргә салынып төште. Бераздан овчаркалар гимнастерканы, аергалап, өстемнән сөйрәп үк төшерделәр Алар авызыннан бөркелгән әшәке сасы ис сулышымны буа. Шул истән котылырга теләп, битемне яшерергә тырышам. Мәгәр овчаркалар миңа моны эшләргә ирек бирмиләр. Иңбашларым, аркаларым ут белән өтеп алган кебек әрни. Ике як терсәгемнән эт тешләгәч, шул урыннар сызлавыннан бөтен тәнем калтырый, күңелем болгана. Шулвакыт аркам буйлап чалбар төбемә җылы сыеклык агып төшкәнен тойдым. Күз алдымда кара таплар уйный башлады. Актык чиккә җитеп хәлсезләнә барганымны сиздем. Этләрнең гырылдык ырылдаулары инде еракта тонык кына булып ишетелде. Мин, караңгы бушлыкка чумып, юкка чыктым.

Мин өч-дүрт кешегә исәпләнгән тар гына камерада аңыма килдем. Миннән башка монда тагын ике әсир бар иде. Өстә тимер рәшәткә белән капланган кечкенә генә тәрәзә, аста цемент идән. Камераның бөтен җиһазы шул. Барактагы кебек монда нарлар да, өстәлләр дә юк. Димәк, мине баракка алып кайтмаганнар булып чыга. Нинди камера бу? Җәзалап үтерә торган, үлем алдыннан ябып куя торган камерамы? Яисә?..

Икенче көнне иртән безне камерадан алып чыктылар, лагерь янында туктап торган машина янына алып килделәр. Көч-хәл белән генә машина кырыена килеп җиттем. Кузовка иптәшләрем күтәреп меңгерделәр. Яныбызга автоматлар аскан кара киемле ике полицай сикереп менде. Кабинага, ишеген шапылдатып ябып, шофер белән рәттән немец офицеры утырды. Машина кузгалып китте. Лагерь зонасыннан чыгып, урманга таба борылды. Без урман эченнән шактый гына ара бардык. Ниһаять, түгәрәк аланлыкка чыккач, машинабыз туктады. Безне машинадан төшерделәр. Өчебезне дә тезеп бастырдылар. Немец офицеры, каршыбызга басып, ашыкмый гына, сары тышлы күн сумкасыннан кәгазь алды. Аны ике кулы белән тотып, безнең рейх законнарына буйсынмаганыбыз өчен атылырга хөкем ителүебез турындагы карарны укыды. Офицер белән янәшә баскан, гөберле бакаНыкы кебек киң, зур авызлы полицай тәрҗемә итеп барды. Кулларыбызга көрәкләр тоттырдылар. Бака авызлы полицай җирне иңгә-буйга адымлап, көрәк белән сызып чыкты. Без күмеләсе кабер зурлыгы иде бу. Казый башладык. Каберебез тирәнәйгән саен, казуы кыенлаша барды. Манма тиргә баттык. Мин тәмам хәлсезләндем. Көрәккә балчык алып ыргыткан саен алга таба сөрлегеп китәм. Иптәшләрем егылырга ирек бирмиләр, тотып калалар. Гыжылдап сулыйм. Йөрәгем күкрәк читлегемне җимереп чыгардай булып тибә. Кулларым, аякларым егәрсезлегемнән дер-дер калтырыйлар. Күз алдымда, яктылыкны томалап, «чебеннәр» уйный. Безнең казуыбыз полицайларга акрын кебек тоелды, ахры, сүгенеп-җикеренеп ашыктыра башладылар. Ниһаять, кабер казылып бетте. Минем аягөсте басып торырлык көчем калмаган иде инде. Безне каберебез кырыена тезеп бастырдылар. Башымны иптәшемнең иңбашына салдым. Авып китәргә ирек бирмәс өчен, ул минем билемнән кочып алды. Әнә шулай өчебез дә кочаклашып бастык та үлемебезне каршы алырга әзерләндек. Шулвакыт башымны күтәреп күккә карадым. Анда, зәңгәр океан өстеннән салмак кына агып барган айсберглар кебек, болытлар агыла. Еракта күк чите зәңгәр булып җиргә тоташкан. Әйтерсең, күкнең зәңгәрлеге җиргә иңгән.

Карашымны кояшка күчердем. Кояш та элеккечә елмаймый. Сүрелеп, моңсуланып

калган. Ул, сагышлы йөзен миңа текәп: «Хуш инде, бәхил бул, Абдулла! Менә син берничә минуттан кара җир астында каласың. Ә мин сине аннан күрә дә, нурларым белән җылыта да алмам инде», – дигән төсле иде. Кинәт сискәнеп киттем. Үлүем түгелме соң бу? Үлүем бит?! Шулай итеп, якты дөньядан китәм дәме инде? Гүр иясенә әйләнү шушы була микәнни инде? Их, Абдулла, Абдулла! Бу дөньяда нинди рәхәт күрдең, нәрсә генә эшләргә өлгерә алдың әле син? Язмышым! Нигә шулай рәхимсез булдың син миңа? Нинди начарлык кылдым мин сиңа?

Күзләрем ачылган, колакларым ишетә башлаган көннән алып әти-әнисез үстем, әзме кимсенүләр, әзме рәнҗүләр күрдем. Мин бит әле сөяргә дә, сөелергә дә өлгерә алмадым. Иң бөек даһиларның да зиһеннәрен чуалтырлык мизгелне – кызлар тәненең рәхәтен дә татымаган килеш нигә дөньядан аерасың мине? Язмышым, нигә миңа шулкадәр шәфкатьсез булдың әле син?

Ышанасыңмы, энекәш, миңа шул иң тетрәндергеч минутта кинәт илһам килде. Башымны югары күтәрдем дә бар көчемә сандугач булып сайрый башладым. Яшел аландагы тынлыкны ярып сайраган сандугач тавышы фашистларны бермәлгә өнсез калдырды. Безгә төбәлгән автомат көпшәләре кинәт калтыранып куйдылар. Немец офицерының атарга команда бирергә күтәрелгән кулы һавада асылынып калды. Сандугач тавышына хәтта аланлыктагы каеннар да баш иеп, тынып калгандай булды. Ә мин, бөтен осталыгымны җигеп, өздерә-өздерә сайрадым да сайрадым. Бу минем газиз туган илем белән, якты кояш белән, җиһан белән хушлашуым иде.

Шулвакыт көтелмәгән хәл булды. Немец офицеры полицайларга: «Һальт!» – дип кычкырды. Аннан кызу-кызу атлап яныма килде. Зур соры күзләрен очкынландырып, эре ак тешләрен ялтыратып миңа карап елмайды да: «О-о, ду – талант», – диде. Сайравымнан туктап, ни әйтергә белми торган арада җилкәмнән эләктереп алды да читкә этеп җибәрде. Мин тәгәрәп киттем. Егылган җиремдә берни аңламыйча бер офицерга, бер полицайларга карап тора башладым. Ничек булды соң әле бу? Офицер мине үлемнән алып калырга тели түгелме соң? Әйә, әйе, әнә бит бер читкә этеп җибәрде. Димәк... димәк, мине атмаячаклар. Шулай булса, рәхмәт, мең рәхмәт сиңа, Тәңрем!

Шатлыгымнан елмаеп иптәшләремә карадым. Сандугач тавышы аларга да тәэсир иткән. Икесенең дә яңаклары буйлап яшь ага. Үзләре полицайларга нәфрәт белән текәлеп горур басып торалар. Тетрәнеп киттем. Тукта, нишләдем мин? Йә, нишләдем? Нигә сайрадым? Минем генә исән калырга хакым юк бит. «Хаин, куркак», – дип пышылдадым мин үз-үземә. Син бит исән калыр өчен сандугач булып сайрадың. Әйе, әйе, исән калыр өчен. Әнә, иптәшләреңә кара! Ничек оялмыйсың син алардан, бичара куркак! Мин, ашыгып, басып торган урыныма үрмәләдем. Иптәшләремә тотынып аягүрә бастым. Шулчак иптәшләремнең берсе, миңа карамый гына: «Алар сине исән калдырырга телиләр. Аңгыра, ничек аңламыйсың шуны? Болай үлү батырлыкмыни ул? Бар, кит, ычкын моннан!» – дип пышылдады. Минем яңадан иптәшләрем янына басуым немец офицерына да ошамады. Әле кайчан гына миңа карап елмайган йөзе, күкне кара болыт баскандай, кинәт бозылып китте, күзләре зәңгәрләнеп акайды. Минем яныма йөгерә-атлый килгән уңайга аяк астыма сугып җибәрде. Мин яңадан йөзтүбән мәтәлеп төштем. Шул арада һаваны ярып автомат тыкылдавы яңгырады. Мин башымны күтәрдем. Иптәшләремнең, үткен чалгы белән чабылган үләннәр кебек, авып төшкәннәрен күреп алдым.

Бака авызлы полицай, эре-эре атлап, минем янга килде. Еланныкы төсле яшел күзләрен миңа төбәп: «Гомереңне бүләк иткән өчен офицер әфәндегә рәхмәт әйт, күсәк», – дип ысылдады. Ул арада яныма офицер үзе килеп җитте. Перчаткалы кулы белән җилкәмә суккалап алды да: «Гут, гут, золдат. Ду – талант», – дип көлемсерәде.

Бака авыз, офицерга сиздерми генә, минем аяк йөземә басып, тагын ысылдады: «Нәрсә көләсең, кусәк? Рәхмәт әйт! Аягына егыл, хайван».

Мин башымны түбән иеп басып торуымны дәвам иттем. Әле һаман булып үткән вакыйгадан айнып җитә алмый идем. Бер караганда, исән калуыма сөенгән кебек булсам, икенче караганда, иптәшләрем алдында гафу ителмәслек хата ясап ташлаганыма газаплана идем. Оят иде миңа. Әкренләп зиһенем ачыла башлады. Шулчак иптәшемнең: «Болай үлү батырлыкмыни ул?» – дигән сүзләре исемә төште. Бәлки, чыннан да, котылу чарасы булганда, үлмәс өчен тырышыргадыр? Мин бит солдат. Мин әле көрәшергә тиеш. Бүген атылган иптәшләрем өчен дә, үзем кебек концлагерьларда газап чигүче меңләгән әсирләр өчен үч алырга тиеш.

Мине кире лагерьга алып кайттылар. Немец офицеры минем өчен лагерь түрәләренә нинди җавап биргәндер, анысы миңа караңгы. Мин аны лагерьдагы түрәләргә йогынты ясый алырлык абруйлы немец булгандыр, дип уйлыйм. Һәрхәлдә, немец офицерлары арасында яңа карашлы, сәнгать әһелләрен ихтирам итүчеләр булмый калмагандыр. Шулай да гомерем буена чишелмәс табышмак булып калды ул миңа...

Син, энекәш, Абдулла абзыеңның тормышында гел шулай күңелсезлекләр генә булып торган икән, дип уйлап утырасыңдыр инде. Юк, минем дә рәхәтләнеп искә алырдай матур көннәрем булды. – Абдулла абзыйның йөзе яктырып китте. Зәңгәр күзләре очкыннар чәчеп алды: – Шулай итеп, без Сания апаң белән тормыш көтәргә дип авылга кайттык. Яңадан үзешчән сәнгатьтә катнаша башладым. Илле җиденче елның язында Казанга, Халык иҗаты йортына чакыртып алдылар. Анда үземнең сәләтемне күрсәттем. Шунда ук миңа Мәскәүдә үткәреләчәк татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнашачагымны әйттеләр. Репетицияләр башланды. Булачак чыгышыма, бөтен көчемне куеп, дәртләнеп әзерләндем.

Ниһаять, Мәскәүгә киттек. Декаданы без Зур театрда «Авыл иртәсе» дигән чыгыш белән башлап җибәрдек.

Авыл иртәсе! Алтын нурларын тирә-якка сибеп әкрен генә кояш чыгып килә. Сәхнә артында, салмак кына тибрәлеп, татар музыкасы агыла. Су буендагы таллыкта өздерепөздереп сандугач сайрый. Авыл иртәсенә сихри моң сирпеп, кәккүк кычкыра. Әнә, урам башында көтүче быргысын кычкыртып җибәрде. Чыбыркы шартлады. Ул арада сыерлар мөгрәде, сарыклар бәәелдәде. Көтүче быргысы якынайды. Аннан аның тавышы ерагая барып юкка чыкты. Бу – авыл иртәсенең иң ямьле вакыты, авылдан көтү чыгып бару вакыты иде.

Сәхнә бер мизгелгә тынып калды. Мин яңадан сайрап җибәрдем. Сайравымны залдагылар алкышларга кереште. Мин тагын да дәртләнебрәк, илһамланыбрак сайрадым. Хөкүмәт ложаларындагы җитәкчеләр аягөсте торып кул чабалар, зал гөр килеп тора. Ә мин куанычымнан ни эшләргә белмим, күзләремдә – шатлык яшьләре. Йөрәгем үземә ишетелерлек итеп тибә. Ә үзем күңелемнән уйлыйм: «Илаһым! Кемгә бу алкышлар, миңамы?»

Кырык икенче елда хәтта фашистның да туң йөрәген эретә алган сандугачкамы?» Үз халкының, үз милләтенең культурасын башкаларга күрсәтүче кечкенә сандугачның иң бәхетле мизгелләре иде ул, энекәш.

Абдулла абзый сөйләвеннән туктады. Йокымсырап күзләрен йомды. Мин, урындыкны шыгырдатмаска тырышып, әкрен генә урынымнан тордым. Моны тоеп алган Абдулла абзый акрын, әмма бик тә үз итеп: «Ярдәмең өчен рәхмәт, энекәш», – диде. Аның белән саубуллашырга дип сузган кулымны селкеп торды да: «Калган тормышым белән кызыксынсаң, иртәгә кил. Сөйләп бетерермен», – дип өстәде. Мин, хушлашып, чыгып киттем. ■

Безнең мирас №7 июль 2018

МӘХМҮТ ГАЛӘҮ
(1886-1937)

Мәхмүт Галәү җәмәгате Зәйнәп белән. 1920-1930 нчы еллар

Егерменче йөзнең башында ук кулына каләм алып, татар көндәлек матбугатының беренче көннәреннән газета-журналларда актив язышкан, «Кармак» көлке журналының нашире һәм мөхәррире булган, заманында «Белек» исемле хосусый нәшрият ачып, халыкка мәгърифәт тарату юлында армый-талмый хезмәт иткән һәм, ниһаять, әдәби әсәрләре белән татар әдәбияты хәзинәсенә зур өлеш керткән талант иясе Мәхмүт Галәүнең (Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗани) абруйлы исеме вә иҗат мирасы совет чорында озак еллар буе халыктан яшереп яткырылды. Алай гына да түгел, ул мирасның шактый өлеше тоталитар режим шартларында бөтенләй юкка чыгарылды. Бу яктан әдипнең катлаулы тормыш юлы һәм фаҗигале язмышы узган гасырның утызынчы елларындагы репрессияләр шаукымында нахакка һәлак ителгән бик күп татар мәдәнияте эшлеклеләренең язмышына охшаш.

Октябрь түнтәрелешеннән соң әдипнең нәшрияты тартып алына, болай да татарча бердәнбер көлке журналы булып калган «Кармак» ябыла. «Эшләмәгән – ашамый!» дигән шигарьнең иң популяр чагы – тормышны алып бару өчен ничек тә даими эш табарга кирәк була. Бу мәсьәләдә Мәхмүт Галәүгә шактый кыенлыклар, мәшәкатьләр кичерергә туры килә. Егерменче еллардан ук тормышның барлык өлкәләрендә хөкем сөрә башлаган идеологик чикләүләр, һәрнәрсәне фәкать сыйнфый көрәш күзлегеннән генә карап бәяләү практикасы иң беренче нәүбәттә «иске заман», «буржуаз заман» зыялыларына – алдынгы фикер ияләренә, язучыларга, мәдәният эшлеклеләренә, белгечләргә каршы юнәлтелә. «Сыйнфый яктан ышанычсызлар» исемлегенә «кергән» мондый кешеләрне җаваплы эш урыннарына куймыйлар, куйсалар да озак тотмыйлар. Моны Мәхмүт Галәүнең эш эзләп бер төбәктән икенче төбәккә бик еш күчеп йөрүләре мисалында да күрергә мөмкин.


РСФСР

СВИДЕТЕЛЬСТВО О СМЕРТИ

II-А № 954293

Гр. Галлутдинов
(фамилия,
Махмуд Галлутдинович
имя, отчество)
умер (ла) 12/XI-1938 года двенадцатого
ноября тысяча девятьсот тридцать
(прописью и цифрами год, месяц и число)
возраст 52 года восьмого года
Причина смерти ———
о чём в книге записей актов гражданского состояния о смерти
1952 года апреля месяца 11 числа
произведена соответствующая запись за № 25
Место смерти: город, селение (Москва)
район ——— область, край,
республика ———
Место регистрации: Отдел ЗАГС
(наименование и
Кировского р-на
местонахождение бюро ЗАГС)
Дата выдачи 13 апреля 1952 г.

м. п. Заведующий бюро записей актов гражданского состояния

Гознак. 1946.

Әлеге таныклыкта Мәхмүт Галәүнең 1938 елның 12 ноябрендә «вафат булуы» (үлем сәбәбен күрсәтергә тиешле юлга сызык куелган) күрсәтелә...


[redacted]

Центральный архив ФСБ РФ

С П Р А В К А

Приговор о расстреле Галаутдинова Махмуда Галаутдиновича приведен в исполнение в гор. Москве "4" XI 1937 г. Акт о приведении приговора в исполнение хранится в Особом архиве 1-го спецотдела НКВД СССР том № 2 лист № 355

НАЧ 12 ОТД-НИЯ 1 СПЕЦОТДЕЛА НКВД СССР
Лейтенант госбезопасности

Бу белешмә исә әдипнең 1937 елның 4 ноябрендә атып үтерелүен раслый...

Ләкин иң гаҗәбе шунда: үзе язганча, «ярым ач хәлдә көн кичерүенә» карамастан, Мәхмүт Галәүнең матур әдәбият өлкәсендәге нәтиҗәле иҗат эшчәнлеге нәкъ менә әлеге елларга туры килә. Барыннан да бигрәк, әдип үзенең күңел түрендә күптәннән йөрткән иҗади хыялын – татар халкының зур бер чор эчендәге тарихи тормышын иңләп алган эпопея язу ниятен гамәлгә ашырырга керешә.

Гомуми исеме «Канлы тамгалар» дип алынган бу эпопея дүрт китаптан торырга тиеш була. Әдип алдан һәр китапның киңәйтелгән планын төзи, исемнәрен билгели. Беренче китапта XIX гасыр татар авылының, авыл һәм шәһәр халкының 1877 елгы ачлык фаҗигасен кичерү вакыйгаларын; икенче китапта 1897 елгы халык исәбен алу, шуңа бәйле рәвештә авыл халкының бунт күтәрүе һәм соңыннан Төркиягә күчеп китүен; өченче китапта урыс-япон сугышы, 1905 елгы беренче инкыйлаб чорын; һәм, ниһаять, «Өермәләр» дип исемләнгән соңгы – дүртенче томда большевиклар инкыйлабы елларындагы давыллы вакыйгаларны гәүдәләндерү күздә тотыла. Ләкин, язучының фаҗигале язмышына бәйле рәвештә, роман-эпопеяның беренче ике китабы гына язып тәмамлана, өченче, дүртенче кисәкләре, каралама хәлендә әзер булсалар да, әдипнең кульъязма архивы һәм беренче ике кисәгенең асыл нөсхәләре белән бергә юкка чыга.

Беренче ике кисәген тәшкил иткән «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнары да безгә 1931 һәм 1934 елларда Мәскәүдә урысча тәрҗемәдә чыккан басмалар буенча гына билгеле.

Совет чоры әдәбият белемендәге вульгар социологизм тарафдарлары егерменче елларның ахырларында Мәхмүт Галәү иҗатына бер-бер артлы һөҗүмнәр оештыра, аңа «контрреволюцион фикерләр тарата торган буржуа болганчыгы» дип мөһер салалар. Мәхмүт Галәүнең бу нахак гаепләүләрдән нинди кыенлыклар, нинди рухи газаплар кичерүен аның СССР Үзәк башкарма комитеты каршындагы Милләтләр Советына һәм РСФСР Халык комиссариатлары Советына адреслап 1930 ел 10 майда язган ачынулы озын хатыннан да күрергә мөмкин. Шул хаттан берничә өзек: «...Менә берничә ел инде, мин үземне нindидер аңлашылмаган, сихерле-серле бер түгәрәк эчендә калган итеп тоям. Җаваплы урыннарда утырган татар агайлары һәммәсе диярлек мине күрмәмешкә салыша, мине язучы итеп рәсми танымыйлар, үткәндәге хезмәтләремнән йөз чөерәләр, әсәрләремнең социаль әһәмиятен, мәкаләләремнең актуальлеген томаларга – кыскасы, мине ничек тә читкә, арткы планга чигерергә тырышалар. Шул сәбәпле мин даими пси-

Язучының Мәскәү төрмәсендә төшкән фотосы. 1937 ел

хологик басым астында яшим. Ә бит мин гади ихтыяҗымнан артык бернәрсәгә дә дәгъва итмим. Минем бердәнбер ихтыяҗым – бер телем икмәк, яшәү хокукы һәм башкалар кебек үк пролетар җәмгыять файдасына хезмәт итү. Менә бу хокукларга мин тулысынча ия түгелмен. Үз белгечлегем буенча аппаратта эшләргә телим, хезмәтемне тәкъдим итәм – төрле сәбәп табып, кире кагалар, эшкә алырга теләмиләр... Мәкалә язам – телдән һәммәсе хуплый, мактый, фикере көчле, эзлекле, актуаль, дип әйтә, ләкин басмага кабул итми, кабул итсә дә, бастырып чыгармый һәм сәбәбен дә ачыктан-ачык сиздереп куя: янәсе, минем исемемне популярлаштырырга ярамый... Әдәби әсәр язып тапшырам – аны да әүвәл хуплаган, мактаган булалар, рецензиялиләр, нәшер итәр өчен чиратка куябыз дип ышандыралар, әмма барыбер бастырып чыгармыйлар, шул юл белән мине яңа хезмәтләремне тәкъдим итү мөмкинлегеннән мәхрүм итәләр...

Менә җиденче ел инде мин социаль эчтәлекле зур бер әсәр өстендә эшлим. Каралама рәвешендә әсәр тәмамланган дияргә була, ә аның «Канлы тамгалар» исеме белән йөргән 25 табак күләмендәге беренче томы күптән басмага әзер. Абруйлы татар тәнкыйтьчеләре һәм әдәбият галимнәре һәммәсе диярлек романны укып чыгып, аны социаль мәгънәсе белән дә, сәнгатьчә дәрәҗәсе белән дә зур кыйммәткә ия әсәр, дип бәяләделәр һәм тизрәк нәшер ителүен яклап чыктылар (кулымда язма рецензияләре бар). Мәсьәләнең гамәли чишелеше исә инде менә ике елдан артык сузыла килә...

Минем уемча, боларның һәммәсе миңа билгесез һәм миңа белгертелми торган ниндидер субъектив фикер, аңламау яки Татарстандагы җаваплы урында утыручыларның бер өлешендә кирәгеннән артык шикләнү, чиктән ашкан саклык күрсәтү нәтиҗәседер. Болаймы, тегеләйме – моны ачыклау һәм төенне чишү кирәк. Бу хәлдә яшәргә, эшләргә һәм гаиләмне туйдырып торырга минем бүтән көчем калмады...»

Хат ахырында әдип югары оешмалардан язган әсәрләрен бастырып чыгаруда ярдәм итүләрен, «милли өлкәдә яки гомумҗәмәгатьчелек линиясе буенча» даими эш урынына урнашу мөмкинлеге тудыруларын сорый.

Бу ачынулы хатның беркадәр уңай нәтиҗәләре дә була, әлбәттә. Аерым алганда, «Канлы тамгалар»ның беренче ике томы, алда әйтелгәнчә, «Муть» һәм «Мухаджиры» дип исемләнеп, 1931 һәм 1934 елларда Мәскәү нәшриятында аерым китаплар булып басылып чыга. Беренче әсәрнең тәрҗемәсен төрки телле әдәбиятларны урысчага аудару өлкәсендәге хезмәтләре белән ул заманда ук исеме танылган Г.Шәрипова эшли, ә икенчесен автор үзе тәрҗемә итеп, соңыннан аны урыс әдәбиятчысы С.Быстрицкая эшкәртеп чыга. «Эшкәрткәндә» һәм, гомумән, нәшрият хезмәткәрләре тарафыннан редакцияләгәндә романнарның төп текстлары урыны-урыны белән кыскартылган һәм

оригиналларындагы кайбер милли үзенчәлекләре кыркыла төшкән булса кирәк. Моны «Мөһаҗирләр» романының татарча оригиналында сакланып калган өч өзеген («Чүлмәк тулгач» җыентыгы, Мәскәү, 1929 ел) урысча тәрҗемәләре белән чагыштырып караганда шактый ачык күрергә мөмкин.

1934 елда Мәскәү язучылар ширкәте нәшриятында әдипнең янә үз тәрҗемәсендә өченче күләмле әсәре – заман темасына багышланган һәм татар авылына 1917 ел алып килгән кискен үзгәрешләр фонында төрле катлау кешеләре арасындагы киеренке мөнәсәбәтләрне психологик планда тасвирлаган «Кабылсай» романы да дөнья күрә. Көндәлек матбугат битләрендә урнаштырылган берничә өземтәсен исәпләмәгәндә, бу әсәрнең дә татарча асыл оригиналы сакланмаган.

Ә менә әсәрләрен татар телендә бастыру мәсьәләсендә әдип Казан, Татарстан китап нәшрияты җитәкчелеге белән берничек тә уртак тел таба алмый. Кульязмалар нәшриятка кат-кат тәкъдим ителсә дә, субъектив тәнкыйтькә яки, әдипнең үз тәгъбиренчә, «чиктән ашкан саклык күрсәтү»гә очрап, һәр юлы «төзәтү өчен» авторга кире кайтарыла. Нәшрият җитәкчелеге «Мөһаҗирләр» романының татарча кульязмасын, соңгы мәртәбә рецензентлар таләп иткәнчә «төзәтү өчен», 1936 елның ахырларында кире кайтара. Бу хакта нәшриятның язма рәвештә теркәлгән рәсми боерыгы сакланган.

Әдип үзенең әсәрен рецензентлары, нәшрият җитәкчелеге һәм башка тәнкыйтьчеләр кушканча «төзәтергә» керешкән булгандырмы-юктырмы – анысы билгесез. Хәер, «төзәтергә» керешсә дә, өлгерә алмагандыр, чөнки ул арада 1937 ел өскә килеп ябырыла, тоталитар режимның хөкем тегермәне – «өчлек»ләр эшли башлый. Ул инде кайсы тәнкыйтьче, кайсы автор дип талымлап тормый: исеме күзгә ташланырдай милли интеллегенциянең һәр шәхесен берәмләп тә, уптым да таш капчыкка җыярга тотына...

«Мемориал» халыкара тарихи-агарту, хәйрия һәм хокук яклау җәмгыятенең рәсми сайты раслаганча (http://lists.memo.ru/d8/f70.htm), Мәхмүт Галәүне 1937 елның 22 сентябрендә кулга алалар[1]. Ул советларга каршы оештырылган пантюркистик диверсион-террорчылык һәм шпионлык оешмасында актив катнашуда, төрек шпионы булуда гаепләнә. Махсус коллегия (ОСО) утырышы 1937 елның 4 ноябрендә була. Әдипне, барлык милкен конфискацияләп, атып үтерергә хөкем итәләр. Хөкем карары шул ук көнне гамәлгә ашырыла[2].

Җәсәде Мәскәүнең Дон зиратындагы туганнар каберлегенә җирләнә.

Рүзәл Мөхәммәтша *әзерләде.* ■

Әдәбият:

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.316-317.
2. Мәхмүт Галәү. Мөһаҗирләр. Тарихи роман. Рәис Даутовның кереш сүзе белән. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 303 бит.
3. Жертвы политического террора в СССР. Электронный ресурс. Режим доступа: http://lists.memo.ru/index.htm. Дата обращения: 19.06.2018.

---

[1] Байтак китапларда (шул исәптән, «Әдипләребез»дә дә) бу дата күрсәтелми. Өстәвенә, еш кына язучының «Мәскәүдә кулга алынып, хөкем итәргә Казанга кайтарылуы» турында языла. Атып үтерелгән урыны Мәскәү икәнен игътибарга алсак, алдагы фаразның хакыйкатькә туры килү-килмәве шик тудыра. Бер шәһәрдән икенче шәһәргә күчереп йөрттеләрме икәнни? – **Р.М.**

[2] Шулай ук, байтак китапларда, НКВД биргән белешмә кәгазенә яисә үлем турындагы таныклыкка сылтама ясап, әдипнең «вафаты» (таныклыкның үлем сәбәбен күрсәтергә тиешле юлына сызык куелган) 1938 елның 12 ноябрендә дип гаманлана. Күргәнебезчә, бу да ялгыш фараз. – **Р.М.**

Истә, һаман да истә!

Язучы Диас Вәлиевнең тууына 80 ел

Язучы, драматург, ТАССРның (1981) һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1983), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Диас Назыйх улы Вәлиев 1938 елның 1 июлендә Татарстанның Арча районындагы Казанбаш авылында туа.

Матбугатта беренче мәртәбә ул 1959 елның октябрендә «Комсомолец Татарии» газетасында «Карта Старика» исемле хикәясе белән күренә.

1971 елда Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә аның «Суд совести» спектакле куела.

1976 елда ул «Дәвам» пьесасы өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Д.Вәлиев – 1973 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

2010 елның 1 ноябрендә Казанда вафат була.

Композитор Мирсәет Яруллинның тууына 80 ел

Композитор, педагог, ТАССРның, Каракалпак АССРның, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты, Республиканың М.Җәлил исемендәге мәртәбәле бүләк иясе Мирсәет Заһидулла улы Яруллин 1938 елның 12 июлендә Татарстанның Мамадыш районындагы Кече Сөн авылында күренекле музыкант, мәшһүр Тукайны күреп белгән Заһидула Яруллин гаиләсендә туа.

1977-1989 елларда Татарстан Композиторлар берлеге рәисе вазыйфасын башкара.

2009 елның 6 апрелендә Казанда вафат була һәм Татар зиратында җирләнә.

«Соңгы бер 50 ел эчендә музыкада үзгәреш тасвирлау чараларын кулланунның үзенчәлегендә. Шуңа күрә, безнең татар композиторлары да аннан төшеп кала алмый. Татар кешесе беркемнән дә ким түгел. Европа нишли, Азия нишли, Америка нишли – без, бөтенесен күз алдында тотып, алардан калышмаска тиеш. Мин бернәрсәгә генә бераз үкенеп карыйм. Менә шушы музыкаль процесста моннан 50 ел элек грузиннар, әрмәннәр, азәрбайҗаннар үзләренең стильләре белән килеп керде һәм күпмедер рәвештә дөньяның музыка агымына тәэсир итә алды.

Ә безнең әле бу дәрәҗәгә үсеп җитә алганыбыз юк. Мин моңа бераз борчылам. Тыйнаклык түгелдер, әгәр дә Фәрит Яруллин исән булса, ул Хачатурян белән бер урында, бер биеклектә булыр иде. Менә ул шундый омтылышны бәлки ясаган булыр иде. Киләчәктә күтәргә кала. Аллага шөкер, консерваториядә бик талантлы яшьләр укый. Киләчәктә безнең халык үз сүзен әйтәчәк әле ул, мин аңа бик ышанам».

Мирсәет Яруллин

Рәссам Эрот Зариповның тууына 80 ел

Танылган рәссам, график, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1985) Эрот Якуп улы Зарипов 1938 елның 20 июлендә Свердловск өлкәсендәге Иштирәк авылында дөньяга килә.

1965 елда Львов шәһәрендәге полиграфия институтын тәмамлый.

1977 елдан СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы.

Танылган линогравюралары: «Туган авыл» (1966-1970); «Татар мәгърифәтчеләре» (1990); «Багышлаулар» (Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Роберт Миңнуллин, Гариф Ахунов, 1996-1998).

2009 елның 12 маенда вафат булды.

Садри Максудиның тууына 140 ел

Күренекле җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче, язучы, юрист, профессор Садретдин Низаметдин улы Максудов (Садри Максуди) 1787 елның 23 июлендә Казан губернасының Казан өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Биектау районы) Ташсу авылында мулла гаиләсендә туа.

1888-1894 елларда Казанда Күл буе мәдрәсәсендә укый, аннан Учительская школаны бетерә. Ахырда Парижда Сорбонна университетының юридик факультетын тәмамлап кайта.

1917 елда Милли Идарә рәисе итеп сайлана. Милли Идарә туздырылгач, 1918 елны эмиграциягә китә.

«Мәгыйшәт: милли хикәя» (Казан, 1900) – С.Максудиның төп басма китабы.

Садри Максуди-Арсал (Арсал – аның Төркиядә алган фамилиясе) 1957 елның 20 февралендә Истанбулда вафат була.

«Бу гаиләдә белемгә омтылыш көчле була, чөнки үз заманының шактый укымышлы кешесе буларак, Низаметдин мулла Төркиядән төрле гәзит-журналлар, китаплар кайтарткалап торган. Шуннан кайткан төрек әлифбасыннан Садри укырга өйрәнә. Ул башта үз авыллары мәдрәсәсендә – әтисендә укый, аннан Казанда абыйсы Әхмәтһади мөгаллимлек иткән Галләмия мәдрәсәсендә белем ала. Биредә ул сигез ел буена төрек, гарәп, фарсы телләрен, ислам фәлсәфәсен, дин белемнәрен өйрәнә. Ләкин, тора-бара, абыйсы Һади өендәге төрекчә китап-журналлар, «Тәрҗеман» гәзите генә яңалыкка сусаган һәм кызыксынучан табигатьле яшүсмер егетне инде канәгатьләндерми башлый: ул үзлегеннән русча өйрәнергә керешә».

***Фәридә Гаффарова**, тарих фәннәре кандидаты. –*
Сөембикә. – 14 ноябрь, 2016 ел ■

ЗАҺИТ ТАЗ

Зәки Зәйнуллин

Ул карт турында язасы да килми. Вә ләкин ул язманың Эстәрлебаш тарихы өчен кирәк икәнен аңлау мине көчләп яздыра.

Без 1936–1946 елларда район үзәге пожарныенда гаилә белән яшәдек. Бер бүлмәдә алты җан: әтиәни һәм аларның балалары – Гарифулла, Рәшидә, Мансур, Зәки. Әти, район пожарные башлыгы булса да, колхозник булып трудоденьга эшли.

Пожарныйдан соң сул якта тыкрык. Аның икенче ягында Гариф Танау исемле балта остасының йорты. Урам аша әлеге йортка Фәттах Ташчы йорты, аның кырында Заһит Таз яши. Ул картның маңгаеннан алып баш түбәсенә кадәр чәче юк – таз! Ап-ак сакалмыек, бите һәрчак азрак кызарыбрак тора – азрак «салмыш» кешенеке кебегрәк. Заһит Таз бертуктаусыз «нас» дигән тәмәке суыра.

Яшәешенең соңгы елларында шул «нас» дигән тәмәке авызының ике ягыннан яшел төстәге селәгәй булып ак сакалына агып төшеп, аны яшел төскә буяп пычрата торган иде. Әтием Лотфулла сөйләгәннән:

– Унсигезенче елның август-синтәбрендә аклар үзләренең гаскәренә дәбрәвүлесләр җыйдылар. Заһит Таз шунда авылның Базар мәйданында җыелган халык алдында чыгыш ясады:

– Бу Алла каргаган сәүит влачының инде бетеп барганын күрдек. Аллага мең шөкер! Шул Алласыз влач дөмексен, бетсен, дип, мин – Заһит Фәйзуллин үземнең егерме яшьлек улым Нәсибулла Фәйзуллинны аклар гаскәренә дәбрәбүл итеп бирәм. Кулына мылтык алсын, биленә кылыч таксын, сугышсын кызыл шайтаннар белән, Алласыз камиссарлар белән. Шул каһәр суккан кызылларны җиңеп кайтсын үзебезнең авылга.

Ирекле солдат булып, унсигезенче елны авылдан чыгып киткән егерме яшьлек Нәсибулла Фәйзуллин. Кызыллар белән сугыша-сугыша, Урал, Себер, Ерак Көнчыгышны үтеп, Спасск каласына кадәр барып җиткән. Спасск каласы янында зур бәрелештә Нәсибулла кызылларга әсир төшкән. Аны шунда Спасск каласыннан йөз чакрым чамасы тайга эченә кертеп, бер авылга «поселение»га урнаштырганнар. Нәсибулла абзый 1946 елны хатыны Нәзирә, ике кызы, бер улы белән авылга кайтты. Заһит бабайга охшаганрак илле яшьләр чамасындагы, арка бөкресе чыга башлап картая башлаган кеше. Заһит бабай аларны яшәргә үзенә кертмәде. Ә өе алтыпочмаклы, зур, өчәү генә яшиләр иде. Фатирдан фатирга күчеп йөреп, ках-кох йөткереп, кырык сигезенче елны вафат булды Нәсибулла абзый. Нәзирә апа өч баласы белән Эстәрлетамакка, Нәсибулла абзыйның сеңлесе янына күченеп китте...

1941 елны сугыш башлангач, нәчәлство Заһит Тазны атка атландырып, кулына каештан үргән чия саплы камчы тоттырып, колхоз яланнарына «надзиратель» итеп куйды. Авыл шулай атады Заһит Тазның атка атлануын. Заһит Таз патша заманнарын картларның исенә төшереп, «надзиратель» булды. 1945 елны фронтовиклар сугыштан кайтканчы ятим, ирләре фронтта һәлак булган күп балалы хатыннарга, аталары сугыштагы бала-чагаларга, карт-корыларга, авыл халкына күрсәтте Заһит Таз «күрмәгәннәрен»!

Атка атланып, уң кулына камчы тотып килеп чыга чабылган иген басуына. Ә анда бала-чага, карт-коры башак җыялар – кыш ашарга кирәк, ә колхоз сугыш елларында трудка бер грамм да икмәк бирми: «Икмәк – фронтка!» Заһит Таз башак җыйган бала-

чаганы, карчыкларны, хатын-кызларны камчылап кыйный. Аларны өер итеп җыйнап, башаклы капчыкларын тартып алып бер урынга өя. Атлы арбага төяп, колхоз келәтләре янына озата. Алар шунда әрәм-шәрәм булып бетәләр. Бала-чага, ирсез хатыннар ач кала. Районда ачтан үлүчеләрнең иң күбесе Эстәрле авылының «8 нче Март» исемле колхозында эшләүчеләр булды.

Заһит Тазның ул кара эшен «8 нче Март» колхозы рәисе, 1942 елда фронттан җәрәхәтләнеп кайткан Йомадилов нык итеп хуплап, башакчыларны кууда үзе дә катнаша. 1943 елда башакчыларны тарантаста бастырып, колхозның Кара айгырын яндырып үтерде. Заһит Таз белән Йомадиловка башакчыларны куугa финагент Чолык Зәйнәбе кушылып, «8 нче Март» колхозчыларын талауны бик нык үтәделәр. 1943 елның язы килеп җитмәс борын Эстәрлебаш авылында 20-25% халык ачтан үлде. Мисал өчен: Сәләвәй Бакыйры – фронтта, хатыны Гәйшә апаның җиде баладан дүртесе 1943 елның язында ачтан үлде. Икесе Карагыш авылы балалар йортында үлмичә тере калдылар, олы улы Зәки сугышка китеп исән кайта алды.

Заһит Таз 1945 елның көзенә кадәр, кулына камчы тотып, авылны изепме-изде. Кырык биштә фронтовиклар кайткач, төнен кереп, Заһит Тазны ике мәртәбә кыйнадылар. Чолык Зәйнәбе гаиләсе белән Урта Азиягә качып чыгып китте. Ә Йомадилов нәрсә өчендер төрмәгә эләкте. Ул чакта райсовет рәисе иде. Төрмәдән нык имгәнеп, кайтты. Авылда: «Өтермәдә бик нык кыйнаганнар тоткыннар!» – дигән гайбәт йөрде. Шул кырык бишнең көзендә камчысын юк итеп, ат менеп, ач балаларны бастырып йөрүдән туктады Заһит Таз.

1939 елның декабрь ае. Урамда суык 40 градуска җиткән көннәр. Правлениегә каршы карлы урамда кошевка чанага колхозның «Уфимский» исемле пеләмән айгыры җигелгән. Чана эченә күп итеп печән салганнар. Заһит бабайның кече улы Хәйбулланы фин сугышына озаталар. Заһит бабай улын кочаклап елый. Хәйбулла абзый аны юата:

– Елама, эти! Баргач, финга ныклап биргәлибез дә, җиңү белән кайтачакбыз. Бәлки орден-медальләр дә тагып кайтырбыз әле.

Китте «Уфимский» айгырына утырып Хәйбулла Фәйзуллин фин сугышына. Тик кайта алмады орденнар тагып, шунда фин җирендә мәңгегә калды.

«Уфимский» җигелгән чана Хәйбулла абыйны утыртып алып китте. Заһит бабай, килене Өммегөлсем апа, дустым Бабач Равиле белән мин басып торып калдык урамда. Заһит бабай белән килене кайтып киткәч, Бабач миннән сорый:

– Фин сугышы кайчан бетәр икән?

– Аның беткәне сиңа, Бабач, нәстәмә инде?

– Без үсеп җиткәнче бетмәсен иде. Без дә синең белән сугышка китәрлек булып үсеп җитәр идек тә, «Уфимский» айгырын җиккән артлы чаналарга утырып сугышка китәр идек. Менә бәхет, әй!

Мин дәшмим. Ни өчендер сугышка китәсем килми. Авылда гына яшисем килә. Чана, чаңгы шуып кына...

Рига ракета училищесында инженерлыкка укып йөргәндә, авылга ялга кайттым. 1961 ел иде бугай. Пожарныйга кергән идем, анда Заһит бабай утыра. Бик нык картайган, бетеренгән, үтә дә ярлы итеп киенгән, ках-кох килеп бертуктаусыз ютәлли. Авызыннан яшел лайла булып аккан «нас» тәмәкесеннән сакалы ямь-яшелгә буялган. Хәйран булып уйлап куйдым: «Сугыш елларында ачтан үлгән сабый балаларның күз яше төшкән инде бу кансыз, вөҗдансыз картка».

РЕДАКЦИЯДӘН:

Даими авторыбыз, язучы Зәки Лотфулла улы Зәйнуллинга 10 июльдә 85 яшь тула. Аны юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек белән хәерле озын гомер һәм иҗат уңышлары теләп калабыз. ■

Безнең мирас №7 июль 2018

МИЛЛИ МӘГАРИФ КАҺАРМАНЫ

Хәнәфи Бәдигый

Хәләф Гарданов

Күренекле милли мөгаллимнәребез арасында тәрҗемәи хәлләре данлы, кызыклы-мавыктыргыч кына түгел, гыйбрәтле язмышларга дучар ителгәннәре дә байтак. Монархияле патша Русиясенең дә, тоталитар Совет хакимиятенең дә иҗтимагый-сәяси, карагруһчыл милли-шовинистик, репрессияле тегермән ташлары арасында имгәтелгәннәре дә, юк ителгәннәре дә аз түгел. Аларның күбесе галим, язучы, журналист, дин әһеле буларак та халык хәтерендә тирән эз калдырган.

Бер гаепсезгә өч тапкыр кулга алынып, 1938 елның 15 февралендә нахактан атып үтерелгән күренекле тарихчы, педагог, җәмәгать эшлеклесе Һади Атласов; репрессияләрдән имгәтелгән нәшир, педагог Шиһаб Әхмәров; сөргеннәргә сөрелү ачысын татыган дин галиме, мөдәррис-педагог, мәшһүр мөфти Галимҗан Баруди; дин галиме, публицист, эзәрлекләүләрдән чит илгә качып китәргә мәҗбүр булган җәмәгать эшлеклесе, Ырынбурдагы атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсенең мөгаллиме Муса Бигиев; тарихчы-галим, мөгаллим, йөзләрчә мәкалә, монографияләр авторы, шулай ук чит илгә чыгып качарга мәҗбүр булган Зәки Вәлиди; тәнкыйтьче, тел-әдәбият белгече, мөгаллим, репрессия корбаны Җамал Вәлиди; татар әдәбияты классигы, җәмәгать эшлеклесе, ялкынлы милләтпәрвәр, чит илгә китәргә мәҗбүр булган Гаяз Исхакый; күренекле җәмәгать эшлеклесе, хокук белгече, язучы, педагог, шулай ук чит илгә китәргә мәҗбүр булган, Төркиядә парламент депутаты дәрәҗәсенә күтәрелгән Садри Максуди дип санап китсәк, шундый язмышка дучар ителгән әле тагын бик күп мәшһүр шәхесләребезне күрсәтә алыр идек. Һөҗүм бүген дә дәвам итә.

Бүгенге катлаулы вазгыять вакытында без ихтыярсыздан, исемнәре алда саналган күренекле шәхесләребез белән бергә, күпкырлы эшчәнлекләре аша киң танылган, көрәш байрагын кулларыннан төшермәгән, алар юлын дәвам иткән безнең заман мөгаллимнәрен дә искә төшерәбез, шулардан үрнәк алырга омтылабыз. Тормышның алгы сафында атлаучы андый мөгаллимнәребез дә, шөкер, аз түгел.

Шундыйларның берсе сыйфатында, күптән түгел арабыздан киткән күренекле галим-педагог, язучы, үткен каләмле журналист, җәмәгать эшлеклесе, ялкынлы милләтпәрвәр, кыю, көчле ихтыярлы Хәләф Шакирҗан улы Гардановның якты истәлеген яңарту да урынлы булыр.

Ул 1932 елның 20 октябрендә Башкортстанның Чакмагыш районы Каракөчек (хәзерге Үрнәк) авылында колхозчы-тегермәнче гаиләсендә туа. Бабасы Шаһигардан Габдекәй атаклы Каргалы мәдрәсәсен тәмамлаган указлы мулла, хаҗи була. Билгеле, аның улы Шакирҗанга да, оныгы Хәләфетдингә дә совет чорында ата-бабаларының юлын дәвам итү насыйп булмый.

Хәләфнең балачагы дәһшәтле сугыш елларына туры килә. Газаплы-михнәтле авыл, шәһәр тормышын да күрә, Гаврош кебек, полигоннарда патроннар, гильзалар җыеп йөри, ялгыш атылып китеп, чак кына үзенә тими калганнары да була.

Хәләф Гарданов мәктәптә укыганда ук шактый җитлеккән шигырьләр яза, сәхнә әсәрләре иҗат итә, алар авыл клубы сәхнәсендә куела. Ул укучыларның үзидарә оешмаларын да җитәкли.

Егет, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Уфадагы Башкорт дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында укый, шул елларда республика матбугатында шигырьләре, хикәяләре, очерк һәм мәкаләләре басыла башлый, студентларның «Чаян» исемле стена газетасының редакторы була. Ул бераздан «Яшь көчләр» дигән әдәби альманах төзи һәм аны татар-башкорт телләрендә дәүләт типографиясендә нәшер итә. Шушы әдәби-фәнни эшчәнлеге өчен аңа, институт тарихында беренче булып, СССР Югары белем министрлыгының Мактау грамотасы бирелә.

1957 елда, Октябрьнең 40 еллыгы уңаеннан, Башкорт дәүләт университеты ачыла. Шунысы кызыклы: 1953 елда төзелә башлаган ул уку йортының беренче нигез ташын салу уку отличнигы Хәләф Гардановка тапшырыла. Алай гынамы соң әле: ул салган таш төзеләчәк бинаның почмагына туры килеп, шуның өстендәгесе ректор бүлмәсе булып китә һәм җитәкче аңа, иң уңайлысы, дип, бик теләп кереп урнаша.

Югары белем алгач, Хәләф Гардановны, университетның укуда һәм җәмәгать эшендә иң алдынгы студенты буларак, Казан дәүләт университеты аспирантурасына максатчан укырга җибәрәләр.

Фән дөньясына кереп, гыйльми-педагогик эшчәнлеккә керешкәнче, ул башта Көньяк Уралда радиожурналист, чакыру буенча «Татарстан яшьләре» газетасының комсомол-яшьләр бүлегендә, «Социалистик Татарстан» газетасында махсус хәбәрче, Рафаэль Мостафин, Рөстәм Кутуй белән бергәләп, шул елларда Казанда яңа ачылган телевидение студиясенең әдәби-драматик тапшырулар бүлегендә эшләп, үткен каләмен тагы да ныграк чарлый.

«Социалистик Татарстан» газетасындагы фидакарь хезмәте – үзе бер кызыклы һәм гыйбрәтле тарих. Ул, чыга башлавының 50 еллыгы уңаеннан, газетаны орден белән бүләкләүгә бәйле маҗаралы вакыйгалар белән үрелгән.

Газета 1918 елның 12 апрелендә, ил башкаласының Петербургтан Мәскәүгә күчү вакыйгасы уңаеннан, «Эш» дигән исем белән чыга башлый. Аның беренче саннары драматург Галиәсгар Камал өендә әзерләнә, ул аның рәссамы да була. Газетага дәүләт бүләге бирү өчен, аның максаты Һәм программасы бәян ителгән менә шул беренче саннарын табарга кирәк була. Тик аларның рәсми рәвештә кайда теркәлүе дә, саклану-сакланмау-

лары да мәгълүм түгел икән. Салам эскертеннән энә эзләү кебек четерекле, билгесез шундый эшне Хәләф Гардановка тапшыралар. Көтелмәгән бер очрак, дөресрәге, репрессия корбаны булып 18 ел төрмәдә утырып чыккан Мәхмүт Бөдәйле белән очрашу аңа газетаның шул тәүге саннарын табарга ярдәм итә. 30 нчы елларда министр булып эшләгән бу зыялы шәхес шул «Эш» исеме белән чыга башлаган газетаның беренче саннарын өй ишегенең тышчасы эченә яшереп куйган була. Кайткач, ул аны Татарстан Дәүләт музеена тапшыра. «Эш»нең менә шул беренче саннарын Хәләф Гарданов эзләп таба да инде.

Икенче көнне иртән, газетаның шундый саннары табылу турында КПСС Үзәк Комитетына хәбәр итәләр. Анда: «Газетаның беренче санын кем тапкан булса, шул кеше алып килсен!» – дигән таләп куялар. Шулай итеп, Мәскәүгә – Үзәк Комитетка бару һәм орден алып кайту вазыйфасы Хәләф Гардановка йөкләнә.

Үзәк Кмитетта аны исеме сәер рәвештә мәгълүм әсәр героена туры килгән Тарас Бульба атлы кеше кабул итә. Хәләф Гарданов аңа 2-3 сәгать дәвамында гарәп хәрефле шул газетадагы язмаларны рус теленә тәрҗемә итеп бирә. Ул аның тәрҗемәләреннән канәгать булуын белдерә һәм төштән соң шундый мәгълүмат белән СССР Югары Советы Президиумына керәчәкләрен әйтә. Бу вакытта аның рәисе Николай Подгорный була. Бераздан, киңәшмәдә катнашучылар чыгып: «Социалистик Татарстан» газетасын Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләү турында Указ әзерләнә», – дип белдерәләр. Хәләф Гардановка башкаланың теләсә кайсы кунакханәсендә ял итү өчен өч көнгә урын бирелә, шул арада Указ да әзерләнә.

Орден алып Казанга кайтышына, Татарстан Журналистлар берлеге аңа, бу җаваплы эшне уңышлы башкарып чыгуы өчен, чит илгә сәяхәткә барырга путевка тәкъдим итә. Ул Төркияне сайлый. Петр Іне Ауропага тәрәзә ачучы, дип сөйләгәннәре кебек, Хәләф Гарданов та Совет хакимияте яшәгән 50 ел эчендә, мөселман илләре белән элемтәләр бөтенләй өзелгән чорда, Казаннан Төркиягә барган – «тәрәзә ачкан» беренче кеше була.

Төркиядән кайткач, Хәләф Гарданов, андагы яхшырак тормыш турында курыкмыйча дөресен сөйләп, матбугатта бер-бер артлы зур күләмле өч очерк язып бастыра. Бу шулай ук СССР яшәгән чорда Төркия турында бирелгән беренче мәгълүмат була.

Һәм менә шул уңайдан үзләренә дан-дәрәҗә, зур абруй дәгъвалап йөргән берничә язучының көнчелек-хөсетлек өянәге кузгала. Алар: «Нишләп аны кулга алмыйсыз, ул ак эмигрантлар, халык дошманнары белән очрашкан бит, капиталистик Төркияне, андагы тормышны мактап бер-бер артлы очерклар яза», – дип, өстеннән шикаять язалар. Билгеле, аны тиешле җиргә «әңгәмәгә» чакырып алалар, тик аның ни өчен баруын яхшы белгәнгә, артык тәфтишләп тормыйлар.

Әмма, аккан су тынар, дошман тынмас, дигәндәй, шикаятьчеләр туктап калмый: «Аны органнар яклый, ул аларга хезмәт итә икән!» – дигән гайбәт тараталар. Шулар һәм аларның иярченнәре, үзләре уйлап чыгарган уйдырмаларына таянып, дистәләгән повесть, хикәяләр, поэмалар, либреттолар һәм бик күп шигырьләр язып бастырган, биш әдәби китабы басылып чыккан язучы Хәләф Гардановны, өч тапкыр тәкъдим ителеп тә, Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул итмәүне оештыралар.

Шуннан соң ул фән, мәгариф юлына кереп китә: кандидатлык диссертациясе яклый, соңрак докторлык диссератациясен әзерли, дәреслекләр төзи һәм бу өлкәдә гаять нәтиҗәле эшчәнлек күрсәтә, әмма каләмен чарлаудан да туктамый: матбугат битләрендә проблемалы мәкаләләр язып бастыра.

Хәләф Гарданов башта СССР Педагогия фәннәр академиясе каршындагы милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтында, шул ук академиянең профессиональ белем бирү фәнни-тикшеренү институтында, ВЦСПС каршындагы Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү институтында социолог булып эшли.

30 ел эчендә аның биш уку дәреслеге 30 тапкыр басылып чыга. «Кызыл байрак» дигәне Россия Мәгариф министрлыгы дипломына лаек була, икенче сыйныф дәреслеге – «Салават күпере» 14 тапкыр яңартып басыла. Шунысы да бар: Мәскәүнең Югары Аттестация комиссиясе өч мең диссертация арасыннан иң яхшылары дигән 13 хезмәтне сайлап ала, шуларның берсе Хәләф Гардановныкы була. Шуның өстенә аның 5 әдәби китабы да дөнья күрә.

Югары уку йортларында укыту барышында ул өлкән педагог, доцент, профессор дәрәҗәләренә ирешә, 1993 елда Татар милли университетын оештыра һәм аның беренче ректоры була, иҗтимагый халык хәрәкәтенең күренекле лидерларыннан берсенә әйләнә. 1988 елның 27 июнендә оешкан халык хәрәкәте үз алдына җитди бурычлар куя, көрәш максаты да ачык күрсәтелә: татар халкының дәүләтчелеген торгызу; татар халкының иҗтимагый һәм милли аңын уяту; милли телен үстерү; татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү; милли басмаларны булдыру; милли университетны ачу (үзебезнең түрәләр баш тарта); Татарстанга союздаш республика статусын бирү һ.б. Ул елларда милли хәрәкәт лидерлары, Татарстан халыкларының хокукларын яклау белән генә чикләнмичә, элекке Союздагы халык хәрәкәтләренә һәм бөтендөнья даирәсендәге демократик хәрәкәтләргә дә катнашып, җитди эшләр башкара. Балтыйк буе республикаларының СССРдан аерылып чыгуын караган, 1989 елның май аенда булган халыкара конференциядә Марат Мөлеков белән Хәләф Гарданов та катнаша. Алар бу республикаларның әлеге конференциядә кабул ителгән программаларын хуплап тавыш бирә. Сүз биреп, алардан татар телендә чыгыш ясауларын сорыйлар. Милләтпәрвәрләрнең ул чыгышлары бөтен Европа илләренә тапшырыла һәм әчтәлеге төрле телләргә тәрҗемә итеп бирелә.

Тарту шәһәрендә үткәрелгән Халыкара конгресска чакыру алгач, Татарстан Республикасының суверенлыгы турында Декларация кабул ителүнең икенче көнендә Бөтентатар иҗтимагый үзәге (БТИҮ) идарәсе Х.Гардановны шушы Конгресска делегат итеп җибәрә. Өченче сентябрьдә ул тантаналы төстә Татарстан Республикасының суверенлыгы турында Декларация кабул ителү турында белдерү белән чыгыш ясый. Катнашучылар моны аягүрә басып алкышлый. Шул ук Конгресста Бөтендөнья вәкаләтсез милләтләрнең (алар биш меңнән артык) халыкара оешмасын төзү турында Меморандум әзерләнә һәм кабул ителә. Аны гамәлгә ашыруда Х.Гарданов та актив эшчәнлек күрсәтә: тугыз автор арасында аның да култамгасы салынган әлеге документ бүген дә Берләшкән Милләтләр Оешмасының (БМО) сейфында саклана.

1991 елда, Марат Мөлеков белән бергә, ул Берләшкән Милләтләр Оешмасы ассамблеясында катнаша һәм яңа оешманың (ЮНПО) байрагы итеп, 18 тәкъдимнең иң уңышлысы буларак, аларныкы кабул ителә.

Хәләф Гарданов Татар югары белем бирү иҗтимагый хәрәкәтен оештыра һәм аның президенты булып сайлана, Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең даими вице-президенты вазыйфаларын да башкара. Аның «Татар мәктәбе» дигән монографик хезмәте милли мәгарифнең бай тарихын, татар мәгарифенең бүгенге системасын, аның күптөрле проблемаларын фәнни нигездә яктыртуга багышланган.

Күренекле галим-педагог – Татарстанның атказанган укытучысы, Россия гуманитар фәннәр академиясе академигы, Россия Язучылар берлеге әгъзасы, Кол Гали исемендәге Халыкара бүләк иясе, үткен каләмле журналист, җәмәгать эшлеклесе, ялкынлы милләтпәрвәр, көчле ихтыярлы Хәләф Гарданов гомер юлын әнә шулай нәтиҗәле, горурланып сөйләрлек итеп уза. Үлчәү йолдызлыгы астында туган бу зыялы шәхескә, исән булса, 85 яшь тулган булыр иде. ■

ӘЗ-МӘЗ ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Равил Шәрәфи

1952 елда ике укучыны, ягъни минем белән гел «бишле»гә генә укучы Әкрам Шәриповны, яраткан укытучыбыз Габдулла абый Яруллинга ияртеп, Казанга җибәрделәр. Габдулла абый безне Башкорт академия театрына алып барып, ике спектакль күрсәтте. Бу минем беренче тапкыр зур сәнгать белән очрашуым булды. Сөйләшүләре әйбәт аңлашылса да, күңелдә: «Ник болай сакау сөйләшәләр икән соң болар?» – дигән сорау калды.

Икенче бер көнне укытучыбыз безне Офицерлар йортындагы (хәзер анда Мэрия) данлыклы Александров ансамбле концертына алып барды. Монда инде безнең соклануыбызга чик булмады. Яраткан укытучыбызга рәхмәтебезне ничек җиткерергә белмәдек. Соң булса да уң булсын, дигәндәй, инде байтак кына вакытлар үткән булса да, шушы кылган игелеге өчен Габдулла абыебызга бер яхшылык эшләүне насыйп итте Ходай. Бу вакытта мин ярыйсы гына танылган артист кеше. Г.Камал театрында эшлим.

Дәвамы. Башы журналның 4 нче (2018) санында.

Һәм менә безнең театр бинасында БДАТның гастрольләре бара. Мин тамашачылар йөри торган ишектән кереп килгәндә, касса тәрәзәсе төбендә нәүмиз генә басып торучы Габдулла абыебызны күрәм. Башкорт спектакльләренә билетлар, һәрвакыттагыча, алдан ук сатылып бетү сәбәпле, Габдулла абыебыз, карап булмый икән, дип, нишләргә белми тора иде. Мин инде башкорт дуслар белән дә яхшы ук таныш, тиз генә кереп, Габдулла абыйга бер чакыру билеты юнәтеп чыктым. Шуның белән бер атуда ике куян, дигәндәй, бурычым да түләнде, һәм шушындый сәнгать җанлы кешене хөрмәт итә алуымнан күңелем рәхәтлеккә тиенде.

Миңа сәхнә җене йоктырган бу шәхеснең урыны оҗмахта булсын иде. Ничәмә-ничә тапкырлар без каникуллар вакытында аның җитәкчелегендә күрше тирә-як авыллары буйлап концертлар куеп йөрдек. Нәкъ шушы елларда Муса Җәлилнең иҗаты, данлы исеме төрле ялалардан арынып, халыкка кайтты. «Моабит дәфтәре»ннән яратып ятлап алган шигырьләрен төрле сәхнәләрдә яттан сөйли идем. Әле районда узган ярышта «Кичер мине, илем» шигырен укып әллә лауреат, әллә дипломантмы шунда булып та кайттым.

Унөч яшемнән, атлар көтүне калдырып, олылар белән беррәттән эскерт салырга йөрдем, печән чаптым һәм, грузчик рәвешендә машина фәләннәргә утырып, Рыбныйга олы-олы капчыкларга салынган ашлыкны ташырга, бушатырга йөри башладым.

Кемнең ничектер, әмма минем күңелдә үкенечләр дә калгалады. Мәктәпнең сигезенче сыйныфында безгә читтән килгән укытучы Гайшә апа инглиз телен укытырга кереште. Без аны үзара «Нәү апа»дип йөрттек. Чөнки, ул гел «ноу», ягъни «юк» сүзен кабатлар иде. Аңарда бер генә ел укып калсам да, шул кыска гына вакыт эчендә дә мин инглиз телен яхшы ук сукаларга өйрәндем. Әмма минем бәхетсезлегемәдер инде, язга таба Сталин үлеп китте. Һәм безнең ифрат нечкә күңелле «Нәү апа»быз бу кара кайгыдан акылыннан язды. Каһәр төшкән Сталин тагы ике генә ел үлми торса да, инглиз телендә шактый әйбәт сөйләшә башлаган булыр идем бит. Мәгәр насыйп ризык булмаган икән. Ә шулай да, никтер, озак-озак еллар төшләремдә гел инглизчә сөйләшеп йөрдем. Их, Сталин вакытыннан алда дөмекмәгән булса, өннәремдә дә инглизчә сөйләшәсе кеше булганмын ләбаса.

Шулай үз көенә бара торгач, 10 нчы классны да тәмамладык. Бик шәп кенә саубуллашу кичәсе булды. Биедек тә, җырладык та, ашадык та һәм эчтек тә. Әйе-әйе, эчтек, дип тә әйтергә туры килә. Чөнки без Тартар Гыйлмие белән икебезгә бер чүлли дә алган идек. Өебездә акчаны комод тартмасында гына тоталар иде. Менә шуннан беркемнән дә сорап тормый гына, урлап, дип уйлый күрмәгез, сорамый-нитми генә әлеге дә баягы чүллиебез өчен бер сум акча алдым. Чүллинең бәһасе 2 сум иде. Яшь чак – җүләр чак, һәрхәлдә, монсы өчен менә бер дә үкенәсе килми.

Сау бул, мәктәп! Син – миннән, ә мин синнән канәгать! Уку бик тә җиңел бирелгәнгәмедер, уку елларының үтеп китүен сизми дә калдым. Безгә белемне газапламый гына бирә алганнары өчен, бигрәк тә укытучыларыма рәхмәт әйтергә тиешмендер.

Инде кая барырга?!

Мәктәптә уку берни түгел икән бит, менә тәмамлаганнан соң – тәккый гаҗәбемне әйттерделәр: нишлим, кая барыйм, кем булырга инде хәзер, дип шактый баш ваттым? Күпме газета бар – барсы да минем алда. Газеталарда игълан өстенә игълан: фәлән җирдә фәлән уку йорты, анда да чакыралар, монда да сине көтеп торалардыр кебек. Шулай да саташып-нитеп калмадым, игълан чытырманлыклары арасында баштарак адашып йөрсәм дә, Авыл хуҗалыгы институты дигән маякны күреп, шуның күңелемне үзенә тарткан агрономия факультетына тукталдым. Ни өчен дигәндә, безне бит инде кечкенәдән җирдә казынырга, җирне яратырга авыл үзе өйрәтеп үстерде. Әйе, иң якы-

ны, мин иң белгән нәрсә шул җир бит инде мәйтәм. Җир миңа һәрчак җанлы, тере булып күренә иде. Хәер, хәзер дә шулай ул, могҗиза белән тулы җир минем өчен изге. Гомер буе җиргә якын булырга тырышып яшим. Шулай итеп, бүтән профессияләрне бар дип тә белмәгән Шәрәфи документларын, Аллаһ теләсә, җир кешесе булам, дип, комиссиягә илтеп тапшырды. Имтиханына килеп, сорау язылган билетны алып җавап бирергә тотынды, ә анда, каһәр генә икән, җир кешесенең төшенә дә кермәскә тиешле сорау – химия турында! Химия дигән фәндә мин белгән сыңар сорау да юк. Бөтен белгәнем H_20, лакмус кәгазенең сыекчага тыккач алсулануы, ниндидер порошокның суга салуга «пошт» итеп кайнап китүе, бака ботына кислота тидергәч, тегесенең аягын тартып алуы. Шулай итеп, минем белгәннәремә икеле дигән бәя куелды. Ансы бик симез икеле булганга, кәефемне күтәреп җибәрде. Ни дисәң дә, симезне яратабыз. Үзем арык булсам да, икелем симез иде шул.

Документларымны алып, 65 чакрымдагы туган авылым Олы Солтанга юл тоттым. Озын юлым Күн авылы урманнары, Түгәрәк урман, Никкүчтем авылы тирәсендәге Тирән чокыр аша иде. Бу яманаты чыккан Тирән чокыр дигәннәрендә безнең авылның май, күкәй сатып кайтып килгән авыл кешеләрен шактый еш талап калганнарын белсәм дә, симез икелемә кызыкмаслар әле, дигән уй беләндер инде, кычкырып җырлап кайттым. Белмәүнең дә шәп яклары бар икән бит ул. Белә торып бирә алмаганнар кычкырып елый, кайберәүләре үз-үзенә кул салырга маташа, ә мин, белмәгәч, бирә алмавыма исем дә китми. Белә торып та, ниндидер белмәгән сорау әләгү аркасында гына керә алмый калсаң, чыннан да читен буладыр. Ә минем монда белмәгән сорау әләгү куркынычы нольгә тиң булды.

Ничек итеп кайтып кереп урынга ауганымны хәтерләмим дә – арылгандыр инде. Әмма менә йокымның искиткеч татлы булганы һаман хәтердә. Рәхәтләнеп йоклап калдым сабый чакларда гына, диләр бит.

Иртән торып тышка чыксам, каршыма авыл советы председателе килеп ята. Әйе, рәис димиләр иде әле ул чакта, председатель дип йөртәләр иде үзләрен.

– Нихәл, биреп булдымы?

– Бирдем, бөтенесен бер керүдә үк биреп чыктым.

– Молодец. Ничек соң алай – бер керүдә?

– Бөтен белгәнемә «2»ле. Беренчесендә үк!

– Ай, әйбәт булган бу! Безнең клубка завклуб кирәк. Бүгеннән үк эшкә тотына аласың!

Клубның ачкычы минем кулга күчте. Мин хәзер мөдир кеше. Элек бу эшне избач дип йөртә торган булганнар. Янәсе, уку йорты (изба-читальня) җитәкчесе. Тик мин бу йортны җитәкләргә төнлә генә кайтам. Аңа кадәр көне буе бөтен авыл халкы белән кырда эшлим. Инде кызу эш көннәре булгач, эштән чыгып арган яшьләргә изба-читальня кирәк булмас, дип уйлыйсың. Юк шул, каһәр, Ходай Тәгалә яшь кешегә арып беткәч тә котырып калырлык көч өстәп бирә. Куып чыгармасаң, таңга кадәр дә утырырлар иде. Җәй, ниһаять, бетмәс-төкәнмәс эшләре, башка сугып тора торган кызулары белән үтеп китте. Шунда гына төп эшемә иркенләп керешү насыйп булды. Мин, уку йортының мөдире булгач, китапларга да хуҗа, ягъни китапханәче дә, лозунглар да язып, үзем үк аларны беркетеп куяр өчен басмалар ташып, лозунгларны кеше кулы җитмәслек җирләргә элеп йөрүче хезмәткәр дә... Баштарак бу лозунг дигәннәре белән булышу әлеге эшнең чын остасы булган Хәлим Җәләлов кулында иде. Әле ярый, аңардан кайбер кирәкле нәрсәләрне өйрәнеп калганмын. Шуңа бу мәшәкатьле эшне башкаруы авыр булмады.

«Мәскәүләрдән кайнар сәлам!»
1956 ел

Эшләсәң, бер ел эчендә дә шактый нәрсә маташтырырга була икән. Хәтта, режиссерга әйләнеп, Таҗи Гыйззәтнең «Габбас Галин» дигән драмасын да сәхнәләштердем. Үземә үк төп рольне дә башкарырга туры килде. Ура-суга комбайн, дигәндәй, бу йөзләрчә һөнәр белүне таләп иткән гаҗәп йортта тагы да эшләргә туры килгән булса, бәлкем пьесалар да яза башлаган булыр идем. Яраткан драматургым Тинчуриннан үрнәк алып, диюем инде. Яшь чак – җүләр чак кына түгел, ул әле зур эшләргә дәшүче, көне-төне тәҗрибәләр үткәреп, үзеңнең яңа якларыңны ачарлык тәвәккәллек бирүче көч чыганагы да. Менә хәзер минем Габбас Галин ролен уйнарга кыюлыгым җитмәс иде. Унҗиде яшьлек чагымда, ике дә уйлап тормый, өлкән яшьләрдәге кешене уйнаганмын, ә менә

хәзер инде яшемә туры килә торган Габбасны уйнарга алына алмас идем. Ә бит әле дә онытып булмый торган рәхәт мизгелләр... Син артык яшь күренәсең, дииюләренә каршы, аксыл кәҗәбез тиресеннән кисеп алып чал мыеклар ясадым. Аны ябыштыру өчен нинди генә тәҗрибәләр уздырмадым. Ахырда авыл медпунктына барып keləйләр таптырып, шуның белән ябыштырып куйдым. Купмады бит тәки. Уйнап чыккач та әле, Аллаһның рәхмәте, һич кубарга теләмәде. Артык тырышырга да кирәкми торгандыр ахры.

Ни булса, шул булды, дигәндәй, «Горький университеты»на әйләнде миңа бу бер ел котырып эшләп алган изба-читальням. Иң мөһимен әйтергә онытып торам икән бит. Авыл клубы җитәкчеләрен язга таба район семинарына чакырдылар. Бардык. Өстәл артында утырам шулай, күземә бер игълан чекрәеп карап тора. Анда Мәдәният министрлыгы белән берлектә ТДАТ театры Мәскәүдә артистлыкка укытыр өчен яшьләрне җыя; уку-укыту эшләре Мәскәүнең Малый театры каршындагы М.С.Щепкин исемендәге театр училищесында буласы, диелгән. Тукта әле, тукта, мин әйтәм, кечкенә чагымда Ходай Тәгалә миңа «агнец божий»ын, ягъни корбан тәкәсен биреп изге кеше ясамакчы иде, кыюлык-фәләнем җитмәде, инде менә бик үк изге эш булмаса да, бик үк алай бозык та булмаган профессия кешесе итмәкче була түгелме соң? Монысын да ычкындырсам, чат бозык профессияне генә тотып калуым да мөмкин бит. Һәм күрегез инде мин кылган «бозыклык»ны: ярамаганын аңлый, бу игъланның башка кешеләр өчен дә монда куелганын белә торып алдым да кесәм төбенә батырып та куйдым. Әмма соңыннан мин аны озак еллар саклап тотканнан соң, театрның музеена, ягъни театр сөючеләребезгә кире кайтардым. Кем белә, ул чакта алмый киткән булсам, тагы кемгә дә кирәге чыгар идеме-юкмы – билгесез, ә болай менә музейны бик кирәкле экспонат белән баеттым. Әле ул игълан үз вакытында аяклы игълан ролен дә үтәде. Белгән-күргәннәргә дә: «Артист булырга теләүчеләргә менә игълан бар», – дип әйтеп йөрдем.

1956 елның август ае. Г.Камал театрында игъланда күрсәтелгән әлеге уку йортына – вакытлар узу белән минем күңел түрендә изге урын биләп алачак Щепкин училищесына укырга керү имтиханнарын уздырдылар. Авыл хуҗалыгы институты имтиханнарында каушамаган идем, монда йөрәк чабыш атыныкыдай дөп-дөп тибә башлады. Комиссиягә Муса Җәлилнең «Кичер мине, илем» шигырен, Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» романыннан Щукарь бабайның ашкамы, әллә боткагамы бака кушып пешергән өзеген һәм дә Крыловның бер мәсәлен укып бирдем. Җюри рәисе – Камал театрының баш режиссеры Ширияздан ага Сарымсаков (урыны җәннәттә булсын) миңа болай дип сүз кушты:

– Карале, Шәрәфиев, син ачулана беләсеңме?

– Белмим, берәүгә дә ачуым килгәне юк.

– Шулай да без синнән сорыйбыз, бик ачуланып кына берәр сүз әйтеп җибәр әле!

Мин шундук:

– Барыгыз да чыгып китегез моннан! – дип кычкырып салдым.

Дәвамы бар ■

Татарстанның атказанган артисты Рәсим Ильясов

Бәхетле моң остасы

Маргарита Фәйзулаева

Казан – талант ияләренә гаҗәеп бай шәһәр. Алар арасында данлыклы шагыйрьләр, күренекле җырчылар, рәссамнар, артистлар күп. Бу язмада шуларның берсенә – оста музыкант һәм соклангыч дирижер, халык уен кораллары сәнгатен армый-талмый дөньяга танытучы Рәсим Ильясовка тукталырбыз. Моңа шактый саллы сәбәп тә бар: быел аның иҗат эшчәнлеген башлап җибәрүенә чирек гасыр – 25 ел тула.

Ульяновск музыка көллиятен, Казан консерваториясен һәм Чиләбе сәнгать академиясе ассистентурасын тәмамлаган Рәсим Ильясовны дан-шөһрәт үзе яулап ала, дисәк тә, ялгышмабыз. Елдан-ел яңа уңышларга ирешә ул: 1998 елда Италиядә (Пья-

Сәхнәдә – «Казан нуры» оркестры һәм аның дирижеры Рәсим Ильясов

ченца шәһәре) узган халыкара конкурста лауреат була, 1999 елда Мәскәүдә оештырылган «Классик мирас» конкурсында, аннары Франциядә үткән Дөнья халыклары фестивалендә шул ук дәрәҗәле исемне алуга ирешә. Бу вакытка Рәсим бар сәләтен һәм көчен сәнгатьнең иң мәртәбәле, әмма, төрле сәбәпләр аркасында, игътибардан иң читтә калган – халык уен кораллары оркестрына багышларга теләвен аңлый башлый.

Туксанынчы еллар ахырына Рәсим Ильясов шәхесе шактый танылып өлгерә. Аны Татарстан мәркәзенә, «Казан» бию ансамбле каршындагы халык музыка уен кораллары оркестрына чакырып алалар. Яшь музыкант җиң сызганып эшкә чума: оркестрның составын киңәйтә, солистлар таба, оркестрга мәгърурәнә яңгыраган «Казан нуры» исемен куша һәм озакламый, тәгаенрәк әйтсәк, 2000 елда, үз илебездә генә түгел, чит җирләрдә дә танылуга ирешәчәк класстер булдыра.

Рәсим Ильясов яңа сыйфатта, яңа коллектив белән (хәзер инде татар милли музыкасы аша) җиһанны яуларга керешә: Тунисга узган халыкара фестиваль-конкурста (2001), Мәскәүдә үткән Халык милли уен кораллары оркестрлары бәйгесендә (2006), Уфада оештырылган шундый ук ярышта лауреат дәрәҗәсенә ирешә. Аның оркестры, җиһанның кайсы гына кыйтгасында чыгыш ясаса да, һәрдаим дәррәү алкышларга күмелә. Мөгаен, шуңа да күрәдер, чит төбәкләргә яисә чит илләргә чыкканда җөмһүрият җитәкчелеге «Казан нуры»н рәсми делегация составына кертми калмый, нәтиҗәдә, Рәсим Ильясов оркестры һәр җирдә Татарстан Республикасы сәнгать осталары концертының күрке булып тора һәм татар музыка сәнгатенең күз өстендәге кашы булуын һәрдаим раслый килә.

Шунысы игътибарга лаек: чит ил сәхнәсенә аяк басканчы, «Казан нуры» җирле милләтләр музыкасын да өйрәнә, аларны концерт программасына кертә. Үз халкы җаныннан ургылып чыккан кадерле, якын моңнарны танып алган казакъ, төрек, үзбәк кадәшләр бу вакытта әйтеп бетергесез ләззәт кичерә, оркестрны алкышлап туймый, аларга чиксез рәхмәт әйтеп, изге теләкләр теләп кала.

«Алар тудырган музыка бай аһәңнәргә, виртуозларча башкаруга һәм киң колачлы яңгырашка ия...»

Затлы-затлы концерт программалары белән дөньяны айкау, дәрәҗәле исемнәргә ия солистларның югары зәвыгы һәм таланты, дирижерның соклангыч башкару осталыгы «Казан нуры»н хаклы рәвештә зыялы, могтәбәр оркестр итеп таныта. Концертларда Рәсим Ильясов сәнгать могҗизасын тулысынча тоярга мөмкинлек бирә: ул гаҗәеп музыка тудыра, оркестр, бербөтенгә әверелеп, тамашачыларны тылсым дөньясына алып кереп китә. Жанр һәм стиль ягыннан шактый төрле булган иҗатында ул Галиҗәнап Тормышның вә аның җанынннан гыйбарәт Галиҗәнап Сәнгатьнең бөеклеген күрсәтә, аларның илаһиятен ача. Ул уздырган чараларда халык шыгрым тулы була, ә икенче көнне мактау язмалары бөтен матбугат чараларында дөнья күрә.

Дирижерның иҗат уңышларын хөкүмәт дәрәҗәсендә таный белүләре дә күңелгә җылылык бирә, орлыкны чүбектән аера белүчеләр дә бар икән ләбаса, дип уйлап куясың, бу уйлар милли сәнгатьнең киләчәгенә өмет белән карарга ышаныч калдыра: Рәсим Ильясов 2008 елда «Татарстан Республикасының атказанган артисты» исеменә лаек була, 2010 елда «Һөнәрмәнд» («Профессионал») номинациясендә Татарстан Республикасы Грантын алуга ирешә.

Җиһанкүләм танылган дирижер Марис Янсонс бер интервьюсында үз һөнәре турында мондый сүзләр әйтә: «Чын дирижерлык талантының ни-нәрсә булуы турында фикер тудыру гаять кыен. Ул, мөгаен, Илаһтан биреләдер, коллективны бергә туплап, аны бер юнәлешкә кертерлек, музыкантларны берләштерерлек, укмаштырырлык көчкә ия эчке энергиядән гыйбарәттер. Шундый аңлаешсыз харизма. Кешедә, булса – бар, булмаса – юк».

Мондый харизма, һичшиксез, Рәсим Ильясовка хас. Шушы сыйфат аңа музыкантларны матурлыкка һәм гармониягә омтылышта берләштерергә ярдәм итә дә. Ул оркестр әгъзалары алдында зур абруйга ия, алар дирижерның һәр ым-ишарәсенә берсүзсез буйсына, Ә уртак максатта бергә-бергә, килешеп эшләсәң, тырышлыкның чын, сәмави музыка тудыру белән тәмамланачагы шөбһәсез.

«Казан нуры» музыкантлары бертигез дәрәҗәдә, камил итеп татар, урыс, чит ил музыкасын башкарырга сәләтле, алар дөнья халыклары фольклоры үрнәкләрен дә, кешелек тарихының төрле дәверләрендә иҗат ителгән һәм жанр, һәм стиль ягыннан кискен аерылып торган җәүһәрләрне дә «кулга җиңелияләштерә». Оркестрантлар үз эшләрен һәрвакыт илһамланып, күңелен салып, яратып башкара. Аларның күбесе – шулай ук мәртәбәле исемнәргә лаек затлар, үз уен коралларын биш бармагыдай белгән, җаны-тәне белән тойган, аңлаган осталар: баянчылар, Татарстанның атказанган артистлары Наил Сәгъдиев, Рөстәм Рәхмәтуллин, балалайкачы Артур Дәүләтшин, бәрмә уен кораллары «хуҗасы» Марат Сираҗетдинов, флейтачы һәм курайчы (свирельчы) Степан Пушин, кларнетчы Олеся Пушина, оркестрның концертмейстеры, домрачы Венера Миловидова, домрачы Диләрә Ильясова, кларнетчы һәм саксофончы Диләрә Вәлиуллина, баянчы Булат Хисмәтов һәм Россия, халыкара конкурслар лауреатлары булган башка солистлар.

Дирижер Рәсим Ильясов «Казан нуры» турында мондый фикердә: «Безнең оркестр – яшь, әмма зур иҗади потенциалга ия һөнәри музыка коллективы. Ул – булмышының һәм тормышының нигезенә бер-береңне ихтирам итү, уртак фикердә булу, килешеп эшләү кебек ихлас вә изге сыйфатлар салынган бердәмлек, сәнгатькәрләр берлеге. Коллектив нибары егерме башкаручыдан торса да, алар тудырган музыка бай аһәңнәргә, виртуозларча башкаруга һәм киң колачлы яңгырашка ия. Кеше саны күп булмаганга күрә, без теләсә кайчан һәм теләсә кайда җәһәт кенә гастрольләргә чыгып китә алабыз. Сәфәрләребез харитасында нинди генә кыйтгалар, илләр юк: Татарстан һәм Россия шәһәрләреннән кала, Италия, Испания, Алмания, Һолландия, Мажарстан (Венгрия), Греция, Тунис, Мальта... Дәрәҗәле конкурсларда җиңү яулау «Казан нуры»н Россия күләмендәге иң мәгълүм оркестрлар исемлегенә кертте һәм Европа дәрәҗәсендәге милли оркестр булуга юл ачты.

Рәсим Ильясов үзенең мөгаллимнәре турында гаять җылы итеп, яратып сөйли: «Ми-

нем тәүге укытучым Евгений Федоров Россия Федерациясенең атказанган артисты, Ульян дәүләт халык уен кораллары оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм дирижеры иде. Сәнгатьнең мондый төренә миндә ул гына мәхәббәт уятты, дисәм, һич арттыру булмас. Җитмәсә, әле Ульяновск музыка көллиятендә укыган вакытта ук укытучым үзе җитәкләгән оркестрда уйнарга, шул рәвешле, сары томшыклы килеш үк, осталыгымны чарларга мөмкинлек бирде. Бу, билгеле, искиткеч мәктәп иде. Без ул чорда төрле шәһәрләрдә концертлар куеп йөрдек: Нижгар, Самара, Тверь, Мәскәү...

Казан консерваториясендә безне Сәгыйть Хәбибуллин, Тәлгать Әхмәров, Рәшит Скуратов кебек мәгълүм затлар укытты. Мин монда да белем эстәү белән генә чикләнмәдем, беренче курстан ук маэстро Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге Халык уен кораллары дәүләт оркестрында уйнадым һәм, шиксез ки, әйтеп бетергесез тәҗрибә тупладым».

Ошбу талантлы музыкантның эшчәнлек даирәсе гаять киң: ул бер үк вакытта берничә халык уен кораллары коллективын җитәкләрлек җегәргә ия, алар арасында Казан дәүләт мәдәният институты, Казан музыка көллияте оркестрлары бар. Рәсим Ильясов килүгә, һәр иҗат берләшмәсе яңа сулыш алып яши башлый. Әйтик, ул 2010 елда җитәкли башлаган Казан дәүләт мәдәният институты оркестры шул кыска гына арада да бик зур алгарыш ясый, чәчәк аткан 1980 нче еллардагы (Анатолий Шутиков чоры) дан-шөһрәтен кире кайтара. Бүген бу коллектив җөмһүриятебезнең иң мәртәбәле концерт залларында сәхнә тота, идеологик җәһәттән әйтеп-мактап бетергесез зур, мәгънәле һәм, һичшиксез, кирәкле эш башкара.

Рәсим Ильясовның әйтми калдырырга ярамаган тагын бер сәләте бар әле, ул да булса – аранжировка ясау һәм оркестр өчен партитуралар язу осталыгы.

Аның халык уен кораллары оркестрына яраклаштырып эшкәртелгән музыка үрнәкләре тирәнлекне тою, милли традицияләргә сакчыл караш, гыйлемлек һәм чын һөнәрилек белән аерылып тора. Аның кулыннан вә җаныннан үткән «Кырым хайтармасы», «Кадриль», «Яһүд сюитасы», «Ирландия ритмнары», «Венесуэлла биюе» кебек аранжировкаларда беренчел мәгънә, әсәрнең асылы сакланып, ләкин, шул ук вакытта, заманча яңарып, сафланып кала алган. Сәнгатькәрнең фантазия очышын һәм тирән, киң миллилеген чагылдырган «Татар темаларына парафраз», «Татар мозаикасы», «Туган тел», «Шомыртым», «Туган ил» әсәрләрендә халык көйләре авторның җан авазы белән гаҗәеп тыгыз һәм гаять табигый рәвештә үрелгән.

Рәсим Ильясовның мәртәбәле мөгаллим булуын да истән чыгарырга ярамый. Югары уку йортлары, музыка көллиятләре студентлары, музыка мәктәпләре укучылары остазларын олпат сәнгатькәр саный, аны бик ихтирам итә һәм: «Ул – музыкада илһамнан һәм камиллектән торган үз дөньясын тудырган шәхес», – дип сокланып кабатлый.

Болар барысы да, мөгаен, Рәсим Ильясовны талантлы музыкант, стильне һәм заманны тирәннән тойган искиткеч дирижер, яраткан мөгаллим дип атарга, димәк ки, гомумиләштереп, бәхетле сәнгатькәр, дип танырга тулы хокук бирәдер. ■

Безнең мирас №7 июль 2018

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ЯСӘВИ ӘХМӘД (1105/1103?-1166) – шагыйрь һәм дин эшлеклесе, суфичылык тарикатенең күренекле вәкиле, шәех. Татарча чыганакларда язылышта *Әхмәт Ясәви, Хуҗахмәт Ясәви, Хуҗа Әхмәд Ясәви* вариантлары күзәтелә. Әүлия дәрәҗәсенә ирешкәнгә, аны *Таҗ Әхмәт* дип тә атаганнар. Кушаматы *Баба Төкләч* һәм *Төкле чәчле әүлия* булган (Н.Исәнбәт; ә Әхмәдзәки Вәлидидә –*Баба Туклас*). Гомумән, Әхмәд Ясәвинең унбер исеме булган дип исәплиләр.

Әхмәд Ясәви Төркестан шәһәрендә (хәзерге Казакъстанның Чимкент өлкәсендәге Сайрам шәһәре) шәех гаиләсендә туган. Риваятьләргә караганда, әтисе Ибраһим бәкнең (Ибраһим ибн Мәхмүд ибн Ифтизарның) нәселе Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) кызы Фатыймага барып тоташа. Әхмәд бик иртә әтисез кала. Әнисе Карасач-ана бик матур, көчле ихтыярлы һәм гакыллы хатын булган. Алар угылларын ул заманда фән һәм мәгърифәт учагы исәпләнгән Мәрв шәһәренә укырга китерәләр. Әхмәд суфичылык буенча тәрбияне *Арслан Баба ишаннан* һәм мәшһүр мөтәсаувиф *Хуҗа Йосыф Һәмаданидән* ала. Соңра тәэсирле вәгазьләре һәм хикмәтле шигырьләре



Әхмәд Ясәви мавзолее

белән таныла, үз тирәсенә мөридләр туплый.

Әхмәд Ясәви тарикатендә шәкертләргә Аллаһының исемнәре санынча зикер өйрәтелә.

Ясәвинең шигырьләре «Дивани хикмәт» исеме белән мәҗмуга рәвешендә китап булып еш басылган. Мәс., аның бишенче Казан басмасы (1878) 149 хикмәтне үз эченә ала һәм шуларның 109ы Әхмәт Ясәвинең үзенекеләре дип исәпләнелә.

Әхмәд Ясәви саманилардан соң Бохараның түбән тәгәрәвен авыр кичерә, чөнки үзара сугышларның кая таба алып баруын ачык күрә. *«Халыкта элекке юмартлык бетте, әүвәлге шаһ һәм вәзирләрнең хакыйкатеннән эз дә кал-*

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

мады, Аллаһы Тәгалә дәрвиш антын кире кага... Коточкыч афәт килә халыкка, ий бәндәләр!» –ди шагыйрь һәм философ.

Ясәвинең төш юрау сәләтенә ия булуы турында да хәбәрләр бар.

Әхмәд Ясәви илле биш-илле алты яшьләрендә Бохарадан Яссыга җир астындагы хөҗрәдә ялгыз дәрвишлектә яшәргә дип китеп бара. Аның өчен бөтенләй башка кануннарга буйсына торган яңа тормыш башлана. Ул, дөнья мәшәкатьләреннән арынып, алардан ваз кичеп, илаһи рәхәтлекләргә ирешә, ягъни Пәйгамбәр рухына ия була. Андыйларны *мөхәммәдиләр* дип атыйлар.

Әхмәд Ясәви кеше күкрәгендә биш гөмбәз бар дип исәпли. Беренче гөмбәз *«кальб»*, ягъни йөрәк дип атала һәм сул як имчәктән ике бармак иңлегендә түбәнрәк урнашкан була. Икенчесе *«рух»* дип йөртелә һәм уң имчәктән ике бармак иңлегендә түбәнрәк тора. Өченчесе беренчесе өстендә урнаша һәм *сер* дип атала. Дүртенче гөмбәз – *хафи*, ягъни яшерүле. Бишенчесе дүртенче һәм икенче гөмбәзләр арасында, *ихфа* (яшерен) дип атала. Әхмәд Ясәви бөтен рухи дөньяны күкрәгенә сыйдырган һәм Аллаһы белән сөйләшкән.

Мөселман татарлар Әхмәд Ясәвине үзләренең рухани атасы дип таныйлар. Ш.Мәрҗани Әхмәд Ясәви турында борынгы Төркестан заманыннан килеп ирешкән бер канатлы сүзне теркәп куйган: *«Мәдинәдә Мөхәммәд булса, Төркестанда Хуҗа Әхмәд бар»*.

Әхмәд Ясәви, хак мөселман буларак, Пәйгамбәрдән (с.г.в.) озаграк яшәүне (Мөхәммәд Пәйгамбәр 62 яшьтә вафат булган) язык күрә, шуның өчен ул, алтмыш өченче яшендә Алла кушуы буенча «җиргә керде кол Хуҗахмәт», дип яза. Әмма аның теләге алданрак үтәлә – ул 51 яшендә дөнья куя (Әхнәф Харисов буенча).

Әхмәд Ясәви 1166 елда вафат булып, Яссыда җирләнгән. Тиздән аның кабере өстенә тыйнак кына тәбәнәк мазар куела. Вафатыннан соң 230 еллар үткәч, мәшһүр әмир һәм җиһангир Тимерләнг (Аксак Тимер) аның кабере урнашкан җиргә ике гөмбәзле зур төрбә-мавзолей төзетә (XV гасырның башы). Бу корылма нигезендә 46,5 х 65,5 метрлы, порталлы һәм берничә гөмбәзле гаять зур бинадан гыйбарәт. Аның үзәк залы (җәмәгатьханә яки казанлык) өстендәге гөмбәзе 37,5 м биеклеккә җитә. Төрбәгә гаять зур пиштак (портал) ишегеннән керелә. Тышкы стеналарның калынлыгы 1,8-2 метр булып, казанлык стеналары 3 метр тәшкил итә. 50 метр киңлектәге порталның ике кырында ике манара тора. Урта биеклеккә кадәр алар сигез кырлы, ә өстәрәк – түгәрәк.

Хуҗа Әхмәд Ясәви төрбәсенең язмышы фаҗигале дә, гыйбрәтле дә. XIX гасыр урталарында Төркестан шәһәре Коканд ханлыгына кергән. 1864 елда аны рус гаскәрләре чолгап алганнар. Әмма башта сугыш хәрәкәтләре русларга уңыш китермәгән, кокандлылар бирелергә теләмәгәннәр. Шуннан соң полковник Веревкин әмере белән Ясәви төрбәсенә артиллерия тупларыннан ата башлаганнар. Унбер снаряд диварларны, катара түшәмәләрне тишкән, зәңгәр көзлек плитәләрен ваткан. Соңыннан снаряд ясаган «җәрәхәтләр» аша мазар эченә карлыгыр, ком үтеп керә башлаган. Дөрес, Коканд ханлыгы буйсындырылганнан соң, инде 1884 елда, җәмәгатьчелек фикере басымы астында, патша хакимияте мавзолейны ремонтлау өчен унбиш мең сум акча бүлеп биргәннәр. Кызганыч ки, ремонт вакытында борынгы бизәкләрне темпера буявы белән сылап, казанлыктагы чынаяк кирпечләрне кубарып ташлаганнар. Көнбатыш диварны җимерелүдән саклау өчен таш терәүләр – контрфорслар салганнар... Шул рәвешле, төрбәне ремонтлауның зыяны да зур булган. Тора-бара комплексның аерым өлешләрен җимергәннәр...

1951-1957 елларда ремонт эшләренә яңадан керешкәннәр. ■

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

И.А.ВТОРОВ ТУПЛАНМАСЫ

Идел буе төбәгендә исеме билгеле библиофил һәм төбәкне өйрәнү белгече Иван Алексеевич Второв (1772-1844) җыйган китаплар коллекциясе – бик бай һәм кызыклы тупланмаларның берсе. 1835 елдан ул Казанда төпләнеп яши башлый. Иван Алексеевич дөнья куйганнан соң, аның улы Николай Иванович Второв (1818-1865) мирас булып калган том-том китапларны шәһәр карамагына, җәмәгать китапханәсе ачылуга өметләнеп бүләк итә. Җәмгысе – 1908 томнан

*Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

торган байлык. Шулай итеп, шәһәребездә 1865 елда китапханә ачылуга Второвлар гаиләсенең китаплары төп сәбәпче була. Шул заманнан алып хәзерге көнгәчә бу тупланма, үзенең беренче иясе һәм китапларны җыючы исеме белән, «Второв коллекциясе» дип аталып йөртелә.

Бүген Второвлар коллекциясендә 1069 исемдә 1714 том китап һәм брошюра, вакытлы матбугат төпләнмәләре исәпләнә. Тупланманың хронологик кысалары 1734-1865 елларны үз эченә ала. 1276 документ – иске басма китаплар, болар коллекциянең 75 процентын тәшкил итә. Шулардан 353 исемдәгесе XVIII гасырга карый, 923е XIX гасырга, төгәлрәк әйтсәк, 1830 нчы елга чаклы басылганнар. Иң «борынгы» китаплардан Ф.Карон китапларын мисалга китерергә була: «Япон хакында тасвирлама...» (1734),

«Гади һәм катлаулы машиналарны өйрәнүгә кыскача белешмә» (1738), «Азовка кагылышлы барча очракларның кыскача тасвирламасы, шәһәргә нигез салынганнан алып аның Россия державасына кайтуына чаклы» (1738).

Эчтәлеге ягыннан коллекция универсаль характерлы. Китаплар тупланмасының беллетристикага караган бүлеге (гомум тупланманың 30 проценты) – мөгаен, иң кызыклысыдыр. Монда инде М.Ломоносов, А.Сумароков, Г.Державин, Д.Фонвизин, князь И.Долгоруков, А.Радищев, Н.Карамзин, Ф.Булгарин, В.Жуковский, А.Пушкин, Д.Давыдов, Шиллер һәм башка шундый мәртәбәле шәхесләрнең әсәрләре урын алган.

Якынча егерме җиде процентка якын хезмәт тарих һәм география өлкәсенә карый. Болар арасында: Н.Новиковның «Россиянең борынгылыкларын бәян итүче...» (1776), аббат Милотның унөч томлык «Борынгы һәм яңа чорлардагы бөтендөнья тарихы» (1820), М.Ломоносовның «Россиянең борынгы тарихы» (1766), Н.Карамзинның «Рос-

сия дәүләте тарихы» (1833), Л.Максимовичның «Рус дәүләтенең тулы һәм яңа географик сүзлеге» (1788), губерна һәм наместничестволарның топографик һәм икътисади-физик яктан тасвирламалары бар, шулар рәтендә П.Палласның «Россия империясенең төрле төбәкләренә сәяхәт»е (1773) һәм П.Рычков хезмәтләре.

И.А.Второв тупланмасында фәлсәфәгә, мантыйкка караган китаплар аерым бер игътибарга лаек. Монда Я.Козельскийның данлыклы «Фәлсәфи тәкъдимнәр»е (1768), С.Колокольников французчадан тәрҗемә иткән «Дөнья яралышыннан алып бүгенге көнгә кадәрге фәлсәфәнең кыскача тарихы» (1785), Ж.-Ж.Руссоның «Ялгыз йөреп фәлсәфи уйланулар»ы (1802), Цицеронның «Игелеклелек хакында фикер йөртү»е («Рассуждение о добродетели») (1820) һәм «Вазыйфалар хакында өч китап» (1761) бар.

Табигать белеменә, авыл хуҗалыгына, медицинага караган китаплар да байтак. Шулар арасыннан берничәсен санап китик: «Саннарга логарифмик таблицалар...» (1791), С.Назаровның «Гамәли геометрия»се (1775), Ламбертның «Җиһан системасы» (1797), Д.Цициановның «Ызанлап җир бүлүнең кыскача математик аңлатмасы» (1757), П.Гиларовскийның «Физикага кулланма» (1793), И.Мартыновның «Үсемлек төре исемнәренең сүзлеге» (1826). Боларга тагын җирнең кадерен белеп файдалану, мал үрчетү, йорт хуҗалыгын алып баруга багышланган хезмәтләрне дә кертергә була.

Дин өйрәтмәләре хакында да китаплар шактый. Менә аларның кайберләре: А.Галлерның «Ходай ихтыяры белән иңдерелгән хикмәтләрнең асылы хакында хатлар»ы (1799), П.Алексеевның биш томлы «Чиркәү сүзлеге» (1817). Боларга тагын зиярәт кылучыларның изге урыннарга сәяхәте, вәгазь, үгет-нәсыйхәт китаплары өстәлә.

Кануннар җыентыклары да бар. «Россия империясенең кануннар тупланмасы» (1835), аталы-уллы Фёдор һәм Александр Правиковларның унбиш томлы «Истә калырлык кануннардан...» (1820-1824) китаплары һәм В.Кукольник, Ф.Вирст, Беккарий һ.б. хезмәтләре шушы өлкәгә карый.

И.А.Второв китапханәсенең байтак өлешен альманахлар, энциклопедияләр, җыентыклар тәшкил итә. Әйтик, «Утренняя заря» («Иртәнге шәфәкъ», 1807-1808), «Пчела» («Бал корты», 1805), «Северные цветы» («Төньяк чәчәкләре», 1825-1831), «Невский альманах» («Нева альманахы», 1826-1831), «Альбом северных муз» («Төньяк музалары альбомы», 1828), «Подснежник» («Умырзая», 1830) һәм тагын күп кенә басмалар.

Барча басмалар да диярлек рус телендә, төрле чит телләрдән тәрҗемә ителгән китаплар күп.

И.А.Второв тупланмасындагы китапларның күпчелеге Санкт-Петербург һәм Мәскәү типографияләрендә басылган. Казан (16 документ), Одесса, Орел, Киев, Смоленск, Дерпт (Эстониянең Тарту шәһәре), Тамбов, Харьков, Уфа, Калуга шәһәрләре типографияләрендә дөнья күргәннәре дә бар.

Фондтагы китаплар Казан җәмәгать китапханәсе оешкан чакта номерланган һәм шул номерлар тәртибендә тезелеп тора. Аерым тупланма рәвешендә саклана. Второв китапларының титул битенә «Из книг Второва» («Второв китапларыннан») дигән кара төстәге мөһер сугылган. 1998 елдан соң табылган китапларның мөһере – зәңгәр төстә.

Милли китапханәбездә Казан җәмәгать китапханәсе оешкан дәвердәге беренче басма каталог (1870, 1878) та саклана. Анда Второв тупланмасы хакында аерым кимәлгә куеп искәртелә. Бу фонд җентекләп тасвирланган, эчке файдаланудагы һәм укучылар каталогларына да кертелгән. Карточкалы, тематик бүленешле махсус топографик каталог та эшләнгән. Электрон каталогы Милли китапханәнең Интернеттагы сайтында урын алды. «Второвлар китапханәсе каталогы» аерым китап булып та басылып чыкты. ■

СИМЕТБАШ ҖЫЕНЫ-2018

Арча районының Симетбаш авылында узган җыенның иганәчесе «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин

Абсолют батыр – Россия Федерациясенең спорт мастеры, ике мәртәбә Татарстан чемпионы Фирдүс Зәйнуллин

КУКМАРА МИРАСЫ

Киез итекләр иле

Әгәр Кукмараны үзенә күрә бер кечкенә ил дип гоман кылсак, аны, һичбер икеләнүсез, «Киез итекләр иле» дип йөртергә булыр иде.

КУКМАРА ТИРӘСЕНДӘГЕ ОСТАХАНӘЛӘР

XIX гасырда киез итек басу эше Кукмара авылыннан читтә дә киң колач ала. Билләһи газыйм, итек басу эше белән шөгыльләнмәгән авыл калмагандыр ул чорда. Шулай да эре остаханәләр Сәрдекбаш өязендәге Түбән Казаклар авылына карый, дисәк, һич хата булмас. Уңган-булган кешеләр яшәгән бу авылда. Тарихка кереп калган берничә исемне искә төшерик.

1877 елда Ситдыйк Габделгаффаров киез ката басу остаханәсе оештырып җибәрә. Аңа 20 кеше хезмәт куйган. Шуның 12се үз өендә торып эшләгән. Эш сентябрьдән алып майга кадәр өзлексез дәвам иткән. 1886 елда Габделгаффаров остаханәсендә 7000 сумлык 3000 пар итек җитештерелгән. Ул итекләр Минзәлә һәм Бөгелмә ярминкәләрендә, шулай ук Алабуга белән Чистай базарларында сатылган. Ситдыйк Габделгаффаров белән бер үк вакытта Мөхәммәтвәли Ситдыйков та үз эшен ачып җибәрә. Аларның авылдашлары Габдулла Казаков белән Каюм Фәизов, итек-ката җитештереп кенә кал-

Кул хезмәте – авыр хезмәт (ир-атлар итек басу белән мәшгуль)

Безнең мирас №7 июль 2018

Насыйр Садыйков фабрикасының бирка-жетоны

Кукмара авылы эшмәкәрләре бертуган Кокаревларның жетон-биркасы

мыйча, хәтта «югары арена»га күтәрелергә җөрьәт итә, 1890 елда Казанда узган фәнни-сәнәгый күргәзмәләрдә катнаша. Габдулла Казаков анда 3-5,50 сумлык алты пар итек тәкъдим итә. Кирәкле материалларны, мәсәлән, Каюм Фәизов урындагы базарлардан сатып алган, ә инде әзер продукцияне исә Сембергә, Минзәләгә һәм Чистайга озаткан.

Гадәттә, киез итек басу эше нәселдән-нәселгә күчкән. Әлеге дә баягы Түбән Казакларны гына алыйк. Шушы авыл кешесе Габдулла Гыйззәтулла улы Казаков үз эшен 1867 елда башлап җибәрә. Бераздан ул «А.Г.Казаков уллары белән» дигән Сәүдә йорты оештыра. Габдулла Казаков 1906 елда вафат булганнан соң, Сәүдә йорты белән аның уртанчы улы Хәйрулла Казаков (1874-1937) идарә итә башлый. Ул хакимлек иткән чорда, әйтик 1909 елда, 400 эшче тарафыннан елына 130 мең пар итек җитештерелә.

Насыйр һәм Фатих Садыйковлар, Каюм Фәизов һәм «А.Г.Казаков һәм уллары» Сәүдә йорты үз эшчәнлеген 1913-1914 елларга кадәр дәвам иттерә. Алда санап үтелгән эшмәкәрләрнең язмышлары совет власте заманында бик аяныч тәмамланган. Хәйрулла

Хәйрулла Казаков хатыны Әминә һәм газиз балалары белән. 1910 нчы еллар фотосы

Киез итекне юу. 1920 нче еллар фотосы

Казаков гаиләсен алыйк. 1930 елда аларны «раскулачивать» итәләр: гаилә башлыгы, аның хатыны Әминә Гарәф кызы (1887-1967), аларның балалары – Гали (1908-1982), Мәрьям (1916 елда туганлыгы мәгълүм), Фәридә (1918-1976), Гомәр (1921 елда туган), Фатыйма (1925 елгы), Зәйнәп (1928-1992) Красноярск краендагы Лужанки Удерейский (хәзер Мотыгинский) районына сөрелә. Өлкән уллары – Гали Хәйрулла улы Казаков 1938 елда кулга алынып, 10 елга хөкем ителә (Норильлаг). 1946 елда ул азат ителә һәм Норильскига сөргенгә сөрелә. Анда ул 1956 елга кадәр яши – «Аэродромстрой»да баш бухгалтер булып эшли. 1962 елдан соң гына ул Красноярскида яшәү хокукына ия була. Гомәр һәм Фатыйма – Бөек Ватан сугышы ветераннары. Фатыйманың ире Фатих Арсланов та Норильлаг афәтен үтә. Сәяси тоткыннар бары тик 1993 елда гына акланды.

САБАНТУЙЛЫ ФОТОХАТИРӘ

«Сабан туе – 2015» стенды янында. Сулдан уңга: ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов, Кырым Республикасыннан С.В.Аксенов, Кукмара муниципаль район хакимияте башлыгы С.Д.Димитриев, «Киез-киез итек комбинаты»ның генераль директоры Шамил Әхмәтшин. 2015 ел

Комбинат директоры Шамил Әхмәтшин Советлар Союзы Каһарманы, Россия Федерациясе Каһарманы, Арктика һәм Антарктиданы өйрәнүче-тикшерүче А.Н.Чилингаров белән. Казан, Сабан туе, 2013 ел

«Универсиада-2013» вакытында Казанда Сабан туе. Комбинат директоры Ш.Әхмәтшин Россия Каһарманы, өч тапкыр Олимпия чемпионы А.А.Карелин белән. 2013 ел

*Язманы **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

ИЮНЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 6 июньдә Арча шәһәрендәге «Казан арты» тарих-этнография музеенда ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, төбәкне өйрәнүче Ринат Фазлыйәхмәтовны искә алу һәм аның яңа басылып чыккан «Шәхесләрдә Арча тарихы» исемле китабын укучыларга тәкъдим итү кичәсе булды.

● 8 июнь көнне Казанның Кол Шәриф мәчетендә, «Татлы Рамазан» акциясе кысаларында, Казан халкына һәм кунакларга хөрмә өләшенде. Акциянең оештыручысы – Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте.

● 10 июнь көнне Бохарада Сабан туе узды. Милли бәйрәм бу ел Үзбәкстан Республикасы бәйсезлегенә – 27 ел, Бохара өлкәсе Татар-башкорт милли-мәдәни үзәгенә 25 ел тулу уңаеннан оештырылды.

● 11 июнь көнне Коми Республикасының Ухта шәһәрендә Сабан туе гөрләде. Ухтада яшәүче милләттәшләребез өчен бу икеләтә бәйрәм, чөнки әлеге көн Ухта шәһәренең «Бердәмлек» татар-башкорт милли-мәдәни автономиясенең 20 еллыгы да. Җыелган кунакларны Коми Республикасының милли сәясәт министры Галина Габушева, Ухта шәһәре администрациясе җитәкчесе Магомед Османов, Ухта шәһәренең «Бердәмлек» татар-башкорт милли-мәдәни автономиясе рәисе Ләлә Потапова, Бөтендөнья татар конгрессы вәкиле Булат Ибраһимов сәламләде.

● Азнакайда узган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция материаллары, бергә тупланып, «Человек и природа в бассейне реки Ик: история и современность» исемле җыентыкта басылып чыкты. Хезмәтнең мөхәррире – Альберт Борһанов.



● 17 июнь көнне Канаданың Монреаль шәһәрендә Сабан туе үтте. Милли бәйрәмне

«МИРАС»татар мәдәни үзәге, «Русский мир Монреаля» оешмасы һәм Самбо-Монреаль мәктәбе берләшеп оештырды.

● 17 июньдә Кукмарада узган Сабан туенда катнашкан кунаклар арасында ТР премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева, тумышы белән Кукмарадан булган күренекле галим һәм язучы Фоат Галимуллин һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон катнашты. Сабан туен Кукмара муниципаль район хакимияте башлыгы Сергей Димитриевич Димитриев ачты.

● 23 июнь көнне Казанның Мирный бистәсендә Татарстан Республикасы Президенты

Рөстәм Нургали улы Миңнеханов һәм футбол чемпионаты кунаклары катнашында Сабан туе узды.

● 23 июньдә Азнакайда Ык буе авыллары Сабан туе үтте. Бәйрәмдә Башкортстан һәм Татарстаннан, Оренбург өлкәсеннән килгән кунаклар катнашты.

● 24 июньдә Урта Бирәзә авылында үткән Сабантуйда «Ак Барс» хоккей командасы капкачысы Эмиль Гариповка «Арча муниципаль районының Мактаулы гражданины» исеме бирелде. Әлеге дәрәҗәле исем бирелү турындагы таныкнамәне район хакимияте башлыгы Илшат Нуриев тапшырды.

Мирасворд

… Урайский

Әдәби әсәрнең эчтәлеге һәм анда сурәтләнгән вакыйгалар

Ачы төтен

Компози-тор Әнвәр …

Чад каласы

Бу (баш-кортча)

Бәрү, ору

Йөгәннең ияк асты каешы

Төньяк халкы

10^{12}

… Ман-дельштам

Грек хәрефе

Тажик әдибе

Кайбер хайваннар-ның муенын-дагы озын куе йон

Актриса … Гәрәева

Наборны юлы-юлы белән коеп җыя торган типография машинасы

Йорт, бина (иск.)

Ат җигү дирбия-се

Ачык, билгеле, мәгълүм (иск.)

Бай, дәрәҗәле кешенең һәр сүзен үтәргә әзер торган куштан, иярчен

Аз санлы фин-угор халкы

Африка-дагы ил

Кадыйр … (башкорт шагыйре)

Кагылыш-лы, мөнә-сәбәтле (иск.)

Драматург … Хәмид

Рус телендә чыга тор-ган әдәби журнал

Язучы, күпсанлы тарихи романнар авторы

Батыр-Болгари, Янсуар

Күчмә төрки һәм монголлар-ның түгәрәк киез торагы

Кәрим Тинчурин драмасы

Электр корылма-лы атом

Күзен яки язын елга өстен тутырып ага торган көпшәк боз

Шагыйрь … Арсланов

Леонардо … Каприо

Актаныш районындагы авыл

Иделле, Гобәйдул-лин, Мөхәм-мәтшин

Арбаның алгы өлешендә кучер утыру өчен ясалган урын

Ир бала (иск.)

Кәҗә бәтие (диал.)

6 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: көре, күмә, Асо, Лэис, Нәби, ылкын, каузы, яла, тархан, Илнәт, Ирек, улан, квинарий, Ика, аак, ачыткы, фәләк, Риони, Шамов, гекта, Анкона, го, скаут.
Өстән аска: Итака, «Түләк», вафа, Баян, икәм, Вәлиуллин, «Логан», «Заира», эвен, ерак, кокк, кич, тога, «Сынау», Насрый, Раил, ти, «Ант», өсәк, Халиков, Колыма, акын, «Нана».

Рәис Гайдулла төзеде.

Шагыйрь Кол Галигә Ульяновск каласында куелган һәйкәл

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
елъязмасы / июль

835 ел элек (1183)

Шагыйрь Кол Гали (1183-1236) дөньяга килә.

690 ел элек (1328)

Үзбәк хан урыс кенәзләрен Алтын Урданың башкаласы Яңа Сарайга чакыртып ала, Мәскәү кенәзе итеп Иван Калитаны билгели һәм вазыйфалыкка ярлык тапшыра. Шул чордан алып Мәскәү Русена татар һөҗүмнәре туктала. Бирелә кырык елга тынычлык урнаша.

400 ел элек (1618)

Гарәп шрифты белән Лейпциг шәһәрендә басылган татар телендәге беренче китапның төзүче-авторы Иероним Мегисер (1555-1618) вафат була.

100 ел элек (1918)

10-17 июльдә Казанда Ильяс Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге театр труппасының гастрольләре башлана.

95 ел элек (1923)

Галимҗан Ибраһимов белән Шәһит Әхмәдиев «Шәрыкны өйрәнүчеләрнең Бөтенроссия җәмгыяте»нә әгъза итеп сайланалар.

90 ел элек (1928)

4 июльдә Татарстан хөкүмәте «Татарстанны өйрәнү җәмгыяте» төзү турында карар кабул итә.

9 июльдә Башкортстанның Баймак авылында күренекле драматург Мирхәйдәр Фәйзи (1892-1923) вафат була.

75 ел элек (1943)

9 июльдә Карелия фронтында чыга торган «Ватан өчен сугышка» газетасында Шәрәф Мөдәрриснең «Тупчы Ваһап» исемле поэмасы басыла.

70 ел элек (1948)

Татарстан китап нәшриятында Галишер Нәвоиның Әхмәт Исхак тәрҗемәсендә «Фәрхад вә Ширин» поэмасы дөнья күрә.

55 ел элек (1963)

«Совет әдәбияты» журналында Сибгат Хәкимнең «Язгыгыз, җир уллары» поэмасы басылып чыга.

Журналга ***Айдар Закиров*** *әзерләде.* ■



СОДЕРЖАНИЕ. ИЮЛЬ 2018

Историческое наследие: «Гаухаршад». О.Иванова; «Судьба Казанского ханства». Б.Хамидуллин; «Нагайбаки-казаки: численность, место проживания и самоуправление». Р.Аминов; «Реализация татарского языка». Х.Габидуллин; «Ичкинские татары». Р.Исакаев; «Эх, увидеть бы, что за человек этот татарин?» Л.Муртазина; Гарифжан Мухамматшин: «Истоки нравственности в деревне!»; Марат Юнусов: «Возлагаем большие надежды на Сабантуй»; «Ремесленники деревни Катай». Т.Каримов; «Церковь Икшурма». Г.Закирова.

Тюркский мир: «Кто такой Пурхи Ахван?»; «Чуваши». З.Башири.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Г.Ибрагимов.

Литературное наследие: «Соловей». Г.Галиев.

Художественное наследие: «Немного о себе». Р.Шарафи.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов». А.Тимергалин.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан»; «Джиен Симетбаша-2018»; «Страна валенок».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. JULY 2018

Historic heritage: «Gaukharshad». by O.Ivanova; «The fate of Kazan khanate» by B.Khamidullin; «The Nagaybak Cossacks: its quantity, settlement and self-government» by R.Aminov; «The problems of usage Tatar language» by Kh. Gabidullin; «The Ichken Tatars» by R.Isakaev; «Here to see what kind of man this Tatar is!» by L.Murtazina; Garifdjan Mukhammatshin: «The root of morality is in the village!»; Marat Unusov: «We have great expectation on Sabantuy»; «The craftsmen of Katay village» by T.Karimov; «Ikshermya church» by G.Zakirova.

Turkic world: «Who is Purkhi Akhvan?»; «The Chuvashes» by Z.Bashiri.

Religious heritage: «Islamic world» by G.Ibragimov.

Literary heritage: «Nightingale» by G.Galiev.

Creative heritage: «Something about myself» by R.Sharafi.

The word is a decoration of language: «The national terms' glossary» by A.Timergalin.

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan»; «Simetbash meeting 2018»; «The felt-boots country».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

«Минем кызым Алсу».
Киндер, майлы буяу. 1999 ел

Фәрит Харис улы Якупов

1951 елның 28 апрелендә Казан шәһәрендә туа.

Казан сынлы сәнгать училищесын (1970) һәм И.Е.Репин исемендәге Ленинград рәсем сәнгате, скульптура һәм архитектура институтын (1976) тәмамлый.

1977-1980 елларда Казандагы Россия рәсем сәнгате академиясе иҗади остаханәсендә шөгыльләнә.

СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1980), ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2002).

Казан шәһәрендә яши һәм иҗат итә.

«Мәчет янындагы ишегалды».
Киндер, майлы буяу. 1992 ел

«Әти белән сөйләшү». Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Зәйнәп Садыйкованы КПСС Өлкә комитетында Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелү белән котлау. 1966 ел
(Ильяс Салихҗан. «Батыр йөрәкле Зәйнәп».)

Нигъмәтулла хаҗи. Ризаэддин Фәхреддин
Академик Мирфатыйх Зәкиевнең фәнни хезмәтләре. Малик Хәйруллин
Бүре кыйссасы. Рәсим Хәбибулла
Әсма апа. Рифкать Шаһиев
Бөекләрнең туганлыгы. Ринат Нуруллин
Татарлыкта татар улы татармын. Илдус Фазлетдинов
Шагыйрьнең соңгы музасы. Сәмига Сәүбәнова
Батыр йөрәкле Зәйнәп. Ильяс Салихҗан
Мирсәй Әмир турында. Камил Саттар

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
• *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
• *редакциядә*
• *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» *журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*